РИЗАЭТДИН ФӘХРЕТДИН



Казан ханнары

Ризаэтдин Фәхретдин (1859—1936)

РИЗАЭТДИН ФӘХРЕТДИН

Казан ханнары

Олуг Мөхәммәд хан
Мәхмүд хан
Хәлил хан
Ибраһим хан
Илһам (Гали) хан
Мөхәммәд Әмин хан
Габдел-Латыйф хан
Сәхиб Гәрәй хан
Сафа Гәрәй хан
Җан Гали хан
Шаһ Гали хан
Үтәмеш Гәрәй һәм Сөенбикә
Ядкәр хан

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
1995

ББК 63.3(2Тат.)
Ф 97

Китапны төзеде, текстны бүгенге шрифтка күчерде-эшкәртте, искәрмә-аңлатмаларны һәм кереш мәкаләне язды тарих фәннәре кандидаты **Равил ӘМИРХАН**

Нәшрият мөхәррире **Солтан ШӘМСИ**

Рәссамнар
Рушан ШӘМСЕТДИНОВ, Рем ШӘМСЕТДИНОВ

Ф $\frac{0503020900-090}{М132(03)-95}$ без объявл.— 95 **ББК 63.3(2Тат.)**

ISBN 5—298—00491—1
© Татарстан китап нәшрияты, 1995.

ЭЧТӘЛЕК

Галимнәр галиме
(Р. Әмирхан кереш мәкаләсе)

6

Казан ханнары
(Р. Фәхретдин текстлары)

37

Казан — ханлык мәркәзе
(С. Шәмси мәкаләсе)

177

Казан ханнарының хакимлек итү еллары

189

ГАЛИМНӘР ГАЛИМЕ

1

Гаять киң эрудицияле, бөек талант һәм энциклопедик белем иясе, рухи тормышның төрле тармакларында йөзләгән хезмәтләр иҗат иткән олпат шәхес буларак, Ризаэтдин бине Фәхретдин (Риза казый) XIX йөз азагы — XX йөз башларында татар тарихи әдәбияты, иҗтимагый фикер үсеше һәм мәдәниятендә үзәк урыннарның берсен биләп торды. Аның даны Орынбур, Уфа, Казан, Петербург, хәтта Русия масштаблары белән генә дә чикләнмәде, бәлки чит мәмләкәтләргә, бигрәк тә төрки һәм Ислам дөньясында киң таралды. Аның шәхесе белән әле революциягә кадәр үк М. Горький кызыксынды. 1911 елда Гаяз Исхакыйга язган бер хатында ул урысча чыгуы күздә тотылган «Татар әдәбияты» дигән җыентыкка Р. Фәхретдиннең биографиясен һәм аның эшчәнлеге турында белешмә урнаштыру кирәклеген искәртте[1]. Әмма Ризаэтдин Фәхретдиннең куәтле сәләте, иҗтимагый, фәнни интересларының егәре, колачы аның тарихи эзләнүләрендә барыннан да калкурак чагылыш тапты. Шуңа күрә аның үз-үзен мөәррих, ягъни тарихчы дип атап йөртүенең җитди җирлеге бар.

Ялкынлы каләм остасы, тарихчы, археограф, мәгърифәтче, әдип, филолог, журналист, нәсихәтче, олуг дин әһеле, фикер иясе, педагог Ризаэтдин бине Фәхретдин бине Сәйфетдин 1859 елның 4 гыйнварында (яңа стиль белән 17 гыйнварда) хәзерге Татарстанның Әлмәт рай-

---

[1] Гайнуллин Мөхәммәт. Татар әдипләре: Иҗат портретлары. Казан, 1978, 79 б.

оны Кичү Чаты авылында мулла гаиләсендә дөньяга килә. Тәүге сабакларын укымышлы әти-әнисеннән алганнан соң, ул 7 яшендә мәктәп бусагасын атлап керә. Бәләкәй авылның бәләкәй мәктәбе сәләтле малай өчен тар булганлыктан, тәкъдир аның алдагы язмышын күрше Түбән Чыршылы авылы мәдрәсәсе белән бәйли. Өлкәнрәк сыйныф шәкерте булып киткәч, эш сөючән, тырыш, һәр нәрсә белән кызыксынучан Ризаэтдин күп вакытын китаплар күчереп язуга багышлый, шул рәвешчә заманы өчен бай гына китапханә туплый. Шул ук чорда туган татар теленнән башка гарәп, фарсы, төрек телләрен җентекләп өйрәнә, бу өлкәдә зур уңышларга ирешә. Болар белән генә чикләнмичә, алдынгы шәкерт башлангыч сыйныф балаларына дәресләр бирә, педагогик күнекмәләр ала. Гомумән, тәрбия эше һәм нәсихәт Ризаэтдиннең гомерлек юлдашына әверелә.

Гарәпчә, фарсыча һәм төрекчә әдәбиятны күчерү һәм өйрәнү процессында ул бу телләрдә иркен язып һәм сөйләшеп кенә калмый, бәлки соңрак үзлегеннән укып, урыс телен дә өйрәнә. Гәрчә урысчаны үзләштерү дәрәҗәсе көнчыгыш телләрне белү дәрәҗәсенә җитмәсә дә, Ризаэтдин мәшһүр урыс тарихчыларының фәнни хезмәтләрен иркен файдаланырлык хәлгә ирешә.

Китаплар күчереп язуны үзенең рухи ихтыяҗына әйләндергән шәкерт шушы ысул белән күп кенә акыл иясләренең, тарихчыларның иҗаты белән таныша, аларның карашларын өйрәнә, фәнни алымнарын үзләштерә. Ризаэтдиннең күчереп язган китаплары арасында Шиһабетдин Мәрҗанинең мәшһүр «Мөстәфадел-әхбар»ы да була. Бөек мәгърифәтченең атаклы әсәрләрен уку һәм тикшерү булачак галимгә зур тәэсир ясый, Ш. Мәрҗанинең фәлсәфи кыйбласы, алдынгы карашлары яшь шәкертнең иҗади фикер юнәлешенә җитди этәргеч бирә. Өлкән замандашын күрү һәм, мөмкин булса, танышу максаты белән югары сыйныф шәкерте Ризаэтдин 1886 елда татарның тарихи һәм мәдәни мәркәзе Казанга юл тота. Егетнең хыялы тормышка аша: ул гомер буе үзенең остазы дип йөрткән бөек зат белән танышып сөйләшә. Очрашу аның күңелендә җуелмас эз, зур тәэсир калдыра. Әүвәлге танышудан соң Ризаэтдин Казанда, Ш. Мәрҗани өендә берничә тапкыр булып китә. Очрашуларның берсендә олуг галим өлкән шәкерткә үзенең 1886 елда басылган бер бик кыйммәтле хезмәтен, «Әл-газбел-фурат...» исемле китабын бүләк итә һәм шушы гамәле белән гүя фәндә

тәүге адымнарын ясый башлаган Р. Фәхретдингә үзенең хәер-фатихасын бирә.

Мәдрәсәдә гыйлем алуын төгәлләгәннән соң, Р. Фәхретдин җиң сызганып балалар укыта, укыту процессында бөек мәгърифәтче Ш. Мәрҗанинең алдынгы ысулларын куллана, тәрбия буенча бай тәҗрибә туплый. Ләкин киң колачлы, әзерлекле егет мәдрәсәдә белем бирү белән генә чикләнми, аның иҗади офыклары киңәйгәннән-киңәя, аңарда рухи дөньяның бай хәзинәсенә шәхси өлеш кертү омтылышы көчәя бара. Яшь галим фәнгә тартыла, ул схоластика киртәләрен җимереп, яңарышны, алга карап атлауны кыйбла итә. Үз каләменең көчен, сүзенең үтемлелеген сизеп алгач, Ризаэтдин иҗади эш белән мавыгып китә, күп кенә китаплар, мәкаләләр яза, татарның рухи тормышына караган язма чыганакларны җыя, аларны әйләнешкә кертеп, яңа сулыш өрә. Р. Фәхретдин артында һәрдаим бу бәрәкәтле эшчәнлеген хуплап-дәртләндереп торган рухи көч — Ш. Мәрҗани образы тора. Мөгаллимлек чорында, ягъни 1887—1888 елларда, яшь галимнең бер-бер артлы «Әт-төхфәтел-әнисия», «Китабет-тәсрыйф», «Китабе мөкаддимә. Әт-тәхрирел мосфа...» һәм «Китабел-игътибар» исемле хезмәтләре дөнья күрә. Алар гарәп теле морфологиясенә, шәригатьчә мирас бүлүгә, тәрбия-әхлак мәсьәләләренә багышланганнар.

1887 елда 28 яшьлек Ризаэтдин имамлыкка имтихан тота. Күрше Илбәк авылында мулла булгач та үз вазыйфасын җиренә җиткереп, намус белән үти, мәхәллә халкы арасында гына түгел, тирә-юньдә дә зур абруй казана. Җәмәгатьчелек аны имам буларак кына түгел, байтак фәнни хезмәтләр иҗат иткән галим буларак та таный башлый, ихтирам итә. 1891 елда Р. Фәхретдинне Уфага, Диния нәзарәтенә казый сыйфатында эшкә чакыралар. Ризаэтдин шул ук елны Уфага күчеп килә, Риза казый исеменә лаек була. Беренче мәртәбәсендә 15 елга сузылган Уфа чоры галим һәм язучы тормышында яңа, күтәренке иҗат дәвере буларак билгеле. Дини мәркәздә, аның бай архивында эшләү Ризаэтдин алдында чикләнмәгән иҗади мөмкинлекләр ача. Ул Диния нәзарәте архивында тупланган бихисап чыганакларны өйрәнә, барлый, аларның күчермәләрен булдыра һәм фәнни әйләнешкә кертеп җибәрә.

Уфада казыйлык вазыйфасын үтәгән чорда Ризаэтдин Фәхретдин «Сәлимә яки гыйффәт» (1899), «Әсма» (1903) повестьларын иҗат итеп бастыра. Аларга, әдәби әсәрләр

буларак, 1912 елда Г. Тукай да югары бәя бирә. Шул ук елларда галим үзенең «Асар» («Эзләр») дип исемләнгән атаклы био-библиографик хезмәте өстендә актив эшли. Бу гаҗәеп әсәр әле бүген дә тикшеренүчеләр тарафыннан тиешле бәһасен алганы юк. «Асар» 1900 елдан алып 1908 елга кадәр Орынбурда (беренче китабы Казанда) 15 чыгарылыш булып басылып чыга. Тупланган очракта алар 2 томны тәшкил итә. Аларда Болгар чорыннан алып XX йөз башларынача Русиядәге мәшһүр ислам галимнәре һәм дәүләт эшлеклеләренең, аларның шәкертләренең, нәсел-нәсәбләренең тормышы һәм эшчәнлеге тасвирланган. «Асар»ның беренче томы 483 бит тәшкил итә, 666 шәхесне эченә ала, ә 572 биттән торган икенче томы 343 затны, ягъни барысы 1009 күренекле кешенең тормышын сурәтли. Ләкин бу томнар галимнең био-библиографик энциклопедия буларак төзергә ниятләнгән хезмәтләрнең бер өлеше генә әле. «Асар»ның 3—4 томнары әлегә басылмаган, ягъни кульязма килеш Уфадагы Башкортостан Фәнни үзәге Урал бүлегенең Тарих, тел, әдәбият институты архивында саклана, үзенең тикшерүчесен һәм, әлбәттә инде, дөньяга чыгарылуын көтә.

Уфада эшләү дәверендә, болардан тыш, Риза казый «Мөталәга», «Тәнзимат», «Тәрбияле ана», «Тәрбияле ата», «Тәрбияле бала», «Тәрбияле хатын», «Шәкертлек әдәбе», «Мәсҗедләр», «Әдәбе тәгълим», «Коръән вә тәбакать», «Гаилә», «Нәсыйхәт», «Мәшһүр хатыннар», «Мәталигы идарәи исламия», «Исмәгыйль сәяхәте», «Ибне Рөшд» кебек тирән эчтәлекле, тәрбиягә, Ислам диненә, аерым шәхесләргә багышланган дистәләгән китабын дөньяга чыгара. Аларның кайберләре 1917 елга кадәр хәтта унар мәртәбә басыла, татар халкы рухи хәзинәсенең кыйммәтле асылташларына әверелә.

1906 ел Ризаэтдин Фәхретдин тормышында текә борылыш ясаган чор. Даны бөтен ислам дөньясына танылган галим һәм дин эшлеклесен атаклы алтынчы миллионерлар — бертуган Шакир һәм Закир Рәмиевлар Орынбур шәһәренә чакыралар. 47 яшьлек Ризаэтдин, казыйлыгын читкә куеп, баштанаяк иҗат һәм мәгърифәтчелек эшенә кереп чума. Башта ул әле яңа гына чыга башлаган «Вакыт» газете редакциясендә актив эшли, анда «Морад» псевдонимы белән күп кенә мәкаләләр бастыра. Бай фәнни һәм педагогик тәҗрибә туплаган галим шул ук вакытта үзенең мөгаллимлек һөнәрен яңартып җибәрә, аннары берничә ел дәвамында татарның

атаклы мәдрәсәсе «Хөсәения»не җитәкли, аны юлга салуга зур көч куя. Шул ук чорларда Р. Фәхретдин үзенең эшчәнлеген татар энциклопедиясенә әверелгән атаклы «Шура» журналы белән бәйли. Башыннан алып ахырына чаклы (1908—1917) галим бу журналның алыштыргысыз мөхәррире — редакторы була. Бертуган Рәмиевлар журналның баш мөхәррире Риза казыйга материалларны сайлауда һәм бастыруда чикләнмәгән ирек бирәләр. Галим үзенә бирелгән хокуктан тулысынча файдалана һәм бар көчен, белемен, оештыру сәләтен халыкны агарту эшенә сарыф итә.

Орынбурда яшәү дәверендә Р. Фәхретдин дистәләрчә яңа әсәрләр иҗат итә, үзенең гыйльми данын тагын да ераккарак тарата. Бу чорда (1906—1918) дөнья күргән китаплардан рухи-мәдәни тормышның төрле өлкәләренә караган «Гакыйдә», «Әһле-гыял», «Мөхәммәд», «Мәшһүр ирләр», «Әбү әл-Галә әл-Мәгарри», «Ибне Гарәпшаһ», «Имам Газали», «Әхмәд бай», «Тел ярышы», «Рәхмәте илаһия мәсьәләләре», «Ибне Тәймия», «Гыйбадәте нисван», «Җәүмигыль кәлим шәрхе», «Ибне Гарәби», «Әхмәд Мидхәт әфәнде», «Дини вә иҗтимагый мәсьәләләр», «Ибне Фазланның Болгарга килүе», «Ибне Баттутаның Дәште Кыпчакка сәяхәте», «Шәйх Зәйнулла хәзрәтнең тәрҗемәи хәле» һ. б. әсәрләрне күрсәтергә мөмкин.

Шуның өстенә «Шура» журналы битләрендә дә киң колачлы галимнең төрле темаларга багышланган 700 дән артык мәкаләсе дөнья күрә. Ләкин болар гына да аз әле. Риза Фәхретдин, башлыча Уфада һәм Орынбурда актив иҗат эше белән шөгыльләнгән чорда, янә 100 томга якын зур күләмле хезмәтләр яза, әмма үзе исән вакытта аларны бастырып чыгара алмый кала. Шуларның 40 томы Уфада, 24 томы Санкт-Петербургта саклана. Аянычка каршы, 20 томы Уфаның Диния нәзарәтеннән каядыр китеп югалган икән. Бу казаның очы 1911 елга ук барып тоташа. Шушы елның 12 февралендә галимнең фатирына полиция басып кереп, тентү ясый, «Асар»ның матбугатка әзерләп куелган 3 нче томын, «Шура» өчен дип язылган бик күп мәкаләләрен, башка кыйммәтле язмаларын конфискацияли, ике ат йөге төяп алып китә. Хакимият бусагаларын бик озак таптаганнан соң Риза казый «Асар»ның 3 нче томы кулъязмасын кайтарып алуга ирешә, ләкин калган материаллары эзсез югала. 1917 елда Орынбурдагы сугыш хәрәкәтләре вакытында галим китапханәсенең тагын зур өлеше һәм күп кенә язмалары һәлак була. 1920

елда Уфада аны хәтта төрмәгә ябалар һәм, Р. Фәхретдин үзе ябылып утырганда өендә тентү ясап, бөтен кәгазьләрен алып китәләр.

Күп кенә телләрне ана теле кебек белгән Р. Фәхретдин Уфа, Орынбур, Казан гыйльми дөньясы белән генә чикләнә алмый, әлбәттә. Ул үзен колониализмга каршы көрәшче дип таныткан Петербург университеты профессоры Җәмалетдин Әфгани, Россия академиклары А. Н. Самойлович, В. В. Бартольд, И. Ю. Крачковский һәм кайбер чит мәмләкәтләрнең байтак галимнәре белән таныш була, алар белән иҗади элемтәдә тора. Русия һәм мөселман илләре галимнәреннән тыш, Риза казый АКШ, Германия, Франция, Испания, Канада, Япония, Кытай, Скандинавия һ. б. илләрнең галимнәре белән языша, уртак фәнни проблемалар чишәргә омтыла. Бу гамәлләре өчен тынгысыз галим үз илендә төрле эзәрлекләүләргә юлыга.

1917 елда Русияне өермәле вакыйгалар ташкыны күмеп китә. Ил бераз вакытка иң демократик дәүләтләр сафына баса. Хөррият, ирек авазы богаулардан котылган күңелләрдә гимн булып яңгырый. Гомумкешелек, иҗтимагый-сәяси төшенчәләргә яңа төсмер өстәлә. Мөселманнар да иркен сулыш ала. Башка мәсьәләләр белән беррәттән, Ислам мәсьәләсен дә яңа җирлектә чишү, хәл итү мөмкинлекләре ачыла. Шушындый күтәренкелек шартларында 1917 елның маенда Мәскәүдә мөселманнарның Бөтенрусия корылтае уздырыла. Ул әлеге вазыйфага бик ашкынып тормаган Ризаэтдин Фәхретдинне яңадан Диния нәзарәтенә казый итеп сайлый. Шуның нәтиҗәсе буларак, Риза казый 1918 елның башында Орынбурдан яңадан Уфа шәһәренә күчеп килә. Тынгысыз галим хәтта шушы очракны да үзенең фәнни багажын баетуда файдалана. Юл уңаеннан ул Башкортостанның атаклы татар авылы Эстәрлебашның мәдрәсә һәм мәчетләрен барып күрә, күреп яки ишетеп белгән кешеләрнең каберләрен зыярәт кыла, тирән көртләрне ерып иске кабер ташларын эзләп, тикшереп йөри. Уфа шәһәрендә бераз казый булып торгач, 1921 елның декабрендә Галимҗан Баруди вафат булганнан соң, ул башта мөфти вазыйфасын башкаручы итеп, ә 1922 елдан мөфти булып эшли башлый. Совет властенең дингә карата үткәрелгән кырыс сәясәте олуг дин әһеленең иҗади һәм гамәли мөмкинлекләрен нык чикли. Ләкин шуңа да карамастан, ул мөфтилек вазыйфасыннан бушаган һәр сәгатен гыйлем-фән юлына

сарыф итә, архивны яңадан җентекләп күздән кичерә, рәткә сала, дөньякүләм әһәмияткә ия тарихи хезмәтләрен язуын дәвам иттерә.

Бихисап чыганакларны чагыштырма планда өйрәнеп, Р. Фәхретдин үтә әһәмиятле «Болгар тарихы» дигән зур күләмле хезмәтен яза. Ләкин зур-зур ике кисәктән торган бу әсәрнең беренче кисәге ниндидер сәбәпләр аркасында вәйран була.

Р. Фәхретдиннең халык арасында абруе ифрат зур булуы күптән мәгълүм. Бу бигрәк тә революциягә кадәрге чорга карый. Бер генә мисал. Бөтен күренекле замандашларын да диярлек очлы сатира каләменә «элгән» җор сүзле, әче телле шагыйрь Ш. Бабич та аңа карата чәнечкеле сүзләр әйтергә базмый, киресенчә, олуглыгына мәдхия җырлый (1918):

Риза хәзрәт, сиңа әйтәм, син мөхтәрәм, дип әйтәм,
Бер җиреңне тешләр идем, ил ышанмас, дип әйтәм!

20 нче елларның урталарына таба Советлар илендә дини оешмалар, шул исәптән мөселманнарның Уфадагы Диния нәзарәте, руханилар нык кысрыклана, дингә мөнәсәбәте булган биналарны бушату турында күрсәтмәләр еш бирелә. Мәсәлән, Уфа губерна башкарма комитеты Диния нәзарәтенә нәзарәтнең үз бинасын, шулай ук аның күршесендәге нәзарәт архивы саклана торган бинаны кичекмәстән бушатырга боера. Бу фәрманга каршы Р. Фәхретдин 1925 елның 11 гыйнварында «Уфа шәһәрендә губернский исполнительный комитетка сайланган котлугъ татар егетләренә һәм, гомумән, бүген эш башында торучы иптәшкәләргә» ачык мәктүб (хат) белән чыга. Тирән әрнү хисе белән язылган һәм, «SOS!» игълан итеп, рухи һәлакәт куркынычыннан кисәткән бу тетрәндергеч хат, бәхеткә каршы, нәтиҗәсез калмый. Халык арасында югары абруен саклаган Риза казый, шул хатны язып, бик күп дәүләт оешмаларына мөрәҗәгать иткәннән соң, халкыбызның мәдәни тарихын өйрәнү өчен бәяләп бетергесез кыйммәтле чыганак — Диния нәзарәте архивын коткарып калуга ирешә.

Шул ук ел олуг галимгә беркадәр сөенеч тә бүләк итә. 1925 елның сентябрендә Р. Фәхретдин, СССР Фәннәр Академиясенең Президиумы чагыруы буенча, Фәннәр академиясенең 200 еллык юбилеенда мәшһүр шәркыятьче (востоковед) буларак иң хөрмәтле кунак сыйфатында катнаша. Риза казый 1926 елда Согуд Гарәбстанына, Мәк-

кәи-Мөкәррәмәгә Бөтендөнья мөселманнары конгрессына бара, анда аны конгрессның вице-президенты итеп сайлыйлар. Мөфти һәм галим конгресста гарәп телендә зур чыгыш ясый. Аны Согуд Гарәбстаны короле кабул итә.

Шулай да бар егәрен, сәламәтлеген, иҗади омтылышларын халкыбызның бай мәдәни мирасын өйрәнүгә, пропагандалауга багышлаган галимнәр галиме гомеренең соңгы елларында язмышның кырыс сынавына дучар ителә. Аннан матди мөмкинлекләре кысылганнан-кысыла баруына, гаиләсенең ишле булуына карамастан, салым өстенә салым түләтәләр, төрлечә басым ясыйлар, акчасыз, аш-сусыз утырырга мәҗбүр итәләр. Үзен һәм гаиләсен ач үлемнән саклап калу өчен ул «дөнья бәһасенә торырлык» китапларын бик арзан бәягә сатарга мәҗбүр була, шуның аркасында каты рухи газаплар кичерә.

Халыкара абруйга ия булган галимгә кульязма хезмәтләрен Вена Фәннәр академиясенә сатуын сорап берничә мәртәбә мөрәҗәгать итәләр. Ләкин тормыш хәленең аяныч булуына карамастан, Р. Фәхретдин бу юлга басмый, ватанының патриоты булып кала. Үзенең күп еллык иҗат җимешләренең бер өлешен генә булса да саклап калу өчен ул шәркыятьче галим, академик А. Н. Самойловичның үтенечен уңай кабул итә, кульязмаларының берничә томын СССР Фәннәр академиясенең Көнчыгышны өйрәнү институты Ленинград бүлеге архивына тапшыра. Алар бүген дә, Ризаэтдин Фәхретдиннең мирасы буларак, шунда сакланалар.

Энциклопедик белем иясе, XX йөз Әбүгалисинасы Риза казый 1936 елның 12 апрелендә 77 яшендә Уфа шәһәрендә вафат була һәм шундагы татар зиратына җирләнә. Аның кабер ташына «Әдип-мөәррих мөфти Ризаэтдин бине Фәхретдин. 1859—1936» дигән сүзләр уелган.

2

Ризаэтдин Фәхретдиннең тарих фәненә керткән ифрат зур өлеше турында сүз алып барганда, без беренче нәүбәттә аның күп томлы био-библиографик «Асар» («Эзләр») исемле хезмәтен, Идел Болгарстаны, Алтын Урда, Казан, Касыйм, Себер ханлыклары буенча язылган тарихи әсәрләрен һ. б. күздә тотабыз. Әйтергә кирәк, В. Н. Татищев, Н. М. Карамзин, П. И. Рычков, С. М. Соловьев, В. О. Ключевскийларның тарихи хез-

мәтләре урыс һәм көнчыгыш славян халыклары өчен нинди әһәмияткә ия булсалар, Р. Фәхретдиннең тарихи әсәрләре дә татар һәм башка төрки халыклар өчен шундый ук зур әһәмияткә ия. Галимнең атап кителгән хезмәтләрен күздән кичергәндә шундый үкенечле бер уй күңелне тырнап китә. Нигә соң Русия тарихы буенча күләмле әсәрләр иҗат иткән, алда исемнәре телгә алынган урыс галимнәренең күп томлы әсәрләре ничәмә-ничә тапкыр нәшер ителгән дә, Риза казыйның ифрат зур кыйммәткә ия хезмәтләре һаман да басылып чыкмый? Нигә без гали фикер иясенең мирасын шулай начар беләбез һәм саран пропагандалыйбыз?

Ниһаять, бу өлкәдә күзгә күренерлек гамәлләр кылына башлады. Шуларның иң мөһиме — Ризаэтдин Фәхретдиннең галим Әнвәр Хәйруллин әзерләп чыгарган «Болгар вә Казан төрекләре» китабы булды (Казан, Таткитнәшр., 1993). Ләкин Орынбур әүлиясының колач җитмәстәй зур мирасын барлау, тикшерү, киң катлау укучыларга җиткерү бүгенге көндә дә иң актуаль мәсьәләләрнең берсе булып кала.

Үзенең шушы «Болгар вә Казан төрекләре» дигән хезмәтендә Р. Фәхретдин татар, башкорт, башка төрки халыкларның гомер сөрүләрендә 5 дәвер билгели, ләкин «татар» атамасын «монгол» этнонимының синонимы итеп караганлыктан, ул казан татарларына карата да «төрекләр» дигән исем куллана. Хәлбуки, «Болгар вә Казан төрекләре» дигән төшенчә астында беренче нәүбәттә бүгенге татар халкының бабалары күздә тотыла. Әлеге 5 дәвер түбәндәгеләр: 1) мөстәкыйль хәлләрендә гомер сөрүләре; 2) татарлар хакимлеге астында калулары; 3) урыслар тарафыннан басып алынып, урыс җәбере һәм золымы астында яшәүләре; 4) урыс миссионерлары хакимлегенә дучар булулары, һәртөрле чирканыч чаралар белән чукындырылулары; 5) коммунистлар кул астында юкка чыгулары.

Әлеге дәверләрнең эчтәлеген ачып, галим «Нәсел-ырудыбыз вә кыскача тарихыбыз. Төрекләр. Фин вә сакълаб. Һун вә болгарлар», «Болгарларның мәмләкәтләре һәм хөкүмәтләре», «Болгарларның нәселләре вә телләре», «Болгарларның мәдәниятләре. Кәсеп вә һөнәрләре», «Болгарларның мәшһүр шәһәрләре», «Болгарларның хөкемдарлары вә ханнары», «Болгар төрекләренең дин вә мәзһәбләре», «Болгар төрекләренең татарлар белән урыслар кул астында калулары», «Миссионерларның хакимлек

итүләре. Урыс хөкүмәте тарафыннан мөселманнарның чукындырылуы» дигән бүлекләр бирә.

Туган халкы татарларны олуг һәм гомуми төрки гаиләнең бер өлеше дип караган Р. Фәхретдин «төрек милләтен» (төрки халыкларны) өч төркемгә бүлә: 1) төшлек төрекләре; 2) көнчыгыш төрекләре; 3) шималь (төньяк) төрекләре. Төшлек төрекләренә ул Анатолия һәм Урта Азиядә, Кырым һәм Кавказда, Иран һәм Төркиядә һәм шул урыннарның төшлек тарафларында, шулай ук Африканың кайбер урыннарында тормыш итүче кавемдәшләрен кертә. Көнчыгыш төрекләре дип Төркестан һәм Фирганә, Бохара һәм Хәрәзм, Кытай һәм Әфган, кыргыз һәм казакъ төрекләрен саный. Шималь төрекләре дип баштагы ике төркемгә кермәгәннәрен күрсәтә. Болар Себердә һәм Уралда, Идел, Дон һәм Җаек буйларында, шушы суларга коя торган дәрьяларның үзәннәрендә гомер сөрүче төрекләрдер, ди галим.

Милләтебезнең болгар тамырларына нисбәтен галим түбәндәге сүзләр белән аныклый: «Болгарлар (иске болгарлар, олуг болгарлар) — сөйләнгән өченче төркем төрекләренең ерак бабалары һәм дөрестән дә үзләредер. Бу көндәге Казан мөселманнары (ягъни татарлар.— Р. Ә.), мишәрләр, башкортлар, чуашлар, типтәрләрнең һәммәсе иске болгарлар һәм олуг болгарның үз балаларыдыр», ди.

Бу зур хезмәттә Идел Болгарстанының мәшһүр шәһәрләре Суар, Җүкәтау, Саксин, Биләр шәһәрләренә кыскача характеристика бирелә. Болгар шәһәре исә тәфсилләрәк итеп сурәтләнә, аның кыскача тарихы, шанлы дәверләре бәян ителә. «Болгарларның хөкемдарлары һәм ханнары» дигән фасылда Риза казый Сәлкидән һәм Исламны 922 елда рәсми төстә кабул иткән Алмас (Алмуш) ханнан башлап (Сәлки аның атасы) 1438 елда Сарайдан килгән Олуг Мөхәммәд, династияләр алмашу, 1552 елда Казанны алганчыга кадәр хөкем сөргән ханнарның эшчәнлеген кыскача тасвирлап чыга, Казан ханлыгының эчке һәм халыкара хәле буенча мәгълүмат биреп китә.

Хезмәтнең «Болгар төрекләренең татарлар белән урыслар кул астында калулары» дигән фасылы «шималь төрекләрен» Чыңгыз-Бату далачыларына каршы куюга нигезләнгән. Р. Фәхретдин ачы ирония белән Онон-Керулен тарафларыннан килгән яугирләрнең «казанышларын» болай билгели: «Монголларның бу мәмләкәтне төзекләндерергә һәм юлга кергән мәдәниятне үстерергә

һәм дәвам иттерергә, һөнәр һәм һөнәрчелекне алга җибәрергә кулларыннан килмәсә дә, чабаталы урысларны итекле ясарга, кечкенә генә булган славян кавеменең ярты дөньяны йота алырлык бер хәлгә күтәрелүенә хезмәтләре зур булды» (сирәкләү безнеке.— *Р. Ә.*). Бу бүлектә кыскача гына Казан алыну фаҗигасе, татар халкының 1552—1557 еллардагы Ватан сугышы тасвирлана, урыс колонизациясенең имәнеч гарасат икәненә басым ясала. Әлеге уңайдан Риза казый илбасарларның вәхшилеген менә ничек тасвирлый: «Урыслар болгар каберлекләрендәге язулы ташларны гына да сәламәт калдырмадылар. Башка нәрсәләрне әйтеп торасы да юк...»

Дүртенче дәвернең эчтәлеген мөселманнарны көчләп чукындыру, урыслаштыру, төрле ысуллар белән изүгә кагылышлы материаллар тәшкил итә. Баскыннарның бетмәс-төкәнмәс чирканыч җинаятьләрен тасвирлаудан гаҗиз калып, тирән сызлану һәм тетрәнү белән Р. Фәхретдин үзенә мәгълүм ике дистә фактны җепкә тезә. Чукындыру, урыслаштыруның колачын нәтиҗәлерәк итеп күзаллау өчен галимнең бер җөмләсенә игътибар итик. «Бу көндәге урысларның ерак әбиләре һәм бабалары мөселман булмаганы бик сирәк һәм аз табылыр»,— ди ул.

Бишенче дәверне, ягъни «коммунистлар кул астындагы» чорны тасвирлауга Риза казый нибары 9 юл сарыф иткән. Канлы диктатура балтасының мазлум муеннар өстендә инде шактый йөгерек уйный башлавын сурәтләү галимгә зур рухи газаплар аркылы бирелгәне күренеп тора. «Бу дәвер хакында язарга түгел, хәтта күңел белән фикерләүгә дә мөмкинлек юк. Алла насыйп итсә, җәннәткә кергәнебездән соң язарбыз. Анда кәгазь мул булыр, яхшы каралар, күңелгә ошаган каләмнәр табылыр. Яктылык җитәрлек булыр, караңгыда утырырга, налог түләү өчен иң кирәк әйберләрне сатуга мәҗбүрлек булмас. Алла теләсә, ЧК һәм ГПУ хөкемнәре дә йөрмәс... Шуның өчен моннан соң башка нәрсәләр хакында язачакбыз. Әсәрнең беренче бүлеме бетте, икенче бүлемгә керәчәкбез».

Күргәнебезчә, Р. Фәхретдин милли тарихны бу дәверләргә бүлгәндә Сталин җәһәннәме капусының киң ачыла башлаган чоры була.

Галимнең тарихи эзләнүләр циклын татар һәм башка төрки халыкларның үткәненә мөһим караш ташлаган «Ибне Фазланның тәрҗемәи хәле вә сәяхәтнамәсе» бай-

так тулыландыра. Мажаралы кыйсса сыман йотлыгып укыла торган бу әсәр Хәрәзм мәмләкәте, Гузия халкы (гузлар), пәчәнәкләр, башкорт кавеме, урыс халкы, хәзәрләр, болгарлар хакында кызыклы мәгълүматлар бирә, безне моннан мең еллар элек булып үткән хәлләр, гореф-гадәтләр, йолалар, идарә эшләре белән таныштыра, зиһенебезне гыйбрәтле төшенчәләр белән баета.

Бабаларыбызның борынгы тарихына караган шул ук рухтагы хәбәрләр «Ибне Баттутаның тәрҗемәи хәле», «Ибне Баттутаның Дәште Кыпчакка сәяхәте» дигән язмаларның да эргәсен тәшкил итә. Әйтик, бүген Синдбадның 8 сәяхәтен һәр мәктәп баласы яхшы белә. Ләкин аларның барысы да әкият, миф, ялтыравык ялган. Ә менә ибне Баттутаның Дәште Кыпчакка сәяхәте әкиятне хәтерләтсә дә, ул бөтенләе белән чынбарлык җимеше. Аның «Кырым вилаятенә сәфәр», «Дәште Кыпчакта арбалар», «Кырымнан сәфәр», «Төрекләрдә хатыннарның дәрәҗәсе», «Биш Тауга сәфәр», «Мөхәммәд Үзбәк хан», «Мөхәммәд Үзбәк хан хатыннары», «Мөхәммәд Үзбәк ханның хатыннары вә балалары», «Болгар шәһәренә сәфәр», «Гаед намазы уку», «Хаҗитархан шәһәре», «Кастантиния сәфәре», «Хаҗитархан шәһәренә кайту», «Сарай шәһәре», «Сарайдан Хәрәзмгә» дигән хикәятләре бер сулыш белән укыла торган кыйссалар бәйләмен тәшкил итә.

Сәяхәтләр тезмәсенең бер дәвамы сыман булган «Рихләтел-Мәрҗани», ягъни «Мәрҗани сәяхәте» дә Р. Фәхретдиннең тарихи хезмәтләренә аваздаш. Биредә без Ш. Мәрҗанигә ияреп, Истанбулга, Измирга, Искәндәриягә, Мисыр әл-Каһирәгә, Суәеш-Исмәгыйлиягә, Янбәгъка, Мәдинәи-Мөнәүвәрәгә, Мәккәи-Мөкәррәмәгә сәяхәт кылабыз, Ислам бишегенең халәте, торышы, мәдәнияте белән якыннан танышабыз.

3

Ризаэтдин Фәхретдингә тарихчы буларак бәя биргәндә, безнең карашыбызча, аның «Шура» журналындагы эшчәнлегенә аерым тукталып китү зарур. Галимнең журнал битләрендәге фәнни хезмәтен чын мәгънәсендә каһарманлык дип атарга мөмкин. Аның кулъязма хәлендәге бик күп хезмәтләренең хәзергәчә өйрәнелмәвен һәм басылып чыкмавын искә алсак, «Шура»да дөнья күргән кыйммәтле тарихи материалларның бәһасе бермә-бер күтәрелер.

Журнал тәүге адымнарыннан ук «Мәшһүр адәмнәр вә бөек хадисәләр» (хадисә — вакыйга.— *Р. Ә.*) дигән даими рубрика белән ачыла һәм нигездә милли тарихыбызның иң әһәмиятле моментларын чагылдыра. Аның беренче санында (1908, гыйнвар) Р. Фәхретдиннең Ислам динен 922 елда рәсми төстә кабул иткән Болгар хөкемдары Алмуш турында «Җәгъфәр бине Габдулла (Алмас бине Сәлки)» исемле күләмле мәкаләсе басыла. Беренче җөмләсендә үк галим татар халкының килеп чыгышына (этногенезына) карата ачык мөнәсәбәтен белдерә. Бернинди икеләнүләргә урын калдырмыйча, ул болгарларны туган халкының бабалары дип игълан итә.

Шулай да Р. Фәхретдиннең татар халкы этник тарихын бер болгар тамырларына гына кайтарып калдыруы белән килешеп булмый. Татарның кавем (народность) һәм милләт буларак калыплануында болгар компоненты хәлиткеч рольләрнең берсен уйнаган булса да, бу процессны гомумтөрки җирлектән аерып карау тарихи дөреслеккә туры килми. Академик М. З. Зәкиев сүзләре белән әйткәндә, «башка халыклар кебек үк, татар да күп төрки һәм төркиләшкән кабиләләрдән оешкан, төрле чорларда төрле кабиләләр өстенлек алганлыктан, хәзер татар дип атала торган халык төрле чорда төрле этнонимнар белән аталган, дәүләте дә шул этнонимны йөрткән»[1]. Татарның болгар этнонимына гына бәйле булмавын раслаучы дәлилләр арасында иң саллысы — аның дүрт дәүләте: Биарм иле, Идел Болгарстаны, Алтын Урда һәм Казан ханлыгы исемле мәмләкәтләре яшәп килү факты булып тора. Татар этносы эзләрен төрки телгә таянып тикшерү безнең төрки бабаларыбызның Идел-Урал төбәгенә өч мең елдан элегрәк килүен күрсәтә. Биредәге скиф-сарматлар да, бортас-сөннәр дә, хәзәрләр дә, болгарлар да гадәти төрки телле булганнар[2]. Соңгырак чорларда татар кавеме формалашуга кыпчак, угыз элементларының да зур өлеш кертүе мәгълүм.

Хәзер инде Р. Фәхретдиннең тарихка фән буларак мөнәсәбәтен ачыклап китик. «Шура» журналының бер санында мондый җөмләгә юлыгасың (теле, алдагы шундый өземтәләрнеке кебек үк, җиңелләштерелеп бирелә): «Тарих гыйлеме милләтләрнең тормышларыннан һәм ба-

---

[1] Мирас, 1994, № 1, 59 б.
[2] Мирас, 1994, № 1, 58 б.

سنه ٣ عدد ١٦

٢٣ شعبان سنه ١٣٢٨ ١٥ آوغوست ١٩١٠ سنه

مشهور آدملر والوغ حادثه‌لر

احمد خان

بوندن بيك بيللر مقدم بر زمانده، اسلام دنيا سنده باشلاب نظاملى و ترتيبلى بر مدرسه تأسيس ايتمش نظام الملك ترجمه‌سى، اونكان عدد ده يازلمش ايدى. اوشبو مناسبت ايله بو عصرمزده هم اسلام دنياسنده ترتيبلى و ملى بر الوغ مدرسه تأسيس ايدوچى بر كيمسه‌نك ترجمه‌سينى يازمقنى موافق كوردك. بو آدم ايسه هندستانده احمد خان جنابلريدر.

احمد خان، هندستانده حكومت سورمش وآوروپا حكومتلرندن كورمكچى اوزلرينه «ايمپراطور» لقبنى ويرمش اولان مغول حكومت اسلاميه‌سنده الوغ منصبلرده خدمت ايدوب كلمش زور توره‌لر نسلندن ايدى. مغول حكمدارلرى ايسه آقساق تيمر بالالرندن اولان بابرشاه نسلندن اولوب آرالرنده حقيقت حالده ايمپراطورلق لقبنه مستحق پادشاهلر وار ايدى. فقط خلفلرنك تدبيرسزلكلرى، علم و هنرگه هوس ايتماديكلرى سببندن الوغ پيتر وقتنده اولان روسيه مملكتى قدر اولان مملكتلرينى ضايع ايتديلر. بتون دولتلرى، بايلقلرى، سلطنت و شهرتلرى انگليزلرگه ميراث اولدى، بو كونده ايسه مغول ايمپراطورلغى اورننده انگلتره ايمپراطورلغى حكومت سورمكده در.

مغول حكومتلرى كوب وقت تركلر طرفندن اداره اولنوب طورديغى معلومدر. اوشبو سببدن احمد خان بابالرى ترك نسلندن اوله‌چقى آڭلاشلور.

احمد خاننك آناسى منصب صاحبى اولوب ده صوڭره‌دن دنيادن اعتزال ايتمش وعبادت ايله مشغول اولمش محمد نقى اسمنده بر ذات ايدى. آناسى خواجه فريدالدين احمد اسمنده سياسى وفاضل بر آدم قزيدر.

انگليزلر هندستاننك يورتلرينى ضبط ايدوب بتردكلرندن مملكتننك اورتالغينه و يورا گينه كلورگه باشلاديلر ومغول ايمپراطورلرينى طفيلارغه كرشديلر. حتى ايكنچى اكبرشاه (ولادتى ١١٧٣ — ١٧٥٩ ده، تخت كه چيقمقى ١٢٢٢ — ١٨٠٦ ده، وفاتى ١٢٥٣— ١٨٣٧ ده ايدى) زماننده، مغول ايمپراطورلغى يالڭز تختگاه اولان «دهلى» شهرندن عبارت اولوب قالمشيدى. ايشته اوشبو وقت اكبرشاه، احمد خان آناسى اولان محمد نقى نى اوزينه وزيرلك ايچون چاقردى. فقط محمد نقى بو طوغروده اعتذار قيلوب اوشبو خدمتنى قيلور ايچون اوزينك قائن آناسى خواجه فريدالدين مناسب اوله‌چقنى بيان قيلدى. خواجه فريدالدين اوشبو وقتده «قالقوتا» شهرنده طورر ايدى.

اكبرشاه، محمد نقى مشورتنى قبول كوروب خواجه فريدالدين نى «دهلى» گه كتوروب «مدبر

Ризаэтдин Фәхретдин мөхәррирлегендә чыккан «Шура» журналының (1908—1917) «Мәшһүр адәмнәр вә бөек хәдисәләр» бүлеге. Казан ханнары хакындагы язмалар шунда басылып килгән.

рлык кешеләрнең тереклек итүләреннән бәхәс итүче бер фән булса да, безнең иске Ислам тарихларыбызның әһәмият биргән нәрсәләре тадж өчен булган сугышлар, башкалаларда булган мәшһүр маҗаралар бөтенләе белән хөкүмәтләргә кагылышлы нәрсәләрдән торып, милләт ихтыяҗлары вә халыкның хәл-әхвәле күбесенчә әйтелмәгән килеш калган» (1909, № 19, 578 б.). Әйе, бу бик принципиаль һәм әһәмиятле момент.

Р. Фәхретдин тарих фәнендә тәхет өчен көрәш, сарай маҗаралары түгел, ә халык тормышы һәм яшәеше тасвирланырга тиеш дигән карашына үзе турылыклы булып калганмы соң? «Шура» журналы материалларына карагaнда, 1908—1909 елларда галим халыклар тарихын династияләр алмашуы аркылы тасвирлаудан котыла алмаган әле. Мәсәлән, галим «Бәркә хан», «Үзбәк хан», «Җанибәк хан», «Мамай», «Туктамыш хан», «Идегәй мирза», «Әхмәд хан» кебек дистәләгән материаллар бастыра. Әмма моңа һич тә гаҗәпләнеп булмый. Урыс тарихчылары Татищев, Карамзин, Соловьев, Платонов һәм башка бик күпләр шулай ук династия принцибыннан чыгып эш иткәннәр, Русия тарихын теге яки бу идарәченең (кенәз, патша, император һ. б.) алмашуына бәйләп яктырткaннар. Хәер, ул заманда рәсми тарих фәненә төрле баскычтагы дәреслекләргә, чорларга бүлүнең династиячел принцибы хас булган. Шуның өстенә «Шура» идарәсенең цензура властьларына белдергән программасында мәмләкәт һәм халык тарихын эзлекле тасвирлау түгел, бәлки мәшһүр шәхесләрнең тормышын һәм аеруча истәлекле вакыйгаларны гына сурәтләү күздә тотылган. Программадан читкә тайпылу җитди низагълар белән бәйләнгән була. Журнал идарәсенә еш кына зур штрафлар түләргә туры килүе дә мәгълүм.

Ләкин шуңа да карамастан, Р. Фәхретдин инде 1912 елда ук, милли тарихны билгеле бер системага салып, концептуаль планда чишәргә омтылыш ясый. Моның мисалы итеп аның «Шура» журналында 1912 елда Идел Болгарстаны турындагы мәкаләләрен күрсәтергә мөмкин: «Шимали (төньяк) Болгар дәүләте», «Болгарларның хөкүмәт вә диннәре», «Болгарларның нәсел вә лисаннары (телләре), асар һәм шәһәрләре», «Болгарларның пайтәхетләре (башкалалары) улан Болгар шәһәре». Гомеренең азагына кадәр тарихи проблемалар белән шөгыльләнгән Риза казый үзенең бу өлкәдәге мәгълүматын, карашын даими рәвештә үстергән, камилләштергән һәм 20—30

нчы елларда мәсьәләне заман таләпләренә җавап бирерлек дәрәҗәдә хәл итәргә омтылган булса кирәк. Алда сүз барган «Болгар вә Казан төрекләре» исемле хезмәт һәм анда күрсәтелгән 5 тарихи дәвер күпмедер дәрәҗәдә шул турыда сөйли. Бу әсәрендә Р. Фәхретдин тарихны династияләр принцибы нигезендә өйрәнүдән тулысынча диярлек ваз кичә һәм кешелек җәмгыяте үсешенең гомуми кануннарына таянып эш итә. Әлбәттә, галимнең үз халкы тарихын нәкъ шушы чорларга бүлүе белән бәхәсләшергә мөмкин, әмма аның мәсьәләгә әүвәлге карашы белән чагыштырганда бу инде, һичшиксез, алга китеш.

Р. Фәхретдиннең олуг тарихчы икәнен аның ифрат бай чыганаклар җирлегендә эшләве ачык күрсәтә. Галимгә тарихи хезмәтләр язганда төрле чор һәм төрле характердагы чыганакларның бөтен бер комплексын җәлеп итү хас. Аның әсәрләренең аеруча кыйммәтле ягы шунда ки, ул берьяклылыкка бирелмичә, көнчыгыш кына түгел, бәлки көнбатыш, Русия галимнәренең хезмәтләренә дә киң таянып эш итә. Мәсәлән, Идел Болгарстаны тарихын язганда гына да галим Әбү әл-Фараҗ әс-Сәбгани, Җаһиз, Якут Хәмәви, Ибне Фазлан, Мәсгуди, Әбү Исхак Истахри, Мөхәммәд ибне Җәррир әт-Тәбри, Ибн әл-Әсир, Әбел-Фида, Ибне Халдун, Әл-Фәхри, Ибне Баттута, Х. Фәезхан, Ш. Мәрҗани хезмәтләрен киң җәлеп итә, В. В. Григорьев, Х. М. Френ һәм башка урыс галимнәренең фикерләреннән файдалана.

Чыңгыз хан мәмләкәте, Дәште Кыпчак, ягъни Алтын Урда турындагы хезмәтләрендә Р. Фәхретдин Әбел-Гази, Ибн әл-Әсир, әл-Кәмаль, Морад Рәмзи, Ибн әл-Урди, Әбел-Фида, Сәми бәк, Ибне Гарәпшаһ әсәрләреннән киң файдалана һәм шул ук вакытта Карамзин, Соловьев, Брокгауз һәм Ефрон хезмәтләренә таяна, бертуган А. һәм И. Гранат Энциклопедик сүзлегенә мөрәҗәгать итә. Тарихны чагыштырма планда шулай өйрәнү галимгә проблемаларны мөмкин кадәр объектив куярга һәм чишәргә, теге яки бу вакыйганы кискен тайпылышларсыз бәяләргә мөмкинлек бирә.

Казан ханлыгы тарихына килгәндә исә, Р. Фәхретдин башлыча урыс галимнәренең (Рычков, Карамзин, Соловьев) хезмәтләренә таяна, өлешчә К. Ф. Фукска, А. һәм И. Гранат Энциклопедиясенә мөрәҗәгать итә. Көнчыгыш чыганакларыннан Ш. Мәрҗанинең «Мөстәфадел-әхбар»ыннан киң файдалана. Сафа Гәрәй хан белән бәйләнешле вакыйгаларны тасвирлаганда автор үзенең

Карамзин һәм Рычков хезмәтләреннән зур-зур өземтәләр алуын таный. Касыйм ханлыгы тарихы да, күрәсең, нигездә урыс чыганакларына таянып язылгандыр. Бу бүлектә бер генә хезмәткә дә сылтамалар очрамый, әмма Р. Фәхретдиннең үз искәрмә-аңлатмалары бихисап. Аерым очракларда галим чыганакларга һәм авторларга булган шөбһәсен ачыктан-ачык белдереп, моны фәлән тарихчы шулай дип яза, дөресен исә бер Аллаһу Тәгалә үзе белә, дип искәрткәләп куя.

Риза казыйның Себер ханлыгы буенча да хезмәт иҗат иткәне билгеле. Бу турыда ул академик А. Н. Самойловичка 1935 елның 5 февралендә язган хатында искә ала. Әлеге хезмәт белән танышырга мөмкин булмаганлыктан, аның нинди чыганакларга таянып язылуы турында сүз әйтүе кыен.

Җитди тарихчы буларак, Р. Фәхретдин, Шәрекънеке яисә Европаныкы булуына карамастан, чыганакларга тәнкыйди мөнәсәбәтнең югары үрнәген бирә. Мондый мөнәсәбәт абруйлы тарихчылар Рычков, Карамзин, Соловьев хезмәтләрен анализлаганда ачык сиземләнә. Рухи мәдәниятнең һәр өлкәсендә үз кыйбласы, инануы булган Р. Фәхретдин теге яки бу авторның дәлилләренә сукырларча иярүче, аның карашларына мөкиббән китеп табынучы шәхес түгел. Ул теге яки бу фактны кат-кат тикшергәннән, бихисап каршылыклы чыганакларны чагыштырып өйрәнгәннең соңында гына тиешле бер нәтиҗә чыгара, аңа үз бәясен бирә. Бу җәһәттән караганда галим тарихта абруйлы «Фәхретдин мәктәбе»нә нигез салучы бер шәхес буларак гәүдәләнә.

Тарих фәнендә чыганакларга тәнкыйди караш бик җитди мәсьәлә булганлыктан, без монда Р. Фәхретдиннең «Шура»да басылган хезмәтләреннән берничә мисал китерәбез.

Галим монголларның 1223 елда Калка елгасы буенда берләштерелгән урыс-кыпчак чирүен җиңгәннән соң, Идел буе болгарларына һөҗүм итүе хакында Карамзинның әйтми калдыруына ризасызлыгын белдерә. Һәм Ибн әл-Әсир хезмәтеннән монголларның болгарлар тарафыннан тәмам тар-мар ителүе һәм барлыгы 4 мең сугышчысы гына исән калуы турында мәгълүмат китерә (Шура, 1909, № 4, 99 б.) Р. Фәхретдин фикеренчә, Карамзин Калкадагы бәрелешнең нәтиҗәсен бозып күрсәтә, хакыйкатькә каршы килеп, башта яу кырын кыпчак полклары ташлап качты, дип раслый. Һәм моның өчен авторны

каты шелтәли. Аннары: «Монда Карамзин гаепле түгел, чөнки аңа шулай дип язарга боерылган», дигән искәрмә бирә. Галим Карамзинның Алтын Урда ханы Тәктага (1312 елда вафат) мәҗүси булган һәм Исламны кабул итмәгән дигән фикере белән дә килешми: «Карамзин никадәр төрек һәм мөселман канынннан булган бер христиан булса да, христианлыгында бик нык вә тарихны хөкүмәт өйрәтүе буенча язганлыктан, бу сүзләргә гаҗәпләнер урын юк»,— ди. Тарихчы Карамзинның түбәндәге белдерүен дә катгый төстә кире кага. Урыс галименең язуынча, 1318 елда Мәскәү кенәзе Георгий Үзбәк ханның сеңелесе Көнчакка өйләнә һәм, яшь бикә чукындырылып, исеме Агафьяга үзгәртелгән, имеш. Риза казый бу гамәлнең «кан чисталыгы» мәсьәләсендә бик тәкъва булган Чыңгыз нәселенең принципларына һич туры килмәвен күрсәтә һәм, үз фикерен куәтләү өчен Ибне Халдунга мөрәҗәгать итә.

Р. Фәхретдин С. М. Соловьев белән дә бәхәскә керә. Аерым алганда, сүз Әхмәд хан гаскәренең 1480 елда Угра елгасыннан кире кайтып китүе турында бара. Әгәр Соловьев бу чигенүне кышның бик салкын булуы, хан союзнигы Казимирның килмәве, Әхмәд ханның урысларның чигенүен хәйлә генә дип уйлавы, Иван III нең үзенә дошман булган кардәшләре белән солых төзүе һәм шул сәбәпле Мәскәүнең көч туплавы белән аңлатса, Риза казый моны Иван III нең союзнигы Нур Дәүләтнең Алтын Урдага кинәттән һөҗүм итү куркынычы белән бәйли. Урыс тарихчылары Рычков белән Соловьевның кенәз Василий II һәм Олуг Мөхәммәд гаскәрләре арасында 1437 елда булган бәрелешне, аның карашынча, бозып күрсәтүенә дә Р. Фәхретдин кискен каршы төшә. Сүз ханның I мең чамасындагы отрядының 40 меңлек кенәз гаскәрен «тәмам кырып вә үтереп» бетерүе хакында бара: «Рычков шундый хорафат бер нәрсәне риваять кыла ки, хәтта кире кагу өчен дә монда китерү мөмкин түгел. Дөньяда фанатизмның мондый дәрәҗәгә җитүен адәм баласы хәтта хыялына да китерә алмас» (Шура, 1908, № 10, 300 б.).

Галим урыс тарихчыларын Казан ханнарының, аерым алганда, Сафа Гәрәйнең Мәскәү кенәзлегенә карата тоткан сәясәтен объектив итеп күрсәтмәүдә гаепли һәм аларның хезмәтләренә шикләнеп карарга чакыра (1908, № 16, 489 б.). Р. Фәхретдин шулай ук Карамзинның Чапкын һәм Бурнаш мирзаларның 1552 елның мартында казан-

лыларны гүяки Мәскәү чирүен шәһәргә кертмәскә һәм соңгы сулышка кадәр сугышырга өндәгәннәр дигән сүзләрен китерә. Карамзин, бу вакыйга турында казанлыларның үзләренең риваятьләре бөтенләй икенче, әмма мин бары тик урыс тарихчыларыныкын гына китердем, дип яза. Шул сәбәпле Р. Фәхретдин, Карамзинны берьяклылыкта гаепләп, болай дип белдерә: «Әгәр дә ул казанлылар хәбәрен искәрмә рәвешендә генә булса да язса иде, фанатик булмаган тарихчы икәнен күрсәткән булыр иде. Ләкин мондый нәрсә иске заман урыс тарихчылары өчен мөмкин булмады. Алар гыйлемнән бигрәк сәясәткә хезмәт күрсәттеләр һәм шул җәһәттән тарихны күп җирдә харап иттеләр» (1908, № 24, 745 б.). Бу сүзләр халкыбыз тарихын фәкать урыс чыганаклары җирлегендә генә өйрәнүче кайбер бүгенге көн галимнәребезгә дә кисәтү булыбрак яңгырый.

Р. Фәхретдин урыс тарихчыларының Казан ханлыгы белән Мәскәү кенәзлеге арасындагы мөнәсәбәтләрне, Казанны алу вакыйгаларын тасвирлауларының байтагын кире кага, ул хезмәтләрнең нигезен мәгълүм бер калыпта фикер йөртүче монахлар елъязмалары тәшкил итә, дип белдерә. Бу җәһәттән галим тулысынча «дөньяви» шәхесне — Казанны алуда турыдан-туры катнашкан кенәз А. Курбскийны да аямый. Чөнки бу гаскәр башлыгының язуына караганда, 1552 елның сентябрь көннәрендә казанлылар көн саен таң вакытында крепость диварларына менеп кычкыралар, яулык һәм киемнәре белән урыс чирүләренә ишарәт итеп, яңгыр болытлары чакыралар да, янәсе, шунда камаучылар өстенә ишелеп яңгыр ява башлый. Бу зәхмәттән гаҗиз калган урыс гаскәрләренә яннарында булган хачлары-тәреләре генә ярдәм итми, алар Мәскәүдән Мөдһиш Иванның (Иван Грозный) үз тәресен китерткәч кенә казанлыларның сихереннән котылалар, имеш. Әмма урыс тарихчыларының күп кенә фикерләрен каты тәнкыйтьләсә дә, Р. Фәхретдин, гомумән алганда, төп әсәрләренә уңай күзлектән карый, үзенең хезмәтләрендә аларга еш мөрәҗәгать итә.

4

Ризаэтдин Фәхретдиннең фәнни эзләнүләрендә төп мәсьәләләрнең берсе — «төрек» яисә «болгар төрекләре» тарихы. Ул үзен бу кавемнең токымы дип саный һәм шуның белән горурлана. Милләте буенча саф Казан татары бу-

луына карамастан, ул бу атаманы (татар) тарихи күзлектән карап кире кага, аны «монгол» төшенчәсенә тәңгәл китереп карый, XIX—XX йөз чынбарлыгын һәрвакытта да кабул итеп бетерә алмый. Шуңа күрә галим Чыңгыз ханга мөнәсәбәтле «татар» сүзе белән бәйләнгән һәр нәрсәгә диярлек кире мөнәсәбәттә тора. 1916 елда «Шура» журналында Коканд шәһәрендә яшәгән нindидер Әһлиулла Хәйруллинның Риза казый исеменә язылган ачык хаты басыла. Автор Р. Фәхретдинне «татарлыкка» чамадан тыш һөҗүм итүдә гаепли һәм бу мәсьәләдә аңлатма бирүен таләп итә. Ләкин бу хакта күләмле мәкалә бирә алырлык тарихчы ниндидер сәбәпләр аркасында (сугыш вакыты!) бәхәскә кермәүне мәгъкуль күрә. Җавап хатында: «Бәхәсләрегезгә һәм шөбһәләрегезгә җавап бирергә хәзерге вакытта мөмкинлек юк. Гарәпләрдә «солых вакытындагы сүзләр белән сугыш вакытындагы сүзләр бер булмый» мәгънәсендә бер мәкаль бар», ди.

Мәгълүм ки, ул чорларда «Шура» журналы битләрендә бик кызу «тел ярышы» бәхәсе бара. Бер як «татар», икенче тараф «төрек» атамасын яклап, милләтнең этнос һәм этнонимына, телне-милләтне ничек дип атау мәсьәләләренә кагылышлы дистәләгән мәкаләләр белән чыгыш ясый. Аеруча зур дискуссия «Татар угылы» һәм «Төрек угылы» псевдонимы белән язган авторлар арасында куерып китә, хәтта җитди бәрелеш төсен ала. Бу имзаларның ияләре, җәмәгатьчелек тарафыннан нык таләп ителсә дә, редакция тарафыннан ачылмый. Күп кенә зыялылар «Төрек угылы» псевдонимы артында журналның баш мөхәррире Риза казый үзе тора булса кирәк, дип фараз кылалар. Югарыда телгә алынган хатта Р. Фәхретдин, «Төрек угылы»н шәхсән белгәнлеген күрсәтеп, аны идарәдән читтә торучы кеше дип аңлата һәм үзенең бу имзага мөнәсәбәте юклыгын искәртә. Әмма Р. Фәхретдиннең «татар» һәм «төрек» атамаларына мөнәсәбәтен күрсәткән мәкаләләрен тәфсилләп күздән кичерсәк, теге фаразның дөреслектән бик үк ерак тормавы ачыклана. Безнеңчә, «Төрек угылы» имзасы артында Р. Фәхретдиннең үзе тору ихтималы шактый зур.

Галимнең туган як тарихының 2 нче дәверен «Болгар төрекләренең татарлар кул астында калулары» дип билгеләвен әйтеп үткән идек инде. Димәк, моннан чыңгызый монголларның болгарлар белән бернинди дә уртаклыгы юк дигән нәтиҗә үзеннән-үзе килеп чыга. Риза Фәхретдин өчен Идел Болгарстаны («Шимали Болгар»)

хәзерге татарлар белән башкортларның бабалары тарихи тәрәкъкый иткән нигез. Галим үзен барлык тарихи хезмәтләрендә дә «болгарлар — безнең борынгы бабаларыбыз» дигән фикерне алга сөрсә дә, XX гасыр башы шартларында үзенең милләтен анык күрсәтми. Ул үзен «татар» дип тә, «төрек» дип тә, «башкорт» дип тә белдерми, бәлки борынгы бабаларын «болгар төрекләре» дип атау белән чикләнә. Әмма аның теле «Тәрҗеман»га яисә Йосыф Акчура стиленә хас гомумтөрки тел түгел. Ә инде башкорт теле турында сүз дә була алмый. Галим үзенең әсәрләрен шул чорның рәсми фәнни-әдәби теле — гарәп-фарсы тәгъбирләре белән «баетылган» татар телендә иҗат итә. Р. Фәхретдиннең теле саф татар теле, ул барлык тарихи хезмәтләрен дә үзенең ана телендә иҗат иткән.

Инде Болгар дәүләте тарихына килсәк, галим биредә VII гасыр вакыйгаларына ук мөрәҗәгать итә. Ул 1 мең чамасы болгар сугышчысының 631 елда (!) үз гаиләләре белән хәзерге Франциягә кадәр барып җитүен һәм шунда, җирле кабиләләр белән кушылып, «эреп» бетүен риваять итә. Ул Болгарда булган җитди бер низагъны 907 ел белән билгели. Шуның нәтиҗәсендә, ди галим, болгарларның зур гына өлеше хәзерге Венгриягә күчеп китә һәм шунда «Мажарстан» дип аталган дәүләт төзи. Р. Фәхретдин күрсәткәнчә, Венгриягә күчеп киткән болгарларның башында Алмас (Алмуш)ның улы Арпад торган, һәм ул яңа урында хан дип игълан ителгән. Болгар хөкемдарының Ислам дине кабул итү турында габбасиларга мөрәҗәгать итүен галим килеп туган сәяси ситуация белән аңлата, чөнки, ди ул, болгарлар хәлифәнең ярдәменә мохтаҗ булалар. Әмма шул ук вакытта Р. Фәхретдин бу мәсьәләдә икеләнүен дә белдерә: «Болгарларның Исламны кабул итүләренә нәрсәләр сәбәп булуы хакында мәгълүматыбыз юк». Аның фикеренчә, моның бер сәбәбе «Багдадта хәлифәләр тирәсендә йөрүче һәм зур дәүләт хезмәтендә торучы төрекләрнең бу мәсьәләдә тырышлыклары булгандыр» (Шура, 1912, № 19, 591 б.).

Шул ук вакытта тарихчы, 922 елда рәсми төстә Ислам кабул иткәнче үк, болгарлар арасында мөселманнар булуын күрсәтә, һәм хәлифә илчелеге Болгарга килгән чор-

да шәһре Болгардагы мәчетләрдә намаз укылуы турында хәбәр иткән Ибне Фазланны үрнәк итеп күрсәтә.

Галим «болгар» атамасын «болгану» сүзенә нисбәт итә һәм биредә һуннарның, җирле фин кабиләләренең һәм төркиләрнең кушылу-катышуын күз алдында тота. Төрки кабиләләрне атау өчен гарәпләр кулланган «сәкъ-лаб» сүзен Р. Фәхретдин төрки нигездәге «саклап» («сак-лаб»)ка кайтарып калдыра, ә һуннарның легендар башлыгы Аттиланың исемен Әтил (Идел) елгасы атамасы белән бәйли. Галим Болгар дәүләтенең бөеклеге һәм шәүкәте турында яза һәм, үзенең фикерен куәтләү йөзеннән, урыс императорларының башка күп титуллар белән беррәттән бүгенгәчә «князь Болгарский» титулын да йөртүләрен күрсәтә.

Р. Фәхретдин Идел Болгарстанының иң куәтле һәм чәчәк аткан чорын гына түгел, бәлки XX йөз башындагы халәтен дә тикшерә, шәһре Болгарның хәрабәләрен җентекләп тасвирлый, аларның киләчәк буыннар өчен тарихи, матди һәм рухи һәйкәл буларак ифрат зур әһәмиятен билгели. Галим Болгар һәм Казан дәүләтләренең матди һәм рухи яктан эзлеклелеген һәрвакыт күрсәтеп килә. Менә аның бер фикере: «Болгар дәүләте төзелде, дөньяда азмы-күпме яшәде, соңыннан хәяты киселде, вафат итте, бетте. Ләкин хөкүмәте бетсә дә, шул хөкүмәтне тәшкил итүче халыклар бетмәде, болар һаман да сәламәтләр. Болгар төрекләре бу көндә Казан, Самар, Уфа, Орынбур, Вятка, Сарытау вә Әстерхан вилаятьләрендә яшиләр» (Шура, 1912, № 22, 681 б.). Р. Фәхретдин раслаганча, болгар төрекләренең өч башкаласы була: беренчесе — хәзер хәрабә хәлендә ятучы шәһре Болгар, икенчесе — хәзер җимерелгән һәм Казан суы ярында торган, Казаннан 45 чакрымдагы Иске Казан, өченчесе — бүгенге Казан.

Казан ханлыгы Болгар дәүләтенең турыдан-туры варисы дигән фикерне галим күп хезмәтләрендә уздыра. Бу бигрәк тә алда аталып киткән «Болгар вә Казан төрекләре» дигән әсәрдә ачык чагыла. Үзенең хезмәтләрендә ул Болгар дәүләтенең һәрбер билгеле булган идарәчесен (Сәлки, Алмас, Әхмәд, Талиб, Мөэмин, Хәйдәр, Мөхәммәд, Сәгыйд, Бараҗ, Ибраһим, Сәлим, Илһам, Габдулла, Хәсән, Мәхмүд, Габдулла, Алтынбик,

Галимбик) исемнәре белән санап чыга һәм Болгар тәхетеннән Галимбикне Алтын Урдадан килгән Олуг Мөхәммәд бәреп төшерә, дип күрсәтеп үтә. Олуг Мөхәммәднең Казан тарафына килүе тарихи фактлар белән раслана, ләкин аның Казанның үзенә керүе, яки шәһәрне яңадан салдыруы хакындагы мәгълүматлар бик каршылыклы. Күп кенә чыганаклар Алтын Урданың әүвәлге ханы Олуг Мөхәммәднең берара Нижегород шәһәрендә гомер сөрүен күрсәтәләр. Ничек кенә булмасын, бу кеше яңа урында үзенең династиясенә нигез сала, һәм аның улы Мәхмүд 1445 елда Казан тәхетенә чыга. Шулай булгач, Казан ханлыгы, кайбер хезмәтләрдә күрсәтелгәнчә, 1445 елда гына оешмый, бәлки, дәүләт буларак, берничә йөз еллардан бирле яшәп килә, ә 1445 елда биредә бары тик җирле династия читтән килгәне белән генә алмашына. Әлбәттә, дәүләтнең халкы асылда үзгәрешсез кала. Шунлыктан, Р. Фәхретдин раслаганча, династияләрнең алмашынуы Идел Болгарстаны халкының монголларга әверелүе дигән сүз түгел. Чөнки Олуг Мөхәммәд (галим аны Казан тәхетенә чыккан хан дип саный) үзе белән нибары 3 мең генә кеше алып килә, алар арасында сугышчылар бер мең чамасы гына тәшкил итә. Тарихчының язуынча, «ханның килүен ишетеп, төрле җиргә таралган болгар төрекләре шатланып хан хозурына җыелалар һәм шәһәрне бергәләп торгызып урнашалар»... «Чуаш һәм чирмеш халыклары,— дип дәвам итә галим,— буйсынуларын белдереп, хан хәзрәтләреннән үзләрен урыс талауларыннан яклавын үтенделәр», (Шура, 1908, № 10, 300 б.).

Р. Фәхретдин, Карамзин һәм Соловьев хезмәтләренә таянып, Олуг Мөхәммәдне Казанның беренче ханы дип игълан итә. Шулай итеп, дип белдерә тарихчы, 1439 елда Казан яңадан аякка баса һәм аның тарихында яңа дәвер башлана. Кыскасы, галим фикеренчә, Болгар — Казан «чылбырының» эзлеклелеге беркайчан да өзелми, җимерелгән Казанны тергезеп идарә итә башлау «яңа дәвер» дип кенә билгеләнә.

Риза казыйның Казан ханлыгы халкының этник составына карата биргән бәясе үтә әһәмиятле. Ул болай дип яза: «Бары тик төрек халкыннан гына гыйбарәт кавемнәрнең «татар» дип аталуы аларның падишаһлары-

на һәм түрәләренә бәйле рәвештә генә килеп чыккан. Чынлыкта [алар арасында — *Р. Ә.*] татарлар диңгездәге тамчы кадәр дә юктыр». Димәк, «татар» атамасы яңа идарәгә килгән хан һәм аның түрәләренә генә хас, ә җирле, гасырлар дәвамында бергә яшәгән халык арасында алар бик аз булган.

Р. Фәхретдин Казан ханлыгы тарихын нигездә Мәскәү кенәзлеге белән хәрби бәрелешләр сыйфатында тасвирлый, һәр ике яктан чабылган яуларны бик тәфсилләп тикшерә, һәлак булучылар санын һәм кулга төшерелгән ганимәт-трофейларның күләмен бәян итә. Бу җәһәттән галим мәмләкәтләр тарихын өйрәнүнең гомуми схемасына таянып эш итә. Бу хәл ул чорлардагы һәр тарихи хезмәткә дә диярлек хас күренеш. Фәкать корал көче белән генә хәл ителеп килгән хәрби-сәяси мәсьәләләр ул заманда һәрчак алгы планга куелып килгән. Хәер, мәдәни үсеш, сәүдә мөнәсәбәтләре кебек өлкәләрне тикшерү өчен галим кулында җитәрлек материал булмавын да әйтергә кирәктер. Моңа урыс чыганакларының үтә тенденциозлыгы, берьяклылыгы, татар ядкәрләренең харап ителүе дә җитди сәбәп булган, әлбәттә.

5

Ризаэтдин Фәхретдиннең тарихи тикшеренүләрендә зур урынны Алтын Урда тарихы алып тора. Ул аны нигездә идарәчеләрнең тәрҗемәи хәлләрен тасвирлау рәвешендә өйрәнгән. Галимнең әлеге мәмләкәткә биргән бәяләрен һәрвакытта да эзлекле дип әйтеп булмый. Бу хасият дин һәм кавемне, мәҗүсилек чоры белән Ислам дәверләрен каршы куюда күбрәк чагыла. Р. Фәхретдиннең барлык тарихи хезмәтләрен җентекләп өйрәнгәннән соң гына кешелек тарихында җуелмас эз калдырган бу бөек дәүләткә булган карашының эволюциясен төгәлрәк күзалларга мөмкин. Кызганычка каршы, бу хезмәтләрнең күбесеннән без әлегә мәхрүмбез. Әмма булган кадәресе дә галимнең бу мәсьәлә буенча бик бәрәкәтле эш башкарганын күрсәтәләр.

«Шура» журналында ул Алтын Урда тарихын Бәрәкә хан тәхеткә утырган чордан (1257) башлап тикшерә

башлый. Бу очраклы хәл түгел, билгеле. Риза казый 922 елда Ислам динен рәсми төстә кабул иткән Алмуш белән Чыңгыз нәселеннән шул ук динне кабул иткән Бәрәкә хан арасында параллель үткәрә. Бәрәкәнең мөселманлыгы Алтын Урда тарихын уңай позициядән торып өйрәнү һәм тасвирлауның бер мөһим сәбәбе. Бәлки шуңа күрәдер, Алтын Урда белән Казан ханлыгы тарихын язганнан соң гына Р. Фәхретдин Чыңгыз, Җуҗи һәм Бату ханнар дәверенә әйләнеп кайта.

Галимнең халкыбыз тарихына багышлап «Шура» журналында бастырган материалларына мондый бер «сәерлек» хас. Башта ул журналның беренче санында ук (1908, № 1) Болгар хөкемдары Алмуш турындагы мәкаләгә урын бирә, аннары, чор буенча зур сикереш ясап, Алтын Урда (Дәште Кыпчак) ханнары буенча мәкаләләр циклы урнаштыра (1908, №№ 2—9), шуннан соң Казан ханнары турындагы материаллар сериясе басыла (1908, №№ 10—16, 20—24; 1909, №№ 1—3). Болардан соң Чыңгыз хан империясе, Җуҗи, Бату ханнар һәм аларның варислары дәвере тасвирлана (1909, №№ 4—9), Алтын Урданың башлангыч чоры тасвир кылына. Касыйм ханлыгы буенча тикшеренү исә 1909 елгы саннарга (№№ 12—16) карый. Идел Болгарстаны тарихына багышланган материалларның төп өлеше инде 1912 ел белән бәйле (№№ 18—20, 22). Әлбәттә, бу дәвер кысалары эчендә галимнең башка тема, проблема һәм шәхесләргә караган бүтән дистәләрчә мәкаләләре дә дөнья күрә. Р. Фәхретдиннең гадәттән тыш актив иҗади эшчәнлеге хәйран калдыра. Хронологик «тайпылыш»ларга килгәндә исә аларны, безнеңчә, болайрак аңлатырга мөмкин: Риза казый цензураның зәһәр сулышын һәрдаим тоеп иҗат иткән һәм, журнал ябылмагае дип, заманы өчен иң четрекле, «кайнар», татар тарихи әдәбиятында моңарчы кискен рәвештә күтәрелмәгән мәсьәләләрне тизрәк күтәреп, бастырып калырга омтылган, ә «салмаграк», «сүлпәнрәк» һәм нейтральрәк темаларны кичектеребрәк торуны кирәк тапкан булса кирәк.

Башта галимнең Чыңгыз хан империясе, Алтын Урда идарәчеләренә шәхес буларак биргән бәясен карап китик. Тарихчы бу хөкемдарларның (аеруча Чыңгыз белән Батуның) шәфкатьсезлеген, рәхимсезлеген тасвирлау өчен

буяуларны кызганмый, аларның зур дәүләтләрне йөзләрчә мең шәһидләрнең сөякләре өстендә төзүләрен һәм бөтен кешелек дөньясына дәһшәт салуларын күрсәтә. Шул ук вакытта Риза казый аларны югары хәрби сәнгатькә, зур оештыру сәләтенә ия булган гаҗәеп күренекле шәхесләр итеп тасвирлый. Чыңгыз ханны, мәсәлән, «дөньяның иң мәшһүр адәмнәренең вә иң бөек даһиларының берсе» дип атый (Шура, 1909, № 4, 97 б.). Хөкемдарларның рәхимсезлеген, залимлеген һич тә акламыйча, тарихчы монгол гаскәрләренең ни өчен шундый зур уңышка ирешүләрен объектив төстә аңлатырга омтыла. Бу яулап алулар каршы торучы көчләрнең таркаулыклары, башбаштаклыклары, идарәчеләренең үзара даими ызгышып торулары, кыюсызлыклары, куркаклыклары яисә хыянәтләре аркасында гына мөмкин булды, дип яза ул.

Р. Фәхретдин Бату һөҗүменең дә Русь өчен нинди афәт китергәнен тирәнтен аңлап эш итә. Әмма Бату һөҗүме вакытында, ягъни 1237—1240 елларда, урыс халкы кичергән фаҗиганең бөтен авырлыгын тасвирлаган хәлдә, Р. Фәхретдин Чыңгыз һәм Бату биргән сабаклар Русь өчен әрәмгә китмәде, дип белдерә. Үзенең ватанын һәм милли бәйсезлеген саклау зарурилыгы алдында калган урыс халкы, ди галим, бар көчне туплау кирәклегенә тәмам инанды. «Менә бүгенге Русияне Русия иткән нәрсә Чыңгызлар, Батуларның дәресләре булды»,— ди тарихчы. Цензураның кырын карашына һәм ихтимал кисәтүләргә карамастан, Р. Фәхретдин түбәндәге сүзләрне әйтергә дә кыюлык таба: «Турысын әйткәндә, урыслар монголларга рәнҗү түгел, бәлки рәхмәт әйтергә тиешләр» (Шура, 1909, № 8, 228 б.).

Икенче яктан, Р. Фәхретдин фикеренчә, Алтын Урданың үз эчендә бертуктаусыз дәвам иткән низаглар, Үзбәк ханның Мәскәүгә карата артык йомшак мөгамәләсе һәм ташламаларга баруы, Урданы Аксак Тимер һәм Миңле Гәрәйнең тар-мар итүләре нәтиҗәсендә генә Русь күтәрелеп китә алган. Бүгенге Русияне Русия итүче бөек Петр I белән Екатерина II булса да, ди тарихчы, нигезен салучы — асылда Үзбәк хандыр. Әгәр дә Үзбәк хан үзеннән элек идарә иткән ханнар юлын тоткан булса, «бер Петр белән бер Екатерина түгел, ун Петр белән ун Екате-

рина тырышсалар да, бу көнге Русия дәүләте мәйданга киләчәк түгел иде (Шура, 1908, № 3, 72 б.).

Үзеннән-үзе аңлашылса кирәк, Алтын Урда тарихы Р. Фәхретдин тарафыннан уңай позициядән торып тасвирлана һәм бу дәүләтнең Русь белән хәрби бәрелешләрен сурәтләгәндә тарихчы Сарай ханнарына, Алтын Урдага булган симпатиясен яшерүне һич кирәк тапмый. Аерым алганда, бу шуның белән аңлатыла: галим Алтын Урдага (Дәште Кыпчакка) «бөек бер Төрек дәүләте» дип карый. Ә бу дәүләтнең төп халкын, Р. Фәхретдин фикеренчә, төрки кабиләләр: кыпчаклар, болгарлар һәм башкалар тәшкил итә. Монгол ханнары яугирләренең күбесе төрек булганга, бу тарафларга килгәч, кабат «үзләреннән ничә өлеш күп булган төрекләргә катышулары сәбәпле, телләрен һәм күп гадәтләрен ташлап, төрек теле кабул иткәннәр». Гаскәрнең югары катлавы гына чын мәгънәсендә татарлар (монголлар) булып, хөкүмәт үзе һәм ханнар «татар» атамасы белән йөриләр, «бу гадәт Кырым һәм Казан ханлыкларына кадәр дәвам иткән». Татарлар (монголлар) үзләре дә җирле кабиләләр арасында тиз «эреп», төрки телне кабул иткәннәр (Шура, 1908, № 2, 34 б.). Шуның өстенә, Алтын Урда халкының күпчелеге Ислам динен тоткан. Әлбәттә, үзен «болгар төреге» һәм «хак мөселман» дип санаган XX йөз башы галименең тарихны урдалылар позициясеннәнрәк торып язуы бик табигый хәл. Икенче тарафка күз салыйк. Рычков, Карамзин, Соловьев, Ключевский һ. б. мәшһүр урыс тарихчылары да бит үзләренең тарихи хезмәтләрен тулаем православие мәзһәбе һәм Урыс дәүләте интересларын күздә тотып язганнар.

Р. Фәхретдиннең Алтын Урданың куәтен һәм данын ныгыткан хөкемдарларны мактавын, ә мәмләкәтнең көчсезләнүенә китергән яисә аны җимергән хакимнәрне яманлавын һич тә гайре табигый күренеш дип әйтеп булмый. Аерым алганда ул болай ди: «Бүгенге Русия мөселманнарының бабалары Тимерләнк [ягъни Аксак Тимер.— *Р. Ә.*] золымыннан күргән фаҗига кебек гомуми фаҗигане башка беркемнән дә күрмәгәннәрдер».

Алтын Урда белән Мәскәү Русе арасындагы мөнәсә-

бәтләрне тасвирлауга килгәндә, Р. Фәхретдин башлыча хәрби орышларга туктала, ләкин шуның белән беррәттән дипломатик адымнарга, ярлыклар эчтәлегенә дә күп урын бирә. Тарихчы еш кына «мәдәниятле» урыслар тарафыннан «вәхши татарлар» дип атап йөртелгән татарларда дин иркенчелеге хөкем сөргәнен, аларның чиркәүгә һәм иманга кагылмавын, христианнарны мөселманлаштыру белән шөгыльләнмәүләрен искәртеп үтә. Биредә Русия мөселманнарының XX гасыр башындагы аяныч хәленә, дини һәм мәдәни яктан төрле кысуларга дучар ителүенә әрнүле киная яңгырый. Бу гыйбрәтле фактны раслау йөзеннән тарихчы Үзбәк ханның 1313 елда митрополит Петрга биргән ярлыгыннан бер өзек китерә. Ярлык христиан диненә тулы ирек гарантияли һәм аны кыерсытучыларга үлем җәзасы билгели.

Алда әйтелгәнчә, Р. Фәхретдин дини симпатияләрдән бөтенләй үк азат тикшеренүче түгел. Ул урыс тарихларында мөселманнарның сугыштагы рәхимсезлеген тасвирлаган язмаларга каты гына рәнҗи, үпкәли, ә кайчагында, үзе дә мавыгып китеп, Исламның орыш вакытларындагы ролен, данын күперткәләп куя. Моңа мисал итеп 1437 елда Олуг Мөхәммәднең 1 меңле чирүе белән 40 меңле урыс гаскәрен тар-мар итү фактын мөселманлыкның өстенлеге белән бәйли.

Игътибарга лаек бер искәрмә китерү дә урынлы булыр: галим каршы якларны беркайчан да диярлек «урыслар» һәм «татарлар», «христианнар» яки «мөселманнар» дип атамый, әйтик, Мәскәү — Казан мөнәсәбәтләре турында сүз барганда гел «москвалылар» һәм «казанлылар» дип яза. Мәскәү гаскәре явын тасвирлаганда Риза казый бер вакытта да урысларның хәрби гайрәтләрен шик астына алмый, урыс кенәзләренең хәрби эшләрен, дипломатик адымнарын шелтәләми, сүз Мәскәү кенәзе турында бара икән, «великий» эпитетын өстәргә онытмый. Аның хезмәтләрендә Иван III ме, Василий III ме, яки Иван Грозныймы,— барлык Мәскәү идарәчеләренә карата хөрмәт, ихтирам сизелеп тора. Моны цензураны күздә тотып эшләнгән гамәл генә дип уйларга нигез юк, чөнки, ихтыяҗ булса, галим битараф бәяләмәләр дә таба алган булыр иде. Безгә калса, биредә

бер төр хөкемдарларны икенче төр хаким-түрәләргә каршы куеп, аларның асылын ачып күрсәтү максат итеп куелган. Шул максатка турылыклы булып, тарихчы күп кенә Казан идарәчеләрен, бәкләрне, мирзаларны аларның җебегәнлекләре, куркаклык вә аумакайлыклары, сатлык җан булулары, шәхси мәнфәгатьләре, коллык психологиясе, үз тиреләре өчен ватаннарын, халкын, динен сатарга әзер булулары өчен рәхимсез рәвештә тәнкыйтьли, фаш итә. Бу җәһәттән аяусыз каһәрләү уты бигрәк тә Шаһ Гали, Камай мирза ише хаиннәргә төбәп атыла.

Р. Фәхретдин Казанның 1552 елда камалуын һәм алынуын бик тәфсилле һәм нигезле итеп тасвирлый, ул, бер яктан, Мәскәү гаскәрләренең гайрәтен, сан ягыннан зур өстенлеген һәм көчен күрсәтсә, икенче яктан, казанлыларның тиңдәшсез каһарманлыгын, ватан өчен үз-үзләрен аямауларын һәм фидакарьлеген сурәтли.

XVI йөзнең беренче яртысында Төркиянең Казан ханлыгын басып алу («турецкое порабощение») куркынычы дип исем алган бер галәмәт мәсьәләсе игътибарга лаек. Р. Фәхретдиннең язуына караганда, солтан Сөләйман Кануни «ул вакыта бөтен җиһанны тетрәтеп торган куәт иясе вә шәүкәтле бер падишаһ» була. Әгәр, ди тарихчы, солтан үзенең Истанбул тәхетеннән Василийга (сүз Иван IV нең атасы Василий III турында бара) бармак кына селексә дә, кенәз «Казан тарафына хәтта күз дә салачак түгел иде». Солтанның Казан эшләренә битараф булуын күрсәтеп, галим фикерен болай дип тәмамлый: «Фәкать Казанга гаскәр дә җибәрмәде һәм җитди сурәттә Казан мәсьәләсенә керешмәде дә». Солтан Казанга ярдәм кулы сузу түгел, бәлки иле өстенә дәһшәт-афәт килгән вакытта үзеннән ялварып ярдәм сораган Казан ханы Сәхиб Гәрәйне кырымлы Дәүләт Гәрәй кулы белән үтертте, дип яза ул (Шура, 1908, № 24, 745 б.).

Р. Фәхретдин Мәскәү хөкүмәте тарафыннан Казан дәүләтенә каршы буларак төзелгән Касыйм ханлыгы хакында да мәкаләләр тезмәсе бирә. Идарәчеләре формаль рәвештә татар ханнары исәпләнгән бу бәйле, курчак хөкүмәтенең тарихын тикшереп, галим, бер яктан, урыс патшаларының бу дәүләттән ничек оста файдалануларын тасвирласа, икенче яктан, Касыйм ханнарының үз кардәшләре дәүләтен, ягъни Казан ханлыгын җимерүдәге җи-

наятьчел һәм ямьсез рольләрен күрсәтә. Билгеле булганча, 1681 елда урыс патшасы ихтыяры белән Мәскәү өчен бернинди кирәге калмаган Касыйм ханлыгының бетерелүе бу буфер дәүләтнең хурлыклы тарихына чик куя. Язмышның каһкаһәсе һәм мәсхәрәсе сыман, бу дәүләтнең соңгы «идарәчесе» — картаеп бетәшкән Фатыйма-Солтан була. Ул Казан егылудан 129 ел үткәннән соң, 1681 елда вафат була һәм каһарман, галиҗәнаб, гүзәл Сөембикәнең гаҗәеп образы фонында шыксыз бер сөрхәнтәй сыман гәүдәләнә.

Галимнең милли тарихыбызга керткән өлеше бәһасез. Күләме чикләнгән бер мәкаләдә аның бу өлкәдәге бәрәкәтле эшчәнлеген һәрьяклап колачлау һич мөмкин түгел. Һәм мондый максат куелмады да. Идел һәм Урал буе төрки халыкларының гыйбрәтле тарихын тәфсилләп өйрәнүгә бөтен аңлы гомерен багышлаган һәм гаять зур көч куйган күренекле галим Ризаэтдин бине Фәхретдиннең иҗаты бүгенге көндә барлауны, комплекслы тикшеренүләрне, яңача бәяләмәләрне көтә.

6

Сезнең кулыгыздагы «Татар ханнары» дигән шушы китап Р. Фәхретдиннең биниһая зур мирасының «Шура» журналында басылган бер бик кечкенә өлеше генә. Без биредә мөхтәрәм укучыларыбызга бөек галимебезнең Казан ханлыгы чорына караган язмаларын тәкъдим итәбез. Әлеге серия Казан дәүләтенең 13 ханын (Олуг Мөхәммәд, Мәхмүд, Хәлил, Ибраһим, Илһам, Мөхәммәд Әмин, Габдел-Латыйф, Сәхиб Гәрәй, Шаһ Гали, Сафа Гәрәй, Җан Гали, Үтәмеш Гәрәй вә Сөенбикә, Ядкәр), ханлыкның 113 еллык дәверен үз эченә ала.

Материалларны басмага әзерләгәндә, бүгенге укучыга мөмкин кадәр аңлаешлы булсын өчен, Р. Фәхретдиннең XIX йөз ахыры — XX йөз башына хас фән телен шактый җиңеләйтеп бирергә, хәтта ки аерым җөмләләрен тәрҗемә итәргә дә туры килде. Үрнәк өчен гарәп, фарсы, гомумтөрки тәгъбирләре кулланылган түбәндәге текстны һәм аның тәрҗемәсен китерү урынлы булыр. «Шура» журналында текст, мәсәлән, болай бирелә: «Бунда һәм

үзенең бер уч гаскәре илә ун вә йөз биңләр илә агыр эшләнәчәк эшләрне иҗраэ идеп, үзенең гайрәт вә җәсарәтене күстәрде. Фәкать бунда һәм бөйлә һиммәтләренең нәтиҗәсене күрәчәк йирдә, билгакес, фәләк җәүренә мөбталә вә зайгъ улды». Тәрҗемәсе: «Монда да үзенең бер уч гаскәре белән ун вә йөз меңнәр белән авыр эшләнә торган эшләрне башкарып, үзенең гайрәт һәм батырлыгын күрсәтте. Тик монда да шушы омтылышларының нәтиҗәсен күрәсе урынына, тәкъдирнең рәнҗетүенә дучар вә әрәм булды».

Ләкин авторның стиле, сүз сөреше, фикерләү алымнары шул килеш сакланды, җөмләнең тарихи аһәңен җуймас өчен кайбер гыйбарә-атамалар асыл формасында алынып, янәшәсендә «ягъни» сүзе белән тәрҗемәсе биреп барылды. Р. Фәхретдиннең үз искәрмәләре текстта җәяләр эчендә, ә тәрҗемәче-эшкәртүченеке, төзүченеке 1, 2, 3... шәкел-формасында ахырдан бирелде.

Равил Әмирхан,
3 февраль 1994 ел.

Казан ханлыгы

ОЛУГ МӨХӘММӘД ХАН

(? — 1446 елда вафат)

Олуг Мөхәммәд хан Дәште Кыпчак белән Казан мәмләкәте хөкемдарларының иң мәшһүрләреннән булып, Тимер хан бине Тимер Котлыг хан бине Тимер Мәлик хан бине Рус (Ырыс) хандыр[1]. (Рус тарихчы-мөәррихләреннән Рычков, Батудан башлап Сарайда булган ханнарның Олуг Мөхәммәд егерменчесе иде, дип яза.) Олуг Мөхәммәд 1419 елда[2] Сарай шәһәрендә Дәште Кыпчак мәмләкәтенә хан итеп куелган иде.

Мәскәү кенәзе Василий Беренче вафат булгач[3], угылы Василий кечкенә булу сәбәбеннән бер тума карендәше (әтисе белән бертуган абзасы) Юрий Дмитрий угылы Мәскәүдә великий кенәз булу кайгысына төште һәм кенәзлек хакында Василий белән Юрий арасында шушы мәсьәләдә олуг бер низаг калыкты. Ахырда, хан хәзрәтләре кемне великий кенәз итеп ярлык бирсә, шуңа риза булачаклары хакында бу ике хәсем, ягъни дошман ризалашып, үз араларында килешү төзеделәр. Бу вакыйга 1428 елда булды. Тик низаг һаман да бетмәде, шуның өчен 1431 елда Юрий белән Василий үз араларын хөкем иттерер өчен Сарай шәһәренә, Олуг Мөхәммәд хан хәзрәтләре хозурына сәфәр иттеләр. (Бу сәфәрләре кыш көне ноябрь яки декабрь аенда булуы риваять ителә.)

Юрий хан хәзрәтләренең игътибарында булган Тикин мирзаны үзенә теләктәш дип ышана һәм аның илтифаты ярдәмендә Мәскәү кенәзлеге өчен ярлык алуга өметләнә иде. Сарайга барганнан соң Тикин мирза, хәтта Юрийны да алып, Кырымга сәфәр итте, бу сәфәрендә Юрийга Мәскәү кенәзлеген бирү хакында вәгъдә итүе дә риваять кылынадыр.



Олуг Мөхәммәд хан. Рушан Шәмсетдинов рәсеме.

Василий ягыннан тырышыр өчен Василий белән берлектә Иван бине Димитрий исемендә олуг боярлардан бер кеше барган иде. Хан хәзрәтләренең мөкаррәбләреннән, ягъни якыннарыннан гыйбарәт булган бер мәҗлескә ничек кирәк алай кереп, әлеге бояр Иван «великий кенәзлек» мәсьәләсен кузгатты һәм: «Юрийны Тикин мирза великий кенәз иттереп куйдырса кирәк. Хан хәзрәтләре Тикин мирза сүзенә игътибар итәр, сезнең исә Тикин мирза кадәр йогынтыгыз вә игътибарыгыз юк дип ишетәм» мәгънәсендә бер сүз сөйләп, бөек мирзаларны гаять гарьләндерде. Шуның тәэсирендә, хан хәзрәтләре каршында үзләренең йогынтысы ни кадәр икәнен күрсәтү теләге белән мирзалар Василийны великий кенәз иттерү хакында хан хозурында тырышлык күрсәтергә карар бирделәр. Һәм дә, әгәр хан хәзрәтләре хозурында Юрий файдасына сүз сөйләр булса, Тикин мирзаның үтереләчәген мирзаның үзенә аңлаттылар. Бигрәк тә Мәскәүдә хан тарафыннан баскак булып торучы Әмир Фулад белән Хәйдәр исемле бер мирза Василий тарафын куәтләүне тиеш табалар иде.

1432 елның язында Урдада Василий белән Юрий арасында булган низаг каралды вә моның нәтиҗәсе буларак, Мәскәү великий кенәзлеге өчен Василий Икенчегә Олуг Мөхәммәд хан хәзрәтләре тарафыннан ярлык бирелеп, изге эш кылынды. Хан хәзрәтләре Углан исемле вәкилен Мәскәүгә җибәрде. Әлеге вәкил исә Василийны тәхеткә утыртып, хан хәзрәтләренең мәншүрен, ягъни хокук кәгазен укып игълан итте[4]. Шул көннәрдә Урда шаһзадәләреннән Кече Мөхәммәд исемле берсе (моны тарихчы Соловьев Олуг Мөхәммәд ханның бер тумасы иде дип яза) Олуг Мөхәммәдкә каршы чыкты. Василий вакыйгасында кәефе кырылган Тикин мирза моны уңышка юрап, Олуг Мөхәммәд ханнан үч алу теләге белән үзенең иярченнәрен Кече Мөхәммәд тарафына кушты. Ахырда Олуг Мөхәммәд хан бу бәла вә мәшәкатьләргә чара юклыгыннан Сарай шәһәрен ташлап качарга мәҗбүр булды[5]. Бу вакыйга исә 1437 елда булмыштыр.

Олуг Мөхәммәд хан үзенең хатыннары, угыл вә кызлары һәм үзенә ихласлы булган иярченнәрен алып, барлыгы 3 мең кадәр җан хисабы буларак, Русия сәрхәденә, ягъни чигенә килде һәм Литвага буйсынган Белев шәһәренә урнашты. Максаты — үзенең хәлен бераз рәтләп һәм Сарайда булган тарафдарлары белән хәбәрләшеп, яңадан үзенең тәхетен кайтарып алу иде. Һәм дә үзенең вәли

нигъмәт, ягъни кенәзгә нигъмәт бирүче булуын фикерләп, бу максатына Мәскәү кенәзе Василий Икенче үзенең гаскәре белән ярдәм бирәчәк дип өметләнә иде. Чөнки Василий бары тик Мөхәммәд хан ярдәме вә аның ярлыгы аркасында гына Мәскәү кенәзлегенә ирешкән иде. Фәкать Василий хан хәзрәтләрен үзенең бәхетенә сәбәп булган вәли нигъмәтне гүзәл кабул итәсе урынына, киресенчә, кеше җибәреп: «Безнең чигебездән китсен!» — дип куды[6].

Шушы хәлне белгәч, хан хәзрәтләре гадәттән тыш гаҗәпләнде, моның кебек усал мөгамәләдән үзенең яхшылыгы бушка киткәнен аңлады, ләкин гаять галиҗанәп һәм солтанәт бер кеше булганлыктан, Василий илчесенә бөтенләй илтифат күрсәтмәде вә җавап бирмәде. Шул сәбәпле Василий хан хәзрәтләрен көч белән чыгарту өчен үзенең тумалары Шемяка белән Дмитрий командасында 40.000 гаскәр җибәрде.

Рус гаскәренең Белев шәһәренә килүен белгәч, хан хәзрәтләре курыкты вә килешү сорап гаскәр башлыкларына кеше җибәрде. Ләкин гаскәр башлыклары хан сүзен кабул итмәделәр, шәһәргә һөҗүм иттеләр. Шушы вакыйгада хан хәзрәтләренең бер кияве шәһид булды.

Икенче көн хан хәзрәтләре Мәскәү кенәзе исеменнән нинди шартлар куйсалар да, барысына да риза булачагын вә моңа инабәт, ягъни ышаныч өчен үзенең угылы Мәхмүдне әманәт итеп биреп торачагын, Урдага кайтканнан соң, Мәскәү кенәзлегеннән бернинди салым алмаячагын тәэкид, ягъни вәгъдә итеп, үзенең мирзаларын җибәреп сөйләтте. Фәкать моның да һичбер нәтиҗәсе күренмәде. Иң ахырда хан тарафыннан: «Һич югы иртәгә кадәр генә форсат бирегез!» — дип үтенеп соралды, моның да файдасы булмады. (Рычков. 79 б.)

Менә бу вакыт хан хәзрәтләре җәнабе Алладан башка һич ярдәмчесе булмавын күреп, тәһарәтләнеп, бер агач күләгәсенә барып ике рәкагать намаз укыды вә озак егълап дога итте һәм җәнабе Алладан мәдәд, ягъни ярдәм вә насыйрәт, ягъни яклау сорап, сугышыр өчен атына менде. (Мөстәфадел-әхбар, Т.1. 125 б.) Бу җирдә русларның карт мөәррихләре, ягъни тарихчылары булган Рычков шундый бер хорафат һәм шыр ялган бер нәрсә риваять итә ки, хәтта кире кагу өчен дә күчереп язу мөнасиб түгел. Дөньяда фанатизмның бу дәрәҗәсе булуын адәм угылы хыялына да китермәс.

Арыслан йөрәкле ханның ат өстенә менеп, «Аллаһе әкбәр!» дип һөҗүм итүе белән Русия гаскәре һич сәбәпсез

качарга керөште. Хәлбуки ханның иярченнәре өч мең булып, хатын-кызлар, бала-чагалар шул хисапта иде. Кораллы сугышчылар исә нибары бер мең микъдарында иде. Менә шушы бер мең халыктан 40 меңле гаскәр качты, хан гаскәре исә аның артыннан куып, тәмам кырып вә үтереп бетерде[7]. (Соловьев бу хәлне бөек бер гарьсезлек һәм куркаклык дип фикер йөртүеннән булса кирәк, шундый бер тәүҗиһ, ягъни астын-өскә әйләндерү тапкан ки, мондый нәрсә хәтта Рычков хәтеренә дә килмәгән. Соловьев әйтә: «Мәскәүдән ярдәм өчен килгән гаскәрнең башлыгы хан тарафын илтизам итте, ягъни хан ягын алды вә хәйлә белән Мәскәү гаскәрен җиңелүгә дучар итте». Чынлыкта болай булмаса да, шулай тәүҗиһ ителергә «тиешледер». Чөнки халык башкаларның дөрес сүзләреннән Соловьев кебек бөек тарихчының ялганнарына күбрәк инабәт итәр, ягъни ышаныр. Хатын-кыз, бала-чагалары белән берлектә күчеп баручы бер юлаучы төркемне куар өчен әүвәл мәртәбә 40 мең кораллы гаскәр җибәрелә дә, шуларга ярдәм сыйфатында иртәгесен яңадан ничә меңнәр гаскәр өстәлә. Һәм дә бу ярдәмче гаскәр Мәскәүнең үзеннән түгел, бәлки Литвадан җибәрелә. Гаскәр башлыклары артларыннан килгән Литва гаскәр башлыкларының авызыннан сөйләгән сүзләргә ышаналар, һичбер язуфәлән сорамыйлар имеш! Мондый урынсыз тәүҗиһ Соловьев тарихына керергә тиешле сүзме инде? Алла гыйшкына бер җавап бирегез!). Бу вакыйга 1438 елның 5 декабрендә булды[8].

Хан хәзрәтләре бу җиңүдән мәгърур булмыйча, үзләренең азлыкларын игътибарга алып, Мәскәү җиренә кермәде, бәлки сахра юлы белән чик буеннан йөреп, Волга елгасына килде вә елганы аркылы чыгып, искедән Болгарга буйсынып та, бу көндә харап булган Казан хәрабәсен төзекләндереп, үзенә торачак урын ясады[9].

Хан хәзрәтләренең килүен ишеткәч, тирә-якта таралып торган болгар төрекләре шатланып, хан хозурына җыелдылар һәм бергәләп шәһәрне торгызып урнаштылар. Хәтта чуаш вә чирмеш халыклары да, буйсынуларын белдереп, рус халыкларының талауларыннан саклауны хан хәзрәтләреннән үтенделәр. Менә шушы юл белән Казан хөкүмәте башланган.

Фәкать төрек халкыннан гына торган бу кавемнәрнең «татар» дип аталып китүе үзләренең падишаһ вә түрәләренә нисбәтле рәвештә генә булмыштыр. Чынлыкта исә биредә татарлар диңгездәге тамчы кадәр дә юк иде[10].

Олуг Мөхәммәд хан. Рәшит Төхфәтуллин рәсеме.

Казан шәһәрен торгызып, бер карарга килгәннән соң хан хәзрәтләренең Сарай вә Хажитархан, ягъни Әстерхан шәһәрләрендә булган иярченнәре күчеп килделәр.

Казан шәһәренең икенче мәртәбә торгызылуы вә Казан хөкүмәтенең оешуы 1439 елдадыр[11].

1439 елның июль аенда Олуг Мөхәммәд хан үзенең аз гына булган гаскәре белән Мәскәү тарафына китте вә аңсыздан Мәскәү янында күренде. Кенәз Василий моны белгәч Мәскәүдән чыгып качты. Хан хәзрәтләре Мәскәү янында ун көн торып, Коломна шәһәрен яндырды һәм күп трофейлар алып кайтып китте.

1445 елда, икенче мәртәбә буларак, кыш көнендә Олуг Мөхәммәд хан Мәскәү мәмләкәтен максат итеп чыкты һәм Нижгород вилаятен забыт итте, ягъни сугышып алды вә Муром шәһәренә юлланды. Бу вакыт великий кенәз Василий бөтен гаскәрен алып хан хәзрәтләренә каршы килде. Мәскәү гаскәренең күплегеннән хәбәр алып, хан Нижгородка кире кайтты. (Бу Соловьев сүзедер. Карамзин исә Нижгород җиренә, Казанга кайтты, дип яза.)

1445 елның язында Олуг Мөхәммәд хан өченче мәртәбә буларак, Мәскәү мәмләкәтенә юлланды. «Хан Нижгородны алды вә Суздаль вилаятенә ике шаһзадә, Мәхмүд белән Ягъкубны җибәрде», дип Мәскәүдә хәбәр чыкты. Моны ишетеп, Василий күңеленә курку төште. Гаскәр җыеп, шаһзадәләргә каршы китте. Евфим монастыре янында ике гаскәр очрашып, сугыш башланды. Ни сәбәптәндер Казан гаскәре бозылды вә кача, ә руслар куа башладылар. Шул вакыт казанлылар кире әйләнеп, Мәскәү гаскәренә каршы торырга һәм һөҗүм итәргә керештеләр, хәтта артларыннан урап алдылар. Табигый, Мәскәү гаскәре җиңелде. Үзенең кенәзләре вә якын адәмнәре белән великий кенәз Василий Икенче казанлылар кулына әсир төште. Казанлы шаһзадәләр Василий муенында булган алтын тәрене алдырып, Мәскәүгә анасы һәм хатынына җибәрделәр (әсир төшүенә таныклык булсын өчен). Бу вакыйга 1445 елның июнь башларында булды.

Мәскәү халкы бу хәбәрне ишетү белән бөтенләй шашып калды, кайгы киемнәре киеп елашырга, чиркәүләренең кыңгырауларын сугарга кереште. Казан гаскәре Мәскәүгә килер дип, кремльгә керә, кача башлады. Шушы хәсрәтләр һәм мәшәкатьләр арасында 14 июльгә каршы төндә Мәскәүдә зур янгын чыкты. Шәһәр тәмам ут эчен-

дә калды вә 700 ләп кеше янып үлде. Великий кенәзнең анасы Софья һәм хатыны Мария балалары белән Ростов шәһәренә качтылар. Мәскәүдә һич хаким-фәлән калмады. Тычкан тишеге мең алтын дигәндәй, халык кая качарга гаҗиз булды. Кыскасы, Мәскәү кыямәт көненә бер мисал булып калды. Әгәр дә шушы сәгатьтә Казан гаскәре килгән булса, һич каршылыксыз Мәскәүне алачак иде. Ләкин бу хәлдән аларның хәбәрләре булмады.

Казанлылар Мәскәү гаскәрендә булган трофей малларын җыеп тәмам иткәннән соң Владимир шәһәренә килделәр. Ләкин үзләренең азлыклары сәбәпле шәһәргә һөҗүм итәргә кыюлыклары җитмәде, шуның өчен Муром шәһәренә, ә аннан Нижгородка хан хәзрәтләре хозурына кайттылар.

Хан хәзрәтләре гаскәрен, әсирләр вә Мәскәү кенәзен алып, 25 августта сәфәр итеп, Курмыш шәһәренә килде һәм Бегич исемле кешене, Мәскәү кенәзенең якыннарыннан булган Шемякага җибәреп, әгәр дә хан тарафыннан куелган шартларга риза булса, аның үзен Мәскәүгә великий кенәз итеп куячагын белдерде. Шемяка исә һич көтмәгәндә мондый мөһим бер хәбәр килүенә бик шатланды вә риза икәнен белдерде. Һәм дә Василийны гомере буена хан хозурында әсир итеп тотып, Мәскәүгә бөтенләй кайтарылмавын үтенеп вә килешү төзер өчен Дубенский исемле бер боярны илче итеп җибәрде.

Хан хәзрәтләренең бу эшне тиз тәмам итәсе килсә дә, Шемяка хозурына киткән илче Бегичның мәэмүлдән, ягъни көткәннән артык озак торуы аркасында шул вакыт Бегич мирза Шемяка тарафыннан үтерелгән икән дигән бер хәбәр таралды. Икенче җанибтән, ягъни тарафтан Болгар шәһәре шаһзадәләреннән Гали бәк исемле берсе Казан шәһәренә һөҗүм иткән, аны яулап алган дигән хәбәр килеп иреште. Менә шул сәбәпле хан хәзрәтләре бу турыда әсирлектә булган Василий белән сөйләшүне тиеш тапты. Шемякага куелган шартларны Василийга хан тарафыннан гарыз иттеләр, ягъни белдерделәр һәм, шуңа риза булса, әсирлектән азат итеп, яңадан Мәскәүгә элекке дәрәҗәсе белән кайтарачакларын аңлаттылар. Язмышыннан мәэюс булган, ягъни өметен өзгән Василий бу хәбәрне ишеткәч шатлыгыннан ни кылырга белмәде. Барлык шартларга риза булды һәм өстәп 200.000 сум акча да бирүе риваять ителәдер. Шулай итеп, Василий белән хан хәзрәтләре арасында шул турыда килешү язылды һәм шуңа күрә Василий һәм дә янында булган кенәзләре

вә әсирләре — барысы да 1 октябрьдә азат ителеп, Мәскәүгә җибәрелделәр[12].

Боларны озатып һәм Мәскәүгә барыр өчен дип хан үзенең мирзаларын җибәрде. Мирза Бегич бу вакыт Шемяка илчесе булган Дубенский белән хан хозурына кайтып киләләр иде. Ока елгасына җиткәндә Василий азат ителгәнне ишеттеләр. Шуның өчен Дубенский кире кайтып китте вә моның кешеләре Бегичны шунда кулга алдылар (эшнең соңы ничек булуы безгә беленмәде).

Олуг Мөхәммәд хан хәзрәтләре 1446 елда вафат булды. Кабере Курмыш шәһәрендәме, яки Казандамы — ачык мәгълүмат табылмады. Рус тарихчылары Мөхәммәд хан хәзрәтләре белән кече угылы Йосыф, олы угылы Мәхмүд тарафыннан үтерелде, диләр. (Карамзин бу тумасының исемен телгә алмаса да, Рычков аны «Йосыф исемендә иде», дип яза, 82 б.)

Вакыйганың иҗмале, ягъни кыскача эчтәлеге моннан гыйбарәт: Мәскәү кенәзе әсир алынганнан соң моны азат итү-итмәү хакында шаһзадәләр вә ханның якыннары ике тараф булдылар. Берсе, моны гомерлек тоткын итеп, великий кенәзлеккә Шемяканы куюны һәм Мәскәү кенәзлеген Казан кул астында тотуны теләсә, икенче як Василийны азат иттерү тарафында иде. Василий тарафдарлары коткару әмәлен күрү хакында шаһзадә Касыйм һәм Ягъкубтан үтенәләр иде.

Шаһзадә Касыймның хан булырга теләге булганлыктан, кенәз үзен хан иттерү хакында тырышырга вәгъдә итсә, Василийны азат иттерергә сүз бирде. Василий исә моңа билгаен вәррәэс, ягъни «баш өсте» дип риза булды. Шул сәбәпле Касыймның атасы Олуг Мөхәммәд хан да Василийны азат иттерү тарафын куәтләде, эшләр озакка сузылмасын өчен Бегич мирза Шемяка тарафыннан үтерелде дигән буш бер хәбәр тараттырды. Әмма шаһзадә Мәхмүд үзе әсир иткән кенәзне азат иттерү ягында түгел иде. Менә шул вакыт Мәхмүд үзенең борадәрләре, ягъни ир туганнары Касыйм вә Йосыфларның мәкерләреннән хәбәрдар булып, Йосыфны үтерде, Касыйм белән Ягъкуб качып котылдылар. Олуг Мөхәммәд хан хәзрәтләре үзе дә шушы интригалар корбаны булды[13].

Олуг Мөхәммәд хан гаять гакыллы вә гайрәтле бер зат булуы сәбәпле, Дәште Кыпчак татарларының холыклары тәмам бозылып, бер-берсеннән мәхәббәт алып, ягъни якын күрүләрен ташлап, дошманлашып беткәннән соң хан булган булса да, хөкүмәт эшләрен гадәттән тыш

төзәтте. Хәтта моның Бату хан заманасын кире кайтарачагы турында фикер йөртәләр иде[14]. Ләкин мәкерле заман моның әмәл-чараларына уңайлылык итмәде вә ниятләгән нәрсәләре тормышка ашмады. Татар түрәләре арасында барлыкка килгән әхлаксызлык сәбәпле гаделлек белән хөкүмәт сөргән бу хан өстенә Борак хан һәм анан соң Кече Мөхәммәд хан чыгып, күп мәшәкатьләргә төшерделәр вә иң ахырда Сарайдан кудылар. Моннан соң Болгар янына килеп, ул Казан дәүләтен тәшкил итте. Монда да үзенең бер уч гаскәре белән ун вә йөз меңнәр белән авыр эшләнә торган эшләрне башкарып, үзенең гайрәт һәм батырлыгын күрсәтте. Тик монда да шушы һиммәтләренең нәтиҗәсен күрәсе урынына, тәкъдирнең рәнҗетүенә дучар вә әрәм булды.

Олуг Мөхәммәд хан кояш елы хисабы буенча Сарайда 17 вә Казанда 8 ел (Рычков, мәсәлән, Казанда 6 ел хөкүмәт сөрде, дип яза, 82 б.), барлыгы якынча 25 ел хөкүмәт сөрмештер[15].

Җәнабе Алла кылган эшләрен гафу итсен вә ярлыкасын!

ИСКӘРМӘЛӘР (ОЛУГ МӨХӘММӘД ХАН):

[1] Кайбер чыганакларда Олуг Мөхәммәд мәшһүр Туктамыш ханның оныгы һәм Җәләлетдин ханның улы дип күрсәтелә.

Аксак Тимернең Алтын Урда башкаласы Сарайга һөҗүменнән соң, биредә тәхет өчен аяусыз көрәш яңа фазага керә. Ханлык өчен нигездә элекке ханнар — Туктамыш тарафыннан бәреп төшерелгән Тимер Котлыг һәм үз чиратында Аксак Тимер тарафыннан алып ташланган Туктамыш көрәшәләр. Туктамыш үлгәннән соң, тәхетне күбесенчә аның уллары дәгъвалый һәм кыска гына вакытлар хан булып тора. Аеруча уңышлы ханлыкны Җәләлетдин сөрә. Ул 1411 елда, Литва кенәзе Витовт ярдәмендә Тимер Котлыг дигән ханны бәреп төшереп, үзе аның урынын ала. Җәләлетдин Русия өстеннән хакимлекне ныгыта, Дмитрий Донскойның улы Василийны Сарайга килергә һәм гадәттәгечә салым түләргә мәҗбүр итә (1412).

[2] Олуг Мөхәммәд тәхеткә 1420 нче еллар азагында, берничә сарай фетнәсеннән соң килә, дигән мәгълүматлар да бар. Аның дәверендә Алтын Урданың урыс кенәзлекләре өстеннән хакимлеге какшамас нык була.

[3] Василий Димитриевич, 36 ел кенәзлек иткәннән соң, 1425 елның 27 февралендә үлә.

[4] Ханның вәкиле Василий Васильевичны Мәскәүнең Успения соборында тәхеткә күтәрә. Бу чорларда Олуг Мөхәммәд

хөкүмәте бик куәтле булып, тирә-юньдәге вилаятьләрдә генә түгел, халыкара өлкәдә дә зур дипломатик эшчәнлек алып бара. Мәсәлән, халыкара сәясәттә нык кызыксыну күрсәткән Олуг Мөхәммәд даирәсе 1428—1429 елда хәтта Мисырга да илчелек юллый.

[5] Олуг Мөхәммәднең Сарайдан куылуы турында мондый версия бар. Тәхеткә менгәннән соң, Олуг Мөхәммәд Тимер Котлыг династиясе тарафдары, үлем җәрәхәтләре алган мәшһүр Идегәй мирзаны, качкан җиреннән табып, үтерергә боера. Тимер Котлыгның кече туганы Гаязетдин белән бергә Русиягә качкан Идегәй уллары, өч меңле гаскәр белән кайтып, Олуг Мөхәммәдкә һөҗүм итәләр. Олуг Мөхәммәд җиңелеп Кырымга кача, ә җиңүче Гаязетдин Сарай тәхетенә чыга, әмма озак ханлык итә алмыйча үлә (1437). Шуннан соң ханлыкка Тимер Котлыгның оныгы Кече Мөхәммәд чыга. Тәхетен кайтарып алырга омтылган Олуг Мөхәммәд белән яңа хан Кече Мөхәммәд арасында сугыш кабына. Ахырда солых төзелеп, солых буенча, Идел буе Кече Мөхәммәдкә, Кырым Олуг Мөхәммәдкә тиеш була. Олуг Мөхәммәд янә әмир Хәйдәр һәм Туктамышның токымы булган Сәед-Әхмәд белән низагка керә. Тегеләр, гаскәрләрен берләштереп, Олуг Мөхәммәдкә яу чабалар. Каршы торудан өметен өзгән Олуг Мөхәммәд хан, Кырымны ташлап, Казан юнәлешендә юл ала.

[6] Ш. Мәрҗани бу вакыйганы икенчерәк сурәтли. Белев шәһәренә килеп урнашкан әүвәлге ханның килүен «Русия хөкемдары Василий II... башта хуш күреп хөрмәт итеп, шул урында торырга рөхсәт һәм халкына күчеп килергә яхшы урын бирә». Ләкин Олуг Мөхәммәд, дошманнан саклану һәм кышкы суыктан ышыклану өчен, Иделнең Тау ягында боздан крепость ясап, су коеп ныгыткач, урыслар шиккә төшәләр һәм ханны бу җирләрдән куа башлыйлар. «Олуг Мөхәммәд хан идарә иткән вакытта аның ярдәме һәм указы белән Русия хөкемдары булуына, ханнан кат-кат күргән ихтирамына карамастан, ул (Василий II) татарларны мәмләкәтеннән чыгарырга зур көч куйган».

М. Г. Худяков, мәсәлән, Василий II нең Олуг Мөхәммәдне кууын Мәскәү хөкүмәтенең ул вакыттагы Сарай ханына, Олуг Мөхәммәднең дошманына турылык саклау ихтималында күрә.

[7] Урыс елъязмаларының берсендә сугыш нәтиҗәләре болай тасвирлана: «... и множество бысть вой русских, а татар велми мало; и под горой приидоша русстии полцы, и выехша татарове и почяша их сечи, а иные побегоша, и убиша Руси много велми... побиша рать русскую, тогда убиша бояр и князей множество, князь великий отиде в мале дружине».

Р. Фәхретдин бу могҗизаи җиңүнең сәбәпләрен нилектәндер шәрехләп тормый. Кырык меңле гаскәрне бер меңле сугыш-

чылар төркеменең пыран-заран китерүен, ихтимал, болай гына аңлатырга мөмкин. Көчләрнең чамасыз тигезсезлеген истә тотып, урыс воеводалары Олуг Мөхәммәднең сугышу ихтималын башларына да китермиләр. Әмма өметсез хәлдәге хан иярченнәренә, «беткән баш беткән» дигәндәй, аҗагандай һөҗүм итүдән башка чара калмый. Ә аннары инде сугышның язмышын кинәтлек, паника, Урда татарларыннан канга сеңгән традицион курку хәл итә.

[8] Башка чыганаклар «Белев сугышы» датасы итеп 1437 елның 5 декабрен күрсәтәләр.

[9] Бу турыда урысның мәшһүр тарихчысы С. М. Соловьев болай дип язган иде: «После этой победы Улу-Махмет пошел степью мимо русских границ, переправился через Волгу и засел в опустелой от русских набегов Казани, где поставил себе деревянный город на новом месте».

[10] Казан ханлыгы халкының ничек аталуы хакында мәшһүр урыс тарихчы-этнографы Н. И. Воробьев фикере игътибарга лаек: «Название татар (официальное со стороны русских население Золотой Орды) по отношению к населению Волжско-Камского края начинает применяться русскими лишь с того момента, когда после организации Казанского ханства и блестящих побед этого ханства над русскими, казанские татары заслонили собой настоящих татар Золотой Орды, и все прежние отношения, которые были выработаны русскими по отношению к Золотой Орде, были перенесены на Казанское ханство и его население. Живущие там финские племена называют их не татарами, а по-прежнему «болгарами». Луговые черемисы (мари) до сих пор называют татар «суас», а вотяки — «бигер», т. е. «болгар». Воробьев өстәп тагын болай ди: «Татары же себя никогда не называли этим именем, а наоборот, казанские татары это название считали обидной кличкой».

[11] Казан ханлыгының барлыкка килү вакыты һәм аны нигезләүченең кем булуы турында тарихчыларда бердәм фикер юк. Гадәттә, күпчелек тарихчылар (Рычков, Карамзин, Соловьев һ. б.) ханлыкның барлыкка килүен 1436 яки 1437 ел белән билгеләләр һәм нигезләүче итеп әүвәлге Сарай ханы Олуг Мөхәммәдне күрсәтәләр. Икенче тараф (аның төп вәкиле проф. Вельяминов-Зернов), Воскресенский һәм Никоновский елъязмаларына таянып, Казан ханлыгының 1445 елда Олуг Мөхәммәднең улы Мәхмүд тарафыннан төзелү фикерен алга сөрәләр. Өченче версия буенча, Казан ханлыгы, Болгар дәүләтенең варисы буларак, XIV йөзнең ахырында — XV йөзнең башында оешкан, ә 1445 (1436—1439?) елда династияләр генә алмашынган. Риза Фәхретдин исә оешу елы итеп 1439 елны һәм нигезләүче итеп Олуг Мөхәммәдне таный.

Болгар-Казан эзлеклелеген һәм бер үк вакытта Олуг Мөхәммәд версиясен таныган Н. И. Воробьев болай дигән иде: «Основатель ханства — Улуг Мухамед, несомненно, дал краю только новую политическую и военную организацию, воспользовавшись уже готовыми общественными формами, ибо мы видим, что только что организованное ханство становится могущественным и занимает прочное положение в Восточной Европе, заменив для Москвы, например, на некоторое время даже Золотую Орду. Этого, конечно, не могло бы произойти, ежели бы Улуг Мухамед опирался только на свою 3000 дружину, с которой он пришел из Крыма, и не имел вполне организованного в общественном и экономическом отношениях населения, которому нужно было дать только политическую организацию, каковую и внес Улуг Мухамед».

[12] Мәскәүдә бу килешүнең шартлары игълан ителгәч, урыс халкы арасында төрле шомлы хәбәрләр, имеш-мимешләр тарала: янәсе, Василий II Казан ханына бөтен Мәскәү кенәзлеген биреп, үзенә Тверьне генә калдырырга ант иткән. М. Г. Худяков, Василий II нең әсир төшүен һәм төзелгән килешүнең нәтиҗәләрен тәфсилләп тикшереп, Мәскәү хөкүмәтенең Казан ханлыгына карата зур ташламаларга баруы турында яза. Бу ташламалар аркасында, ди ул, Василий II хөкүмәте татарларга «Касыйм ханлыгы» төзетергә мәҗбүр була, яңа ханлыкка контрибуция түли, урыс җиренә урнашкан татар шаһзадәләрен һәм аларның даирәсен «асрый», төрлечә буйсыну галәмәтләре күрсәтә. «Ни о каком противопоставлении татарам побежденный Василий в то время не смел и мечтать, и татары, назначенные в русские города, совершенно не думали забывать своей национальности. Они собирали контрибуцию — окуп за освобождение великого князя из плена и, неся административную службу, получали «кормление» — доходы с русской земли; таким образом татарам удалось переложить содержание части своих соотечественников на русский народ».

[13] Олуг Мөхәммәднең улы Мәхмүд тарафыннан үтерелүе бик шикле. Бу турыда «Казанский Летописец» авторы язган уйдырмаларны фаш итеп, М. Г. Худяков болай ди: «Казанский Летописец» с избытком пропитан фанатической ненавистью к казанцам и всячески старается представить их злобными дикарями и осмеять несчастия, в которые им приходилось иногда попадать. С большим удовольствием составитель «Казанского Летописца» нагромождает нелепые вымыслы один на другой, стараясь намеренно поразить читателей зверством татар и смакуя

смешные и нередко скабрезные подробности, сочиненные им же самим».

М. Худяков раславынча, Касыйм һәм Ягъкуб шаһзадәләр әтиләрен «үтергән» Мәхмүдтән качып китмиләр, бәлки әлеге килешүне тормышка ашыру һәм Василий II не тәхеткә кайтару өчен Русиягә махсус киләләр.

[14] Казан ханлыгы тарихын үтә җентекләп һәм объектив өйрәнгән М. Г. Худяков Олуг Мөхәммәдне, шәхес һәм дәүләт эшлеклесе буларак, бик югары бәяли, аның Сарайда һәм Кырымда идарә итүләрен бик уңышлы («блестяще») дип билгеләп үтә. Ә Казан ханлыгы төзү турындагы планын «даһи» план дип атый. «План основания Казанского ханства можно назвать гениальным, потому что хан Мухаммед понял особенность древнего культурного местного населения, и, задумавши восстановить мусульманское государство в Среднем Поволжье, правильно оценил шансы на его прочное существование. Дальновидный проект был выполнен с огромным умением, и вновь созданное государство оказалось очень могущественным. Военный талант и организаторский гений основателя Казанского ханства дали ему возможность поставить величие государства сразу на должную высоту и достигнуть такой полноты верховенства над Россией, которая заставила считаться с Казанью более, чем с ханством Сарайским. Всем этим государство казанских татар было обязано Улу Мухаммеду».

[15] М. Г. Худяков фикеренчә, Олуг Мөхәммәд Нижний Новгородтан кайтканнан соң Казанда үлә. Кайбер тарихчылар Олуг Мөхәммәднең беркайчан да Казанда булмавы һәм, шулай булгач, берничек тә Казан ханлыгына нигез сала алмавы турында фикерне алга сөрәләр. Әлбәттә, һәр ике тараф та бер-берсенә һәрдаим каршы килүче урыс елъязмаларына һәм чыганакларына таяна.

МӘХМҮД ХАН

(?—1464 елда вафат)

Казан мәмләкәтендә хөкүмәт иткән ханнарның беренчесе Олуг Мөхәммәд хан булып, икенчесе исә ошбу Мәхмүд хандыр[1]. Мәхмүд хан атасы Олуг Мөхәммәд хан вафаты соңында Казан тәхетенә чыгып хөкемдар булды[2]. Ошбу вакыт үзенең тумалары Касыйм һәм Ягъкуб Мәхмүд ханнан качып киттеләр[3]. Берәр ел чамасы чиркәс җирләрендә йөреп, соңыннан аталары Олуг Мөхәммәд хан хозурында арадашлык итеп, әсирлегеннән коткарылган һәм яңадан Мәскәү кенәзлегенә кайтарылган Мәскәү кенәзе Василий II хозурына бардылар.

Василий боларны хуш кабул итте вә Ока суы буенда күбесе мукшы халкыннан гыйбарәт булган бер шәһәрне биреп урнаштырды. Әлеге шәһәр шаһзадә Касыймга нисбәт ителеп, «Касыйм шәһәре» дип шөһрәт алды[4].

Яңа мәйданга чыгып вә баш күтәреп килгән Казан дәүләтенең Сарай кебек зураюыннан, Бәркә, Үзбәк һәм Җанибәк ханнар кебек ханнар килеп чыгып, Мәскәү кенәзлеген яңадан кул асларына алу ихтималыннан курыккан Мәскәү кенәзе шаһзадәләрне һәм, бигрәк тә, Касыймны Казан ханлыгына каршы корал итәргә омтылды[5]. Касыймның хезмәте дә Казан ханлыгы эченә фетнә салып торудан гыйбарәт иде. Касыйм хан Казанда булган нәфүзле, ягъни йогынтылы түрәләр вә мирзалар белән хат язышып, хәбәрләшеп тора, ханнарны урыннарыннан төшереп, араларын боза һәм сугыштырыр өчен һәрвакыт игъва итә, ягъни котырта иде.

1446 елда Мәхмүд хан гаскәреннән 700 кадәр кеше Вологда вилаятендә булган Устюг шәһәренә барып, сугышып алдылар да, соңыннан мәшһүр шәһәрне бик күп акча бәрабәренә сатып кайтып киттеләр. Фәкать кайткан



Мәхмүд хан. Рушан Шәмсетдинов рәсеме.

вакыт юлда Ветлуга суын чыкканда казага очрап, суга батып вафат иттеләр. (Карамзин. Т. 5, 390—391 б.)

Русларның иске тарихчылары үз диннәренә якын һәм үз милләтләре хакында шәфкать вә хәмиятле, ягъни яклаучан булган ханнар турында — болар христианнарны дошман күрәләр һәм христианнарга бик каты иделәр, дип билгеләп үтәләр. Бу исә аларда бер гадәттер. Алар карашынча, гакыллы вә яхшы хан булыр өчен үз мәмләкәтендә христиан руханиларына чикләнмәгән ирек белән йөрергә ихтыяр бирелергә тиешле, руханилар да, хәтта ханнарның сарайларына кадәр кереп, хатын вә кызларны өшкереп йөрсеннәр. Шул сәбәпле Рычков, Карамзин вә башкалар Мәхмүд хан хакында: христианнарга бик дошман, аларны бер дә сөйми иде дип белдерәләр, әмма христианнар хакында нинди золым күрсәткәндер, аны исә әйтә алмыйлар. Шуның өчен русларның иске тарихчыларының сүзләренә һәрвакыт сак килергә һәм һәрьяклы тикшереп хөкем йөртергә тиешле, тиешенчә әһәмият бирелмәсә, алдану бик җиңелдер[6].

Мәхмүд хан вафаты хакында күз уңыбызда булган русча тарих вә энциклопедияләрдә мәгълүмат күренмәде. «Мөстәфадел-әхбар»ның бәянына күрә (Т.1, 127 б.), 868 һиҗридә вафат булмыштыр[7]. Бу ел миляди белән 1463—1464 елларга туры килә. Кайбер рус тарихчылары Мәхмүд хан исемен «Махмутек» сурәтендә телгә алалар.

ИСКӘРМӘЛӘР (МӘХМҮД ХАН):

[1] Инде Олуг Мөхәммәд турындагы мәкаләдә Казан ханлыгының кайчан оешуы һәм нигезләүчесенең кем булуы хакында мәгълүмат бирелгән иде. Бер төркем тарихчылар, ханлыкның әүвәлге хөкемдары Олуг Мөхәммәд, икенчеләре, аның улы Мәхмүд булган, дип раслыйлар.

Урыс чыганакларында Мәхмүднең исеме еш кына кечерәйтелгән исем белән «Махмутек» дип йөртелә.

[2] Мәхмүд хан атасы исән вакытта ул атаклы гаскәр башлыгы булып таныла. Василий II не әсир итеп алган мәшһүр Суздаль сугышында (1445) башкомандующийлык вазифасын шаһзадә Мәхмүд үти. Урыс елъязмалары Мәхмүд исемен атасы Олуг Мөхәммәд белән еш кына янәшә телгә алалар. Белев сугышында (1437) җиңүне дә кайбер елъязмалар Олуг Мөхәммәдкә генә түгел, аның улы Мәхмүдкә дә нисбәт итәләр.

[3] Касыйм белән Ягъкубның «качып китү» сәбәпләре «Олуг Мөхәммәд» мәкаләсенең искәрмәсендә ачыкланган иде инде. Бу

ике бертуганның Русиягә китүе килешүне җиренә җиткерү һәм Василий II не тәхеткә кайтару өчен булган булса кирәк. Һәрхәлдә М. Худяков бу версияне бик төпле нигезли.

[4] Касыймга Русия җиреннән шәһәр («Касыйм» дип атала башлый) бирү дә Казан белән Мәскәү хөкүмәтләре арасындагы килешү шартларына нигезләнгән булуы ихтимал.

[5] М. Худяков бу версияне кире кага.

[6] Р. Фәхретдин мәкаләсендә Казан ханлыгының Мәхмүд хан дәверендәге хәле ачыкланып бетми. Хәлбуки ул хөкемдар булган чорда Мәскәү һәм Казан арасында тынычлык хөкем сөрә, 20 ел дәвамында (1446—1466) ике хөкүмәт үзара хезмәттәшлекне, сәүдә мөнәсәбәтләрен ныгыталар, Казан Иделдәге халыкара сәүдәнең төп үзәгенә әверелә. 1445 елда урыс хөкүмәте белән төзелгән уңышлы килешү Русиядән акча килүне тәэмин итә һәм Казанда сәүдә эшләрен киңәйтүдә зур роль уйный. Тора-бара Казан шәһәре бөтен Көнчыгыш Европаның товар алмашу үзәгенә әйләнә: бирегә Урта Азия, Себер, Персия, Кавказ арты, бөтен Идел буе һәм Русиядән мал һәм сәүдәгәрләр агыла. Казанда ел саен үткәрелә торган традицион ярминкә Болгар заманындагы халыкара ярминкәне хәтерләтә, аның узган гасырлардагы данын дәгъвалый. Урыс сәүдәгәрләре тарафыннан «Гостиный остров» дип аталган һәм Казан шәһәренә каршы урнашкан бу Идел утравында ярминкә җәй көне, су кайткач үткәрелгән. Биредә язгы ташу вакытында су астында кала торган сәүдә йортлары, амбарлар, складлар урнашкан булган.

Мәхмүд хан заманында Казан ханлыгы зур хәрби көч хасил иткән, бу үз чиратында тыныч тормыш һәм сәүдәне гарантияләгән, ханлыкка тирә-яктан бик күп кешеләрне җәлеп иткән. Бу дәвердә ханлык башкаласы баеган, зур шәһәр булып үскән, ислам мәдәниятенең халык кайнап торган үзәге булып җитешкән. Мәхмүд дәверендә Казан ханлыгының дәүләт структурасы тулысынча калыпланган, дәүләтнең эчке төзелеше оешкан һәм ныгыган, дип исәпләргә нигез бар.

[7] Мәхмүд ханның үлү вакыты төгәл билгеле түгел, кайбер чыганаклар аның әле 1461 елда тәхеттә утыруын, 60 нчы елларда вафат булу ихтималын искәртеп китәләр. Ул заманның гадәте буенча, Мәхмүднең тол калган хатыны иренең энесе, Ока елгасы буендагы «Касыйм» («Мещар») шәһәре, Касыйм ханлыгы хөкемдары Касыймга кияүгә чыгарга тиеш булган.

ХӘЛИЛ ХАН

(? — 1467 елда вафат)

Мәхмүд хан вафаты соңында угылы Хәлил хан тәхеткә чыккан иде. Ләкин 1467 елларда үзенең бер тумасы шаһзадә Ибраһим моңа каршы чыкты. Шуннан башка хәле мәгълүм түгелдер[1].

ИСКӘРМӘЛӘР (ХӘЛИЛ ХАН):

[1] Мәхмүд хан үлгәннән соң, аның Хәлил һәм Ибраһим исемле ике улы кала. Тәхеткә Хәлил чыга. Ләкин ул шулкадәр кыска вакыт идарә итә ки, хәтта кайбер тарихчылар андый ханның чынлыкта булу-булмавына шик белдерәләр. Урыс елъязмаларында Хәлил исеме бөтенләй телгә алынмый диярлек. Ләкин аның исеме XVI гасыр сәяхәтчесе Сигизмунд Герберштейнның «Записки о Московии» дигән хезмәтендә Shelealek («Хелеалек») рәвешендә телгә алына. Шулай ук К. Ф. Фукс та үзенең 1817 елгы әсәрендә, Казан ханнарының борынгы татарча исемлегеннән файдаланып, Хәлил исемен телгә ала. Һади Атласи Мәхмүд белән Ибраһим арасында Хәлилнең булуында һич шөбһә юктыр, дип белдерә, аның Олуг Мөхәммәд оныгы икәнен, өч ел чамасы ханлык итүен искәртә. Шул ук мәгълүматны Ш. Мәрҗанидә дә очратабыз. Хәлил Тимер мирзаның кызы, нугай принцессасы Нурсолтанга өйләнгән була. 1467 елда үлгән, дип исәпләнә. Балалары булмый.

ИБРАҺИМ ХАН

(?—1478 елда вафат)

Ибраһим хан, Мәхмүд ханның угылы булып, 1467 елда тумасы Хәлил ханны урыныннан төшерде, Казан мәмләкәтенә хан булды[1]. Аның анасы Мәскәү кенәзе хезмәтенә кергән Касыйм хан никахында булып, Ибраһим хан Касыйм ханның үги угылы иде (Карамзин. Т. 5., 17 б.).

Казанда булган бу ханлык дәгъваларын форсат итеп, Мәскәү кенәзе хезмәтендә булган Касыйм хан Казанның бөек адәмнәре, түрә вә мирзалары белән хат язышыр вә үзен хан итеп куюю тугрысында өмет итәр, һәртөрле вәгъдәләр кылыр иде. Ахыр чиктә яңа хан Ибраһимга каршы булган бер фирка, ягъни төркем, Ибраһим ханны тәхетеннән төшерергә карар кылып, аның урынына хан булыр өчен Касыймны Казан шәһәренә чакырдылар[2]. Бу хәбәргә Касыйм бик нык шатланды һәм великий кенәз Иван III гә сөйләде. Иван исә бу рәвештә татарны татар белән, мөселманны мөселман белән сугыштыру юлы ачылу хәбәреннән мәмнүн, ягъни шат булып, Касыймны үзенең татарлары белән берлектә Казан шәһәренә барыр өчен хәзерләде һәм дә ихтималдан ихтият өчен, ягъни ул-бу булмагае, дип рус гаскәре тәртип итте. Боларның барысы кенәз Оболенский командасында 1467 елның 14 сентябрендә сәфәр иттеләр[3]. Касыйм исә, үзе юл күрсәтеп, рус гаскәрен алып барды[4].

Касыйм хан кинәттән Казан шәһәренә һөҗүм итеп керү теләге белән барган хәлдә, тәхеткә яңа чыккан Ибраһим хан каяндыр Касыймның Мәскәү гаскәре белән килүен белеп, каршы чыкты. Ике гаскәр Идел буенда очраштылар. Касыйм вә рус гаскәре кай җирдән чыгарга

теләсәләр дә, Ибраһим хан шул җирдән боларга каршы торды вә Идел аркылы чыгарга бөтенләй юл бирмәде.

Касыйм вә Русия гаскәренең ошбу сәфәрләре гаять мәшәкатьле булды. Бер яктан, Ибраһим хан гаскәре ук вә мылтык атып күп һәлакәт китерде вә, икенче яктан, суык яңгырлар яуганлыктан йөрергә мөмкинлек булмады. Шул сәбәпле хайваннарның вә үзләренең азыклары бетеп, бик каты ачыктылар, хәтта үлгән ат итләре ашарга мәҗбүр булдылар вә ахыр чиктә чар-начар, ягъни теләр-теләмәс кире кайтып киттеләр[5]. Ибраһим хан, боларның артыннан куарга кыюлыгы җитмәсә дә, үзенең бер өлеш гаскәрен Русия чигендә булган Галич шәһәренә җибәрде. Ләкин бу җирләргә Мәскәү кенәзенең каравыл гаскәре куеп өлгерүе сәбәпле, зур зарар китерә алмыйча, кире кайтып киттеләр[6].

Моннан соң Иван, Ибраһим ханны зәгыйфьләндерер өчен, Мәскәү гаскәрен җыеп, Казан тарафына кабат сәфәр итсә дә, Литва кенәзенең Мәскәүгә килүен ишетеп, борылып кайтып китте, бер өлеш гаскәрен аерып, Вятка вилаятенә, ягъни өлкәсенә җибәрде. Бу гаскәр Кама белән барып, Вяткадагы ислам гаскәре белән сугышты, аны җиңде, күп сугышчыларны үтереп, калганнарын әсир итеп алып китте[7]. Ак Идел кушылган җирдәге ислам сәүдәгәрләренең сәүдә көймәләрен ганимәт, ягъни трофей итеп алдылар. Шушы урында (Казаннан 40 чакрым җирдә) 200 ләп кешелек Казан гаскәре очрады, аларны да үтереп бетерделәр. Шунда боларның Калибә исемендә баһадирлары шәһид китте, вә Хуҗам Бирде[8] исемле сәргаскәре, ягъни гаскәр башлыгы мәскәүлеләргә әсир төште. Руслар Вятка аркылы Мәскәүгә кайтып киттеләр. Моннан соң Казаннан янә гаскәр килеп, Вятка тарафларын яңадан Ибраһим хан кулы астына керттеләр[9]. Бу вакыйга 1468 елда булды.

1469 елда яз көне Мәскәү кенәзе Иван Казан шәһәренә бару өчен хәзерләнергә кереште вә гаскәрен Нижгород шәһәренә җыйды. Гаскәр башлыгы бөтен гаскәр белән сәфәр итәргә торган бер вакытта Мәскәүдә кенәз тарафыннан адәм килеп, кенәзнең Казан сәфәреннән туктап торырга боерганын ирештерде. Моның сәбәбе исә шушы сугышның төп сәбәпчесе булган Касыйм вафат итеп, хатыны вә Ибраһим ханның анасы Мәскәү кенәзенә барып сугышны туктатырга үтенүе һәм Ибраһим хан белән араларны солых белән тәмам итәргә вәгъдә бирүе булмыштыр[10]. Иван исә Ибраһим хан анасының васитасы

Ибраһим хан. Рушан Шәмсетдинов рәсеме.

илә, ягъни арадашлыгы белән Казанны үз кул астына алу нияте белән сугышны туктатырга муафыйк күрде (Карамзин. Т. 6, 17 б.). Ләкин гаскәр башлыгы бу хәбәрне сугышчыларга җиткергәч, алар әлеге фәрманны кабул итмәделәр, «без мөселманнардан үч алмыйча торып кайтмыйбыз!» диделәр һәм, Иван Руно исемле бер затны үзләренә сәргаскәр итеп куеп, көймәләре белән Иделгә киттеләр[11]. (Болар Иван һәм сәргаскәр әмере белән киткән булырлар, фәкать Иван, Касыйм хатынына биргән вәгъдәсенә күрә, асылда сүзендә тормаганлыгын яшерү өчен, шушы рәвештә хәйлә корган булса кирәк. Рус тарихларында мондый хәлләр яшерелсә дә, «без капчыкта ятмас» мәкаленчә, хакыйкатьләре аңлашыладыр).

21 майда Казан астына килеп җитеп, Казан халкының һич нәрсәдән хәбәрләре булмаган хәлдә, төнлә Казанга кереп туры килгән бер кешене үтерергә вә таларга керешәләр, рус әсирләрен азат итәләр, ут төртәләр. Мөселманнар, куркулары сәбәпле, хатын-кыз, бала-чагалары белән мәчетләргә кереп тулалар, руслар исә шул мәчетләргә ут төртәләр, эчләре адәм җаны белән тулы хәлдә һәммәсе бергә өелешеп яналар[12].

Моннан соң руслар, үзләренең көймәләренә утырып, Нижгород шәһәренә кайтып киттеләр вә Коровнич исемле утрауга төшеп, бер һәфтә, ягъни атна микъдарында истирахәт, ягъни ял иттеләр. Руслар бирედә үзләренең сәргаскәрләрен гаепли һәм аңа начар уйларын белдерә башладылар: «Казан шәһәренә ут төрткәннән соң эченә керергә дә мөмкин иде, шул форсатны кулдан ычкындырдык, инде бу кадәр ганимәт маллары, ягъни трофейлар белән монда нишләп торабыз, ни өчен туры Мәскәүгә кайтып китмибез? Болай бушка гомер кичерүебез файдалы түгел, ихтимал, Ибраһим хан, гаскәр җыеп, артыбыздан килеп басар!» — дип шауларга һәм кычкырышырга керештеләр. Чыннан да, боларның бу фаразлары дөрескә чыкты. Казан шәһәреннән качып кайтып килүче бер рус әсире болар янына җитеп, Ибраһим ханның башкорт вә башкалардан гаскәр җыйганын, корыдан һәм судан килергә чыкканын хәбәр итте[13]. Моны ишетү белән руслар арасында зур фетнә купты, ахыр чиктә Казан гаскәренә каршы торырга хәзерләнә башладылар. Озак вакыт үтмәде, Казан гаскәре күренә башлады. Руслар бу хәбәрне Нижгородта булган гаскәр башлыгына һәм Мәскәүдәге великий кенәзгә ирештерделәр. Шуңа күрә Иван һәр тарафтан гаскәр хәзерләргә кереште вә, Казан өстенә

барыр өчен, дип, Вяткада булган ар вә чирмешләргә дә фәрман җибәрде. Ләкин Ибраһим ханга бигать биреп, ягъни буйсынуларын белдереп ант итүләрен сәбәп итеп, Вятка халыклары Иван фәрманын кабул итмәделәр. Ахыр чиктә ашар әйберләре бетү вә Вятка халыкларының ярдәм белән килмәячәкләре мәгълүм булгач, Мәскәү гаскәре Нижгород шәһәренә чигәргә мәҗбүр булды.

Шул вакыт боларга Касыйм хатыны вә Ибраһим ханның анасы булган бикә очрап: «Менә мин Иван яныннан киләм, Иван теләгенә муафыйк сурәттә угылым Ибраһим ханны солых иттерермен, моннан соң сугыш булмас!» — диде. Руслар ашарга утырганнар иде, кисәктән Казан гаскәре килеп чыкты. Бу вакыт руслар бик мәшәкать белән хәзерләнделәр, корыда вә суда сугыш башланды. Мәскәү гаскәренә ярдәм өчен көймәләр белән килгән кенәз Даниил Ярославский командасында булган гаскәрне Ибраһим хан үзе уратып алды. Менә шул вакыт кыямәт көне мисалында куркыныч сугыш булды. Рус гаскәре җиңелеп, үтерелеп, әсир төшеп, бөтенләй бәрбад булып бетте, ягъни тар-мар ителде[14].

Шул ук ел көз көне Иван Казан өстенә яңадан гаскәр җибәрде. Мәскәү гаскәре кинәттән Казанга ирешеп, 1 сентябрьдә шәһәр янында күренде. Ибраһим хан, үзенең әзер түгел икәнен белеп, Мәскәү сәргаскәреннән солых сорарга мәҗбүр булды һәм Казанда булган рус әсирләре азат ителү шарты белән солых ясалды[15].

1478 елда Иван Новгород эшләре белән мәшәкатьләнгән вакытта Казанга, «Мәскәү кенәзе Иван III Новгородта җиңелгән һәм, яраланып, көч-хәл белән качып котылган», дигән бер хәбәр җитеште. Ибраһим хан, мондый форсатны әрәм итмичә, бәлки файдаланып калу теләге белән, солых шартларын бозып, Мәскәү кул астында калган Вяткага гаскәр җибәреп, һөҗүм иттерде. Соңра Иван турында ишетелгән хәбәрнең ялган икәнен белеп, Вяткада булган гаскәрен кире чакыртып кайтарды[16].

Иван исә моның үчен алыр өчен Нижгородтан Идел белән Казан шәһәренә гаскәр җибәрде. Фәкать көчле җил вә яңгырлар булу сәбәпле, Мәскәү гаскәре бу сәфәрдә күп зәхмәт татыды. Ул арада Ибраһим хан Мәскәүгә кеше җибәреп, Иван теләгенә муафыйк солых ясадылар. Ләкин шартлары ниләр булуы мәгълүм түгелдер[17].

Солых ясалып тәмам булганнан соң күп гомер үтмәде, Ибраһим хан вафат итте. Бу һиҗри белән 883, миляди белән 1478 елда булды. Ибраһим ханның хөкемдарлыгы

җөмләсе, ягъни барлыгы 11 ел микъдарындадыр. Моның вафатыннан соң Казан хөкүмәте мәгънәви җәһәттән бөтенләй Мәскәү кенәзлеге химаясендә калды, ягъни аның кулы астында саклана торган булды[18].

ИСКӘРМӘЛӘР (ИБРАҺИМ ХАН):

[1] М. Г. Худяков язганча, яшәп килгән гадәт буенча, Ибраһим хан мәрхүм абыйсының, ягъни Хәлилнең тол калган хатыны Нур Солтанга өйләнә.

[2] Сөяләлә, ягъни династияләр, алмашыну күзлегеннән карaганда, бу абзый (дядя) белән аның энесе (племянник) арасында тәхет өчен көрәш буларак төсмерләнә. Ләкин биредә эш катлаулырак булган булса кирәк, чөнки Казан ханлыгы идарәче даирәләре арасында XV йөзнең алтмышынчы елларында ике төркем (партия) барлыкка килә һәм алар арасында хакимият өчен туктаусыз көрәш бара. Шуны истә тотып, Ш. Мәрҗани болай ди: «Гасырында (Ибраһим хан заманында.— Р. Ә.) Казан түрәләреннән Габделмөэмин-бәк исемле кеше, берничә бәк белән берләшеп, дөрес ният беләнме яки алдапмы, Ибраһим хан өстеннән яшерен шикаять кылып, Русия мәмләкәтендәге Касыйм ханны үзләренә ханлыкка чакыралар». Урыс тарихчылары С. М. Соловьев һәм Вельяминов-Зернов тәхет өчен көрәш инициативасын Габделмөэмин бәк һәм аның төркеме белән бәйлиләр, Карамзин исә Касыймның үзенең омтылышларын алгы планга куя. Худяков фикеренчә, Габделмөэмин-бәк тарафдарлары аз булган һәм фирка (партия) аерымлыклары иҗтимагыйдан да бигрәк шәхси характер төсен алган.

[3] Сүз урыс кенәзе Иван Васильевич Оболенский-Стрига турында бара. Ш. Мәрҗани бу датаны 1468 ел белән (873 һиҗри) бирә.

[4] Русиянең кечкенә удел кенәзе Касыйм, Казан тәхетен дәгъва итсә дә, үз биләмәсендәге хәрби көчләрнең аз булуы сәбәпле, ярдәм сорап Мәскәү хөкемдарына мөрәҗәгать иткән булса кирәк. Әлбәттә, Русия хөкүмәте бу адымны бик хуплый, чөнки Казан ханлыгының эчке эшләренә турыдан-туры тыкшыну мөмкинлеге туа. Әлеге чор казанлыларның 1445 елда Василий II не әсир иткән вакытларыннан нык аерыла. Мәскәү хөкүмәте 1462 елда бөек кенәз булып тәхеткә менгән Иван III заманында

бик көчәя һәм Казан ханлыгына каршы агрессив сәясәт алып бара башлый. Алтмышынчы еллардан башлап Мәскәү — Казан мөнәсәбәтләре яңа фазага керә. М. Худяков сүзләре белән әйткәндә, әгәр Олуг Мөхәммәд заманында казанлылар мәскәүлеләргә каршы үзләре актив хәрәкәт итсәләр, Мәхмүд хан дәверендә үзара тигезлек саклап, тыныч мөнәсәбәттә торсалар, ә инде Ибраһим хан чорында мәскәүлеләр Казанга каршы үзләре һөҗүмгә күчәләр. Мәскәү хөкүмәтенең кечкенә генә сөяләлә дәгъвалары-ызгышларына катыша башлавы аның бөек мәмләкәтчелек сәясәтенә тулаем туры килә һәм бу тыкшыну ике дәүләт арасында канкойгыч сугышлар башлануга җитди этәргеч бирә.

[5] Урыс гаскәренең бу җиңелүен М. Худяков Ибраһим ханның уңышлы сәяси һәм хәрби адымнарында күрә, аның үз халкын оештырып, баскынчыларга милли хисне күтәрү хисабына отпор бирүен шәрехли. Каршы фирка (оппозиция) милли хис күтәрелү алдында көчсез була. Ә бәлки, ди галим, Касыймга барыннан да бигрәк Русия хөкүмәте тарафыннан үзенә кылынган ярдәм зыян китергәндер.

[6] С. М. Соловьев бу турыда болай ди: «Казанцы спешили отомстить и немедленно явились под Галичем, но получили скудную добычу, ибо все окружные жители сидели, запершись в городе; городов же брать не могли, потому что великий князь успел разослать заставы в Муром, Нижний, Кострому и Галич».

[7] Сүз өлешчә урыс гаскәрләренең Казан ханлыгына кергән чирмеш (мари) территориясендәге хәрби операцияләре турында бара. Н. М. Карамзин бу җәза экспедициясен болай тасвирлый: «Россияне истребили все, чего не могли взять в добычу: резали скот и людей, жгли не только селения, но и бедных жителей, избирая любых в пленники».

[8] Урыс чыганакларында бу зат «Ходжум-Берде» дип күрсәтелә.

[9] «Алмаш уңыш» белән барган бу хәрби хәрәкәтләр ике дәүләт арасындагы мөнәсәбәтләрне тагын да кискенләштерәләр, тоташ сугышларның бер чылбырын тәшкил итәләр.

[10] Касыймның үлүе белән Казан тәхете өчен Касыйм — Ибраһим көрәшенә, әлбәттә, чик куела. Ләкин Мәскәү хөкүмәте өчен Казан ханлыгына каршы агрессив сәясәттә Касыйм исә бер гади корал гына булып чыга. Казан хөкүмәте Касыйм

артында кемнәр торганын бик ачык аныклый. көн тәртибенә инде дәүләтнең бәйсезлеге мәсьәләсе клеп басканлыгн аңлап, үзен саклау өчен бөтен хәрби һәм дипломатик чараларны эшкә җигә.

[11] 1469 ел — Мәскәү хөкүмәтенең Казанга ясалган беренче зур яу елы. Шуннан башлап мондый яулар баскынчылар өчен бер традициягә әверелә. Хәрби хәрәкәтнең планы: Казанны Иделнең югары һәм түбән агымыннан кысып, «келәшчәгә» алу була. Бу максаттан чыгып, Устюгта һәм Нижнийда ике зур аерым гаскәр төзелә.

[12] С. М. Соловьев тасвирлаганча, урыс сугышчылары «бросились сечь сонных татар, грабить, брать в плен, освободили христианских пленников... и зажгли посады со всех сторон; татары, не хотя отдаваться в руки христианам и больше жалея о богатстве своем, запирались со всем добром, с женами и детьми в мечетях и там сгорали».

[13] Соловьев сүзләре белән әйткәндә, бу качак әсир болай дигән: «Собрался на вас царь казанский Ибрагим со всею землею, Камскою, Сыплинскою, Костяцкою, Беловолжскою, Вотяцкою, Башкирскою». Димәк, ватан иминлеген саклау өчен, Ибраһим хан коточкыч зур яуга каршы үзенең бөтен көчен туплый алган («со всею землею»).

[14] Казан ханлыгы тарихында бик сирәк булган бу су өсте сугышы Ибраһим хан гаскәренең зур җиңүе белән тәмамлана. Урыс елъязмачысы болай ди: «Бой бысть на Волзе с устюжаны и с великого князя бояры дворными, татарове устюжан били, и детей боярских переимали: тогда же убили Микиту Костянтиновича и Юрла Плещеева полонили и его товарищов». Устюг гаскәренең калдыклары гына качып котыла һәм Нижгород чирүенә барып кушыла.

[15] Мәҗбүр булу мәсьәләсе бәхәсле. Солых Русия хөкүмәтенә дә зарур була, чөнки, бердән, кышка каршы Казанны озак камауның уңыш ягы чамалы, икенчедән, Иван III нең новгородлылар белән «борчагы пешми», өченчедән, бу вакытта Литва кенәзе Казимир Мәскәүнең дошманы, ул Алтын Урда ханы Әхмәд белән сөйләшүләр алып бара.

[16] М. Г. Худяковның версиясе икенче. Солых шартларын казанлылар түгел, киресенчә, Новгородны буйсындырганнан соң, куллары «бушаган» Мәскәү хөкүмәте боза һәм үзе өчен иң кулай моментта Казан ханлыгына сугыш игълан итә.

[17] Иван III әлеге походны ашык-пошык кына оештырган булырга кирәк, чөнки аның уңышсызлыгын башкача аңлату дөрес булмас иде. Бу үзенә күрә бер җәза операциясе була, аны Вятка һәм Устюг талаучы (ушкуйниклар) юлбасарлары тулыландыра. Мәсәлән, Зәки Вәлиди, урыслар «Нижний Новгород илә Казан арасында булган барлык авыллар вә шәһәрләрне талап, утка яндырып һәлак иттеләр», ди. Әмма нигездә 1478 ел явы Мәскәү хөкүмәтенә бернинди дә уңыш китерми, шуңа күрә солыхның «Иван теләгенә муафыйк» булуы бәхәс тудыра.

[18] Бу фикерне Р. Фәхретдин С. М. Соловьев сүзләренә таянып үткәрә. Ләкин Казан ханлыгының шактый дәрәҗәдә Мәскәү химаясенә керүен 1487 ел белән бәйләү дөресрәк булыр.

ИЛҺАМ (ГАЛИ) ХАН

(?—?)

Ибраһим хан вафат иткәннең соңында төрле хатыннарыннан ир балалары калды[1]. Суфия исемле хатыны Кырым ханы Миңле Гәрәй ханга никахланды[2]. Моның урынына хан кую мәсьәләсендә мирзалар вә Казан олуглары ике тараф булып, үзара низаг итешергә керештеләр (гасырыбызда мулла кую низаглары да шул вакытлардан мирас булып калган булса кирәк) һәм һәр як үзләренә кулай күргән шаһзадәләрне хан итеп куярга омтылалар иде.

Бер тараф, яше ягыннан олы булуын сәбәп итеп, Ибраһим ханның өлкән угылы Илһам (Гали)ны[3] хан итеп күтәрергә теләгәндә, икенче тараф кече угылы Мөхәммәд Әминне кую фикерен алга сөрделәр. Нугай ханы Илһам тарафында (моның сәбәбе Илһам ханның бер хатыны нугай кызы булуыдыр), Кырым ханы Миңле Гәрәй исә Мөхәммәд Әмин тарафында иде. (Чөнки аның анасы никахлануы вә яки никахланырга ниятләнүе сәбәпле аны яклаячагы табигыйдыр. Мәскәү кенәзе дә дусты Миңле Гәрәй тарафын тиешле таба иде.)

Тавыш-гаугалар, җәнк-җәдәлләр, ягъни бәрелешләр соңында Илһам тарафы җиңеп, Казан хөкүмәте тәхетенә Илһам (Гали)ны хан итеп күтәрделәр. Мөхәммәд Әмин бу вакыйга аркасында Мәскәүгә килеп, великий кенәз химаясен кабул итте, ягъни канаты астына сыенды[4]. Кенәз исә, Казан эшләренә катышырга зур сылтау булганлыктан, моны хөрмәтләп каршы алды һәм үзенә Кашир шәһәрен бирде. Мөхәммәд Әмин хан бу шәһәрдән Казанда булган үз тарафдарлары белән язышып торыр вә, һәрвакыт Казан хәлләрен күз уңында тотып, форсат эзләр иде. Хәтта



Илһам (Гали) хан. Рушан Шәмсетдинов рәсеме.

ки Казан хәлләрен белеп, хәбәр биреп торыр өчен Казан мәмләкәте чигенә якын җиргә үзенең бер адәмен билгеләп куйган иде[5].

Великий кенәз белән Мөхәммәд Әмин игъвасы, ягъни котыртуы сәбәпле Казан һаман да фетнә эчендә һәм эчке дәгъва астында гомер сөрер булды. Ахырда Мәскәү кенәзе Мөхәммәд Әминне хан итү максаты белән Холмский исемле бер сәргаскәр командасында гаскәр төзеп, Казанга җибәрде (1487 елның апрелендә)[6].

Мәскәү гаскәре 18 майда Казан шәһәренә килеп җитте вә шәһәрне камап алды һәм өч атналап шушы камау хәлендә тотты. Шәһәр тышындагы халыклар кенәз Әл-Газый дигән мәшһүр бер мөселман сәргаскәр командасында руслар белән сугыштылар. Фәкать гаскәре аз булганлыктан, руслар моны Кама елгасына кадәр кудылар.

Соңра шул елның 9 июлендә Илһам хан, шәһәрдән чыгып, рус гаскәренә әсир бирелде[7].

Мәскәүдә бу хәбәрне ишеткәч, гаять зур бәйрәм ясадылар вә моннан берничә еллар элек Мәскәү кенәзен әсир итеп алып киткән вә тоткынлыкка салган Казан хөкүмәтенең ханын әсир алуларын дөньяда гадәттән тыш эшләр җөмләсеннән хисап итәр булдылар.

Илһам (Гали) ханны, анасы Суфияне, хатынын, ике тума кардәшен әсир алып, Мәскәүгә китерделәр. Әсир буларак килгән ханны күрер өчен бөтен Мәскәү халкы чыкты вә татар ханының әсир алынуына гакылларыннан шашар дәрәҗәдә тәгаҗҗеб иттеләр, ягъни гаҗәпләнделәр (моның әсир төшүенең сәбәбе исә җиңел булып, эчтә булган тынычсызлык, үз араларында булган фетнәдер). Моннан соң ике хатыны белән бергә ханны Вологда шәһәренә, туганнары белән анасын Белоозерга җибәрделәр.

Тумаларыннан берсе Белоозерда вафат итте вә икенчесен чукындырдылар да великий кенәз аңа үзенең Евдокия исемле кызын бирде вә Петр исемле атадылар. Әүвәлге исеме Ходай Бирде иде[8]. (Рычков, 58 б.)

Илһам хан әсирлегендә каты мәшәкать астында торды. Сарай ханы[9] Әхмәд ханны үтергән Нугай ханы Юак[10] һәм Алач, Муса, Ямгурчы исемле нугай мирзалары Иванга хат язып, Илһам ханны әсирлектән азат итүне үтенсәләр дә, Иван боларга илтифат итмәде. Чөнки боларның Иван өчен кирәкләре Сарай дәүләтен харап итәр өчен генә иде. Сарай монкариз булдыгы соң, ягъни юкка

чыкканнан соң, Иван каршында мондый хан вә мирзаларның кыйммәләре калмаган иде.

Ахирел-әмер, ягъни иң соңында, Илһам хан ошбу әсирлектә вафат итте. Анасы да шунда вафат булды. Ханлык сөрү вакыты 9 ел булмыштыр. (Мөстәфаделәхбар. Т. 1, 128 б.) Вафат елы ачык беленмәде.

ИСКӘРМӘЛӘР (ИЛҺАМ (ГАЛИ) ХАН

[1] Ибраһим 1479 елда үлә. М. Г. Худяков мәгълүматлары буенча, беренче хатыны Фатыйма бикәдән өч улы: Гали (Илһам), Ходайкол һәм Мәлик Таһир, икенче хатыны Нур Солтаннан (мәрхүм Хәлил ханның тол хатыныннан) ике улы: Мөхәммәд Әмин һәм Габдел-Латыйф кала. Болардан башка Ибраһимның үзеннән соң берничә кызы кала. Алар арасында соңыннан Гәүһәршад (урыс чыганакларында Ковгоршад) дигәне зур шөһрәт казана.

[2] Бу исем кайбер чыганакларда «Суфия», икенчеләрендә «Нур Солтан» дип күрсәтелә. Миңле Гәрәйгә кияүгә чыккач, бу бикә Казаннан Бакчасарайга юнәлә.

[3] Илһам (Гали)ның ике төрле исем йөртүе нииндидер томанлыкка ишарәли. Ш. Мәрҗани бу мәсьәләдә шик белдереп, Илһам турында сүз барганда, «кайбер чыганакларда шул гасырда Гали хан дигән шәхес тә күренә. Бу шул ук бер кешеме яки башкамы?» дип язып үтә. Безнең уебызча, мәсьәләне татар язма чыганакларының сакланмавы катлауландыра, хәлбуки Илһам белән Гали икесе бер шәхес. Буталыш урысча транскрипция аркасында килеп чыккан булса кирәк, чөнки урыс елъязмалары Илһамны «Алегам»га әйләндергәннәр, ә аннан инде «Алихан»га да ерак калмый. Соловьев шулай дип яза да: Алегам (Али-хан).

[4] С. М. Соловьев бу турыда болай ди: «Около каждого из них образовалась своя сторона; Алегам с помощью ногаев осилил и сел на отцовском столе, но волнения не прекратились и подавали повод московскому князю вооруженною рукою вмешиваться в казанские дела; наконец, молодой Магмет-Аминь явился в Москву бить челом великому князю, назвал его себе отцом и просил у него силы на брата Алегама». Шулай итеп, шәхси мәнфәгатьләр, тәхет хакына бер-берсен, ватанын, халкын сатып, урыс кенәзләренә сыену яңа сулыш ала.

[5] Зәки Вәлиди сүзләре белән әйткәндә, «Мөхәммәд Әмин Казанда фетнәләр кубару, Илһамнан халыкны суындыру хакында һәртөрле фидакярлекләр итә иде».

[6] Бу инде Казанга 1469 елдан соң ясалган икенче зур поход була. Бик зур чирүне Иван III әмере буенча кенәзләр Данила

Холмский, Александр Оболенский, Семен Ряполовский һәм Семен Ярославский җитәкли. Алар артыннан Мөхәммәд Әмин гаскәре юл ала.

[7] Ш. Мәрҗани бу вакыйганы болай сурәтли: «Илһам хан Зөя буенда Русия гаскәре белән сугышып, җиңелеп качып кайта. Әмма Казан шәһәре капкасына килгәндә капканы ачып өлгертә алмыйлар. Руслар килеп җитеп, Казанга кереп, ханның үзен һәм бертуган кардәшен, анасын һәм хатынын әсир итеп алып китәләр һәм Вологда шәһәренә илтеп куялар». Сигизмунд Герберштейн язып калдырганча, казанлылар Илһам ханны тәхеттән үзләре төшерәләр һәм урысларга тотып бирәләр. Зәки Вәлиди дә казанлыларның үз ханнарын бөтен гаиләсе белән урыс баскыннарына үзләре биреп җибәрүләрен раслый.

[8] Илһам хан Вологдада әсирлектә үлә. Аның вафатыннан соң бер хатыны төрмәдән чыгарыла һәм, гадәт буенча, Мөхәммәд Әмингә хатынлыкка бирелә. Фатыйма бикә һәм шаһзадә Мәлик Таһир Карголомда әсирлектә дөнья куялар. Мәлик Таһирның ике улы Василий һәм Федор исемнәре белән чукындырылалар. Шулардан Федор дигәне 1531 елда Новгородта наместник була. Илһам ханның икенче улы Ходайкул (Р. Фәхретдин аны, П. И. Рычковка ияреп, Ходай Бирде дип атый) соңыннан сөргеннән кайтарылып, 1505 елда Мәскәүдә чукындырыла һәм Петр исеменә «лаек» була. Мөселманнарны көчләп чукындыру сәясәтенең, күргәнебезчә, тарихы бик озын, тамырлары тирән икән.

[9] Алтын Урда (башкаласы Сарай) ханы дигәнне аңлата.

[10] Бу исемнең язылышы төрле чыганакларда төрлечә: Юак, Ивак, Иуак, Ибак. Иң дөресе «Ибак» булса кирәк.

МӨХӘММӘД ӘМИН ХАН

(? — 1518 елда вафат)

Илһам хан руслар тарафыннан әсир итеп алынганнан, дөресрәге, Казанда Мөхәммәд Әмин тарафдары булган мирзалар, түрәләр әсир итеп рус кулына биргәннән соң, Ибраһим ханның яшь угылы вә Кырым ханы Миңле Гәрәйнең үги угылы булган Мөхәммәд Әмин Казан дәүләтенә хан итеп куелды, халык аңа бигать бирде, ягъни буйсынуын белдерде[1]. Әҗем (Ижем) хан исеме белән танылды[2].

Мөхәммәд Әмин ханның һәрвакыт Мәскәү кенәзе теләге буенча хәрәкәт итеп торуын белгәч, Казан халыклары моны мәкруһ, ягъни начар, сөйкемсез күрә башладылар[3]. Ахырда Мөхәммәд Әминне ханлыктан төшереп, аның урынына хан итеп куяр өчен чакырып, яшерен сурәттә Нугай урдасыннан вә, икенче бер риваятькә күрә, Сибирия ханнарыннан Мамук исемле бер затка хәбәр җибәрделәр[4].

Вакыйгадан хәбәрдар булыр, Мөхәммәд Әмин хан 1496 елның маенда Мәскәү кенәзе Иванга мондый хәбәр җибәрде: «Минем өстемә Шәйбани Мамук хан зур көч белән килә дип ишеттем, моны чакыручылар һәрвакыт минем зарарыма эшләүче кенәзләр: Калимәт, Урак, Садыйр, Агиштыр». Бу хәбәрне ишеткәч, Иван Мөхәммәд Әмингә ярдәм бирү сылтавы белән Казан шәһәренә гаскәр җибәрде[5]. Моны ишеткәч, Калимәт вә иптәшләре Казаннан качып, Мамук хан каршысына килделәр. Мамук исә бу хәбәрне белеп, үзе дә курыкты һәм Казанга килгән җиреннән кире кайтып китте. Мәскәү гаскәре Казанга килеп җиткәч, Мамукның килмәве, бәлки кире кайтып китүе

мәгълүм булды. Шуның өчен Мәскәү гаскәре дә кире кайтып китте.

Мәскәү гаскәренең китүен ишетү белән үк Мамук, яңадан үзенең көчен җыеп, Казан шәһәренә юлланды вә һичкем көтмәгәндә Казан төбенә килеп чыкты[6]. Мөхәммәд Әмин хатыны вә балалары һәм якыннары белән качты, Казаннан чыкты вә туры Мәскәүгә юнәлде[7].

Мамук һичбер мөзахәмсез, ягъни ыгы-зыгысыз Казан шәһәренә кереп хуҗа булды[8]. Ләкин бозык табигатьле, әхлаксыз бер адәм булганлыктан, урынын ныгытмастан һәм дәүләт эшләренә керешмәстән элек байларны таларга вә үзенә хәерхаһлык итеп алып килүче Калимәт мирза вә иптәшләренә җәбер-золым кыла башлады. Ар шәһәрен барып мөхасарә итте, ягъни камады. Һәм шул вакыт Казан халкы моның ханлыгыннан файда чыкмаячагын белде вә Казан шәһәренә кабат кертмәскә карар бирде. Золмани вә дәни, ягъни золым иясе һәм әшәке табигатьле икәнен ишетү сәбәпле Ар шәһәре халкы да моны шәһәрләренә кертмәс өчен гайрәт итте һәм Казан ханы булуына риза түгелллекләрен белдерде. Казан шәһәренә кайтканда аның да капкалары бикле булды[9].

Казан мирзалары вә түрәләре Иванга мондый хәбәр бирделәр: «Без Мамукны ханлык өчен кабул итмәдек, Мөхәммәд Әминнең дә хан булуы мөнасиб түгел, чөнки ул яңадан хан булса, үзенең зарарына йөргән кешеләргә җәза бирер, шуның өчен безгә Ибраһим ханның кече угылы Габдел-Латыйф җибәрелсен, без аны куячакбыз».

Иван моңа шатланды һәм үз ягында торган Габдел-Латыйф Ибраһим хан угылын Казанга җибәрде. Монысы ханлык тәхетенә утырды[10].

Габдел-Латыйф хан мәгъзул улдыгында, ягъни урыныннан төшерелгәннән соң Иван тарафыннан Казан шәһәренә яңадан Мөхәммәд Әмин җибәрелде һәм ул икенче мәртәбә Казан тәхетенә утырды. Мөхәммәд Әмин хан моңарчы башына килгән эшләрнең сәбәпчесе Калимәт икәнен белгәнлектән, Мәскәүдә вакытта Иванга: «Без Калимәт белән бер казанга сыймабыз!» — диде вә Казанга килеп тәхеткә яңадан утыргач, беренче эше Калимәт мирзаны үтерү булды.

Габдел-Латыйф төшерелгәннән соң, Мөхәммәд Әмин хан яңадан Казанга кайтып никахланды һәм Мәскәүдә торганда Илһам хан хатыны булган җиңгәсен никахлап алган иде[11].

Мөхәммәд Әмин хан ошбу хатын мәхәббәтенә әсир булганлыктан, аның бар сүзен кабул итәр һәм аннан

Мөхәммәд Әмин хан. Рушан Шәмсетдинов рәсеме.

башка сабыр итеп тора алмас иде. Мәзкүрә дә, ягъни телгә алынган хатын да гаять әдәпле вә гакыллы бер хатын булуы өстенә, сүзгә оста, гаять хәмиятьле, ягъни яклаучан һәм һимммәтле иде. Шул сәбәпле Мөхәммәд Әмин ханны Мәскәү кенәзенә каршы кыздырыр, хәмиять вә гайрәтен кузгатыр, әле гарьләндерер, әле күңелләндерер иде. Бу рәвештә чит кешеләр кул астында хан булып торудан хан исемен күтәрмәү хәерледер, кеше өчен хурлык белән яшәүгә караганда гыйззәт, ягъни кадер-хөрмәт белән үлү яхшырак, дия иде. Кыскасы, Мөхәммәд Әмин ханның хәмият тамырларын тәмам хәрәкәтләндерде, ата вә бабаларының шәҗагать, ягъни гайрәт вә батырлыкларын сөйләп, хан күңеленә кыюлык орлыклары салды[12]. Ниһаять, бу хатынның вәгазь вә нәсихәтләре тәэсире белән Мөхәммәд Әмин Мәскәүдән аерылып, мөстәкыйль хан булу фикеренә керде вә моның чараларын эзли башлады.

1505 елда Мөхәммәд Әмин хан Уфимский (Уфалы) (ни сәбәпледер моны Карамзин шулай дип атый) бер мирзасын Иван янына җибәреп, кайбер нәрсәләр сорады. Иванның моңа гаять ачуы килде вә бу турыда әмерләрен турыдан-туры ирештерер өчен үзенең кятибен, ягъни секретарен Казан шәһәренә күндерде. Хәлбуки Мөхәммәд Әмин фикереннән Иван бөтенләй хәбәрдар түгел иде.

Иван илчесе барган вакытта июнь аенда Казан шәһәрендә бөек ярминкә булып, рус сәүдәгәрләреннән дә байлар бар иде. Иван илчесенә гаять ачуы килгәнлектән, Мөхәммәд Әмин аны үтерде һәм ярминкәдә булган рус сәүдәгәрләрен вә, никадәр рус чиновниклары булса, барысын да үтерергә боерды. Хан әмере буенча, һәммәсе үтерелде һәм маллары хәзинәгә алынды (бу вакыйга 24 июньдә булды)[13].

Моннан соң 40 мең кадәр Казан гаскәреннән һәм 20 мең нугай атлы гаскәреннән чирү тәртип итеп, Русия өстенә йөрде, юлда булган Мәскәү шәһәрләрен берәм-берәм алып, Нижгород шәһәренә җитте һәм бу шәһәрне камап алды. Нижгородта исә 3 мең кадәр әсир булып торучы Литва гаскәре бар иде. Нижгород валисе, ягъни идарәчесе бу әсирләрне азат итте, һәм бу мәрхәмәт бәрабәренә Казан гаскәренә каршы сугышуларын үтенде һәм барысын да коралландырды. Менә шуларның татар рәвешендә оста сугышулары сәбәпле Казан гаскәре шәһәрне ала

алмады һәм бу сугышта Мөхәммәд Әмин ханның хатыны белән бер тума булган Нугай гаскәренең башлыклары үтерелде. Моннан соң бер микъдар сугышып, Мөхәммәд Әмин гаскәре белән Казанга кайтып китте. Бу хәбәрне ишетеп, болар белән сугышыр өчен Иван 100 мең кадәр гаскәр җыеп җибәрсә дә, ошбу гаскәр Мөхәммәд Әмин белән сугышырга батырчылык итмәде һәм Муром шәһәреннән кире кайтып китте[14]. Иван III ошбу вакыйгалар турында кайгыртып, аның кайгысыннан шул елның октябрендә вафат булды. Яше 66 да булып, 43 елдан артык хөкүмәт сөрмеш иде.

Моның соңында угылы Василий III Мәскәү кенәзе булды һәм, казанлылардан үч алыр өчен гаять зур гаскәр җыеп, 1506 елда Казан шәһәренә җибәрде. Мәскәү гаскәре Волгадан чыгып, 22 майда Казан төбенә килеп туктады. Шул вакыт Казан гаскәре каршы чыгып сугыш башланды. Казан гаскәре аз булганлыктан, җиңелергә ерак калмаган иде. Фәкать шул аз гаскәрдән бер микъдары аерылып, Мәскәү гаскәренең юлларын кисте һәм шуннан соң дүрт тарафтан һөҗүм итеп «теләгән кадәр» үтерә башладылар. Бер микъдар Мәскәү гаскәре зур бәла белән котылса да, күбесе үтерелде вә әсир алынды, бөтен Мәскәү гаскәре шәзер-мәзер булып бетте, ягъни бөтенләй туздырылды[15].

Бу хәбәр ишетелгәч, Василий тагын гаскәр җыеп, Казан белән сугышырга җибәрде. Бу вакыт Казанның мәшһүр ярминкәсе заманы булып, дөньяның һәр тарафыннан сәүдәгәрләр җыелып, дөкяннарын, ягъни кибетләрен ачып, сәүдә белән шөгыльләнәләр иде.

Казанлылар исә, русларны кудык, дип шатлык белән бәйрәм итәләр, Мөхәммәд Әмин вә мирзалары өчен Арча кырында меңнән артык чатыр корылган иде. Менә Казан мөселманнары кәеф-сафа корып яткан вакытта Василий тарафыннан соңыннан чакырылган гаскәр кинәт килеп, 23 июньдә казанлыларны бастылар вә һәр тарафтан ук, мылтык вә кылыч белән үтерергә керештеләр. Мөселманнар исә, һич нәрсәләрен алырга өлгермичә, шәһәргә кереп бикләнделәр.

Мәскәү чирүе, Казанда хәзер гаскәр юк икәнен белеп, Казанны алачакларында шөбһә итмәде. Шуңа күрә мөселманнарның чатырларына кереп, һәрбере комсызланып ашый башлады. Болар һичбер нәрсәгә ихтимал бирмичә, корсакларын тутыру белән мәшгуль вакытта, 25 июньдә, төн уртасыннан соң, 20 мең атлы вә 30 мең җәяүле гаскәр

Казаннан чыгып, руслар өстенә һөҗүм иттеләр. Руслар исә кәеф-сафа корып рәхәттә ятырлар, хәтта каравылчылары да ятып йоклаган иде.

Казан гаскәре мәскәүлеләрне һәр тарафтан үтерергә кереште, ничә өлеш күп булсалар да, Мәскәү гаскәре тоташтан кача башлады, бөтен нәрсәләрен ташлап йөгерделәр вә әүвәлге мәртәбәсеннән дә катырак сурәттә тар-мар ителделәр. Бөтен Арча кыры рус үләксәсе белән тулды. Гаскәр башлыкларының кайсыберләре үтерелде, кайберләре әсир алынды[16]. Моннан соң Миңле Гәрәй арадашлыгы белән Мөхәммәд Әмин Василий белән солых ясады. Бу солых буенча Казан ханлыгының Мәскәү кенәзе химаясендә, ягъни канат астында булуы шарт ителсә дә, Мөхәммәд Әмин дань, ягъни салым түләмәс булды. Шуның өчен әлеге шарт коры бер сүздән гыйбарәт булып, асылда Казан бөтенләй мөстәкыйль булган иде[17].

1510 елда Мөхәммәд Әминнең анасы, ә Миңле Гәрәй ханның хатыны булган Нур Солтан бикә угылы Габдел-Латыйф белән күрешү өчен Кырым вилаятеннән Мәскәүгә килде. Василий аны бик олылап һәм ихтирам белән каршы алды. Бер ел чамасы Мәскәүдә кенәз хозурында кунак булып торгач, Нур Солтан Казан шәһәренә юлланды. Казанда угылы Мөхәммәд Әмин хан хозурында бер ел торды вә шул вакыт Мөхәммәд Әмин белән Мәскәү кенәзе Василий араларын килештерде. Моннан соң яңадан Мәскәүгә барып, кенәз сараенда ярты ел торды һәм аннан Кырым вилаятенә кайтып китте[18].

1516 елда Мөхәммәд Әмин хан авыр хәстә булды. Бөтен бәдәне шешеп, дәвасыннан табиблар гаҗиз калды. Ошбу вакыт Василийга кеше җибәреп, үзе үлгәч хан булыр өчен Габдел-Латыйфны Мәскәүдән Казанга җибәрүне үтенде. Василийның моңа риза булуы мөрәвидер, ягъни риваять ителәдер.

Мөхәммәд Әминнең авыруын ишеткәч, шул вакыт Кырым мәмләкәтендә ханлык иткән Мөхәммәд Гәрәй, Мәскәү кенәзе үз максатына муафыйк адәмне хан итеп куяр да, Кырым белән Казан арасындагы мөнәсәбәтләрне бозар, дип куркуга төште. Шуның өчен мөдарә юлына кереп, ягъни тыштан дуслык күрсәтеп, Василийга дуслык тәкъдим итеп бер адәм җибәрде вә Габдел-Латыйфны Казанда Мөхәммәд Әмингә вәли гаһед, ягъни тәхет варисы итүне һәм Мещар (Касыйм) шәһәрендә булган Шаһ Гали урынына Нур Дәүләт угылын куюын үтенде. Мөхәммәд Гәрәй хан исә Габдел-Латыйфны Казан ханы

итеп куйдырып, аның аркылы Казан эшләренә катышырга, бәлки Казаны тәмам Кырым хөкүмәте канаты астына алу максатында булмыштыр. Фәкать шул һич көтмәгән вакытта Мәскәүдә Габдел-Латыйф вафат итте (1518 ел, 9 ноябрьдә)[19].

Моны ишеткәч, Мөхәммәд Гәрәй хан Аппак исемле мирзаны яңадан Мәскәүгә җибәреп, Мөхәммәд Әмин өчен үзенең анасы ягыннан бер тумасы Сәхиб Гәрәй бине Миңле Гәрәй ханны тәхет варисы итүне сорады. Беркадәр шартлар бәрабәренә Василий моңа риза булды һәм Казан ханлыгы өчен Нур Солтан бикәнең Миңле Гәрәй ханнан дөньяга килгән угылы Сәхиб Гәрәй хан Василий тарафыннан Казан ханлыгы өчен вәли гаһед буларак тәгаен ителде, ягъни билгеләнде. (Карамзин. Т. 7, 104 б.)

1518 елның декабрь аенда Мөхәммәд Әмин хан мәгълүм хәстәлегеннән вафат булды. Әүвәлге мәртәбә ханлыгы 9 вә соңгы мәртәбә ханлыгы 17 ел чамасында булды. Ир баласы калмады, тумасы булган Габдел-Латыйф ханнан да ир бала калмаган иде.

Моның вафатыннан соң Казан дәүләтен тәэсис иткән, ягъни төзегән Олуг Мөхәммәд хан хәзрәтләренең Казанда булган нәселе тәмам киселде. Ошбу җәһәттән Мөхәммәд Әмин хан үлгәндә Казан тәхетен үзенең ана ягыннан бер тума карендәше Сәхиб Гәрәй бине Миңле Гәрәй ханга васыять итте. (Мөстәфадел-әхбар, Т. 1, 129 б.) (Василийның Шаһ Галине Казан хөкемдары итү буенча тырышлыгына ант бозу мәгънәсен бирдермәс өчен, Карамзин: Мөхәммәд Әмин үзенең вафаты алдыннан хан кую мәсьәләсендә «казанлылар Василийга мөрәҗәгать итсеннәр», дип васыять итте, дип яза.)[20]

Олуг Мөхәммәд ханның хөкемдарлык итә башлаган көне белән Мөхәммәд Әмин хан вафаты арасында 85 ел үткән вә киләчәктә сөйләнәчәк Габдел-Латыйф хан белән барлыгы 7 адәм хөкүмәт сөрмештер.

Мөхәммәд Әминнең вафат булуын игълан итәр өчен Казандагы сәед-задәләрдән Кол дәрвиш, Углан, кенәзләрдән — Карачак, Эчек, мирзалардан — Малан шаһзадә 1518 елның 29 декабрендә Мәскәүгә килеп керделәр. (Карамзин. Т. 6, 18 б.)

ИСКӘРМӘЛӘР (МӨХӘММӘД ӘМИН ХАН):

[1] Мөхәммәд Әминнең чит ил гаскәре тарафыннан хан тәхетенә куелуы белән Казан ханлыгы тарихының Олуг Мөхәммәд җиңүләре белән башланган шанлы чоры тәмам була. Инде икенче дәвер — урыс партиясенең хакимлеге, чит мәмләкәткә бәйлелек чоры бушлана. Казанны 1487 елда алуга шундый зур әһәмият бирелә ки, бу җиңүе хөрмәтенә Иван III (шулай ук Грозный дигән кушаматка ия булган) үзенә «князь Болгарский» титулын ала. Казанга ясак түләү туктатыла. Казан ханының «салымчысы», ягъни аның кул астындагы кешедән Мәскәү великий кенәзе инде мөстәкыйль хөкемдарга әйләнә. Казан дәүләте ике якның да тигезлеген таный, үзара язышкан вакытта ике хөкемдар да бер-берсен борадәр («брат») дип атый башлыйлар.

Мәскәү белән Казан арасын билгели торган килешүләр гадәттә өч шартны үз эченә алалар. Казан дәүләте үз өстенә мондый йөкләмәләр ала: 1) Русиягә каршы сугышмаска, 2) урыс кенәзе белән килешүдән башка яңа хан сайламаска, 3) ханлыктагы урысларның мәнфәгатьләрен якларга. Бу шартлар нигездә үтәләләр, әмма Русия хөкүмәтенең басымы торган саен көчәя бара. Икенче дәвер Иван III даирәсенең Казанны һәрьяклап кысрыклау һәм татар башкаласында урыс партиясенең хакимияте, кысымы белән билгеләнә. Җитмәсә, казанлылар Мәскәү хөкүмәтенә сугыш вакытларында ярдәмче гаскәр (вспомогательное войско) бирергә тиеш булалар.

[2] Әҗем (Ижем) исеме тарихи әдәбиятта сирәк очрый. Бу исемнең яки кушаматның мәшһүр татар эшлеклеләре һәм сәүдәгәрләре Әҗемовларга мөнәсәбәте булуы ихтимал.

[3] С. М. Соловьев, мәсәлән, болай ди: «Магмет-Аминь возбудил против себя негодование вельмож казанских разного рода насилиями».

[4] Казанның чит ил гаскәре ярдәме белән хакимияткә менгән урыс партиясе халыкта теләктәшлек тапмый. Иң күренекле юлбашчылары үтерелүгә карамастан, көнчыгыш партиясе сакланып кала һәм 1490 елларның уртасына Мөхәммәд Әмин хөкүмәтенә каршы оппозиция тәмам оешып җитә. Оппозициянең башында Казан аксөяк-мирзаларының 4 күренекле вәкиле — Кол Әхмәд (Калимәт), Урак, Садыйр һәм Агиш торалар. Көнчыгыш партиясе үзләренең табигый союзниклары — шәрекътагы күршеләренең хәрби куәтенә таянырга карар бирә. Хан тәхетенә варис итеп Себер шаһзадәсе Мамук (Мамык) сайлап алына. Хан Ибакның Себер хөкүмәте Казан мөһаҗирләрен (эмигрантларын) һәм оппозиция көчләрен яклый. 1496 елның

язында Казан тәхетенә чакырылган Мамук зур гына гаскәр белән походка чыга.

[5] Иван III, үзенең воеводасы Семен Ряполовский җитәкчелегендә зур гаскәр җибәреп, Казанны «сакларга боера».

[6] К. Ф. Фукс болай дип яза: «Но когда Мамук отступил, то и русское войско пошло обратно, не оставя гарнизона для защищения города, а Мамук в то самое время, будучи в добром согласии со многими казанцами, появился снова».

[7] С. М. Соловьев хәбәренчә, «Магмет-Аминь, боясь измены, выбежал из Казани с женою и верными князьями и приехал в Москву, где великий князь держал его в чести».

[8] Себер шаһзадәсе Мамук — Батуның энесе, Чыңгыз ханның оныгы Шәйбани нәселеннән. Көнбатыш Себердәге татар ханлыгының башкаласы, М. Г. Худяков язганча, Төмән шәһәре була. Мамук шуннан килеп, Казанда ханлык тәхетенә менә.

[9] Кайбер чыганаклар Мамукның начар холкын шәрехләү, зур салымнар белән интектерүеннән бигрәк, аның олуг мәдәният үзәге Казанга эләккәннән соң югалып калуына, электән яшәп килгән традицияләрне бозмыйча дәүләт белән идарә итәргә сәләтсезлегенә, үзен ханлыкка чакырган мирзалар белән кискен низагка керүенә ишарәлиләр.

[10] Габдел-Латыйфка аерым мәкалә багышлана.

[11] Мөхәммәд Әмин әсирлектә үлгән абыйсы Илһам (Гали) ханның хатыны, Нугай морзасы Мусаның кызына өйләнә. Бу никах Иван III нең рөхсәте белән генә гамәлгә ашырыла.

[12] Бу ханбикә турында Соловьев болай ди: «Будучи научаема вельможами, она день и ночь шептала хану, чтобы (он) отложился от Москвы».

[13] Кайбер чыганакларга караганда, бу һөҗүмнең максаты мөмкин кадәр күбрәк әсирләр алу була. Казан ханлыгында яшәгән барлык урыслар да, диелә аларда, колларга әйләндерелә.

[14] Урыс гаскәрендәге куркуны елъязмачы мондый юллар белән тасвирлый. «Они же паче себя стрежаху, а не земли своея, и вышли страхом объяти быша, безумни, убояхуся и трепатаху, избранными воины блюдущеся из града выйти, толико имуща не мало воспретити царю (т. е. хану)».

[15] Елъязмачы сугыш нәтиҗәсен мондый сүзләр белән сурәтли: «И грех ради наших побища татарове воевод пеших и детей боярских многих, и иных поимаша, а инии мнози истопоша на поганом озере».

[16] Бу икенче тар-мар ителү турында урыс елъязмачысы берничә генә сүз яза: «Месяца июня 25 начаша ко граду приступати с небрежением, и граду не успеша ничтоже, но сами

побеждени быша от татар». Елъязмачы хәбәр иткәнчә, 100 мең урыс гаскәреннән 7 меңләп кенә кеше исән кала. М. Худяков язганча, казанлыларның 1506 елдагы бу җиңүе Олуг Мөхәммәднең Белев һәм Суздаль төбендәге уңышларын (1437 һәм 1445) хәтерләтә.

[17] М. Худяков язганча, казанлылар җиңү җимешләрен ахырынача файдаланмыйлар. Урыс хөкүмәте Мөхәммәд Әмин гаскәренең Русиягә һөҗүмен көтсә дә, сугыш театры киңәйми кала. Казан дәүләте һөҗүм планнарыннан баш тарта. Ике зур җиңү Мөхәммәд Әминнең тәхетен бик ныгыта, аның Мәскәүгә ярарга тырышу сәясәтеннән ризасызлык бетә, Казан гаскәренең даны күтәрелеп, дәүләткә күп ганимәт маллары керә. Авыр сабак алган Русия хөкүмәте дә яңа походлар оештырырга базмый һәм тиздән Мәскәү белән Казан арасында «мәңгелек солых» («вечный мир») төзелә.

[18] Нур Солтанның бу дипломатик сәяхәтләре «мәңгелек солых» өчен җитди нигез була.

[19] Аерым чыганаклардан күренгәнчә, Русия хөкүмәте Габдел-Латыйфка ышанмый, шаһзадәне озак вакыт әсирлектә тота, шуңа күрә аның Казан тәхетенә чыгуын теләми. Тәхет варисының көтмәгәндә серле үлемендә Мәскәү идарәчеләренең кулы уйнавы бик ихтимал.

[20] Василий IIIнең Сәхиб Гәрәйне Казан тәхетендә күрергә теләмәве яхшы аңлашыла, чөнки Русия хөкүмәте Казанга Кырым йогынтысының көчәюеннән курка. Шул ук вакытта кенәз Мөхәммәд Әмин үлгәнчегә кадәр икейөзле сәясәт алып бара һәм ханның вафатыннан соң Казан тәхетенә моңа һичнинди хокукы булмаган Касыйм ханлыгы шаһзадәсе Шаһ Галине билгели.

ГАБДЕЛ-ЛАТЫЙФ ХАН

(1475—1518 елда вафат)

Ибраһим ханның угылы вә Мөхәммәд Әмин ханның энесе булган ошбу зат Мөхәммәд Әмин ханның ике мәртәбә ханлыгы арасында 5 ел чамасы Казан хөкүмәтендә хан булып торды[1].

Габдел-Латыйф, Кырымда анасы Нур Солтан бикә янында торып, великий кенәз хозурында хезмәт итәр өчен дип Мәскәүгә килгән иде[2]. Менә шул вакыт моны казанлылар чакырдылар[3]. Шуның өчен Мәскәү кенәзе гаскәр вә мәэмүрләр, ягъни чиновниклар белән берлектә Мәскәүдән Казан шәһәренә җибәреп, [аны] тәхеткә утырттырды вә үзенә итагатьле, ягъни буйсынучан булыр дип, Габдел-Латыйф олуг мирзалар һәм Казанның могътәбәр, ягъни дәрәҗәле, абруйлы затларыннан ант иттерде[4].

Шәйбани нәселеннән Агалак хан исемле бер зат Габдел-Латыйф хан өстенә килер өчен хәзерләнә[5] дигән бер хәбәр чыкканын бәһанә, ягъни сылтау итеп, Мәскәү кенәзе Иван Казанга гаскәр җибәрде һәм дә моннан соң хан хозурында Мәскәү мәэмүрләре тору гадәте башланды. Ханнарны үзләренең дошманнарыннан саклау сылтавы белән Казанда һәрвакыт Мәскәү кенәзе тарафыннан рус мәэмүрләре торыр иде. Бу мәэмүрләр ханны дошманнарыннан саклаудан бигрәк итәк астыннан ут йөртү белән мәшгуль булып тордылар. Шул сәбәптән хан белән халык арасы бозылып, илтифат һәм мәхәббәтнең исеме дә калмады. Соңра Казан халкы Габдел-Латыйф хан өстеннән рәсми суратттә Иванга шикаять итте[6]. Моны сылтау итеп, Иван Мәскәүдән гаскәр җибәреп Габдел-Латыйф ханны тоттырды, Мәскәүгә китертте вә Белоозерга җибәреп хәбес иттерде, ягъни тоткынлыкка салды[7].

Бу хәбәр Кырымда Миңле Гәрәй ханга ирешкәч, үги улының болай мәсхәрә ителүенә аның ачуы килде. Бары тик Иван ризалыгын алыр өчен генә үзенең Дәште Кыпчак хөкүмәтен, ата вә бабалары бина иткән Сарай шәһәрен харап итүен фикерләп, Миңле Гәрәй ханның күңеле гаять мөгаззәб булды, ягъни газапланды, һәм дә [ул] Иванга хат язып: «Габдел-Латыйф ханны азат итеп, ханнар мөгамәләсе кебек бер мөгамәләдә булуыгыз тиешледер, яисә [аны] Кырымга җибәрегез! Юкса, дуслыгыбыз киселеп, арабызда булган солых һәм килешүләр батыйль улыр, ягъни яраксызга чыгар»,— диде.

Бу хатны алгач, Иван Габдел-Латыйф ханны хәбестән азат итеп, мәрхәмәт итте, ләкин, Кырымга барып көч хасил итүеннән куркып, читкә чыгарга ихтыяр бирмәде[8]. [Габдел-Латыйф] шул хәлендә Мәскәүдә торып, 1518 елның ноябрендә вафат булды[9]. Вафаты хакында төрле фикерләр вә төрле имеш-мимешләр бардыр, хакыйкатен исә [бер] Аллаһы Тәгалә белер[10].

ИСКӘРМӘЛӘР (ГАБДЕЛ-ЛАТЫЙФ ХАН):

[1] Габдел-Латыйф — Ибраһим хан һәм Нур Солтан бикәнең кече улы, Казанда 1475 еллар тирәсендә туган.

[2] Әнисенең 1480 елда Кырым ханы Миңле Гәрәйгә кияүгә чыгуы сәбәпле, сабый шаһзадә Казаннан Бакчасарайга күчеп китә, балалык һәм үсмер елларын Кырымда үткәрә. Кырым ханлыгының Русия белән дустанә мөнәсәбәтләрен искә алып, Габдел-Латыйфның үги атасы Миңле Гәрәй, шаһзадә балигъ булу белән үк, аны урыс патшасы хезмәтенә Мәскәүгә җибәрә. Мәскәү хөкүмәте шаһзадәне якты чырай белән каршы ала, аңа удел-биләмә сыйфатында Русиянең төп шәһәрләреннән саналган Звенигород шәһәрен бирә.

[3] Габдел-Латыйфка үзенең биләмәсендә озак булырга туры килми. Мөхәммәд Әминнән шактый гайрәтләре чиккән Казан түрәләре Иван IIIдән ханлык тәхетенә Габдел-Латыйфны сорыйлар.

[4] С. М. Соловьевның язуына күрә, Габдел-Латыйфны Казан тәхетенә кенәзләр Семен Холмский һәм Федор Палецкий утырталар һәм яңа ханны да, барлык түрәләрне дә урыс кенәзенә тугрылык саклау турында ант иттерәләр.

[5] М. Г. Худяков хәбәренә караганда, 1499 елда Казан ханлыгының шәрекъ фиркасе Казанда Себер сөляләсен, ягъни ди-

Габдел-Латыйф хан. Рушан Шәмсетдинов рәсеме.

настиясен торгызырга омтылыш ясый. Бу хәрәкәт башында мирза Урак тора, ә тәхетне Мамук ханның энесе шаһзадә Агалак дәгъвалый.

[6] М. Г. Худяков версиясе буенча, Габдел-Латыйфның хакимлеге чорында идарәнең дилбегәсе мирза Калимәт кулында була. Хан яшь вакытта (тәхеткә 20 яшьләр тирәсендә утыра) Русия белән сәяси каршылыклар тумый. Әмма Габдел-Латыйфка 25 яшь тулганнан соң, ул мөстәкыйль сәясәт алып бара башлый, дәүләтнең милли мәнфәгатьләрен яклый һәм Русиягә карата кискен позициягә күчә. Урыс фиркасендә мондый сәясәт яклау тапмый, Казанда ханга каршы агым калыпплана. 1501 елның азагында Калимәт Мәскәүгә бара, анда урыс хөкүмәте даирәләре белән булачак хәлләр турында киңәшмә үткәрелә.

[7] 1502 елның гыйнварында Иван III Казанга кенәзләр Василий Ноздреватый һәм Иван Телешов җитәкчелегендә гаскәр җибәрә һәм Габдел-Латыйфны «тугрысызлыгы» өчен («начал лгать») кулга алырга боера. Икенче версия буенча, Габдел-Латыйф моның өчен әле генә Мәскәүдән кайткан Калимәт мирза тарафынан кулга алына. Карл Фукс язуына күрә, Иван III Габдел-Латыйфны Мәскәүгә богауланган («скованного») килеш китерергә фәрман бирә.

М. Г. Худяков Казан ханының Мәскәү тарафыннан әсир итеп алып42 кителүен чит илнең мондагы эчке эшләргә тыкшынуы, тыныч түнтәреш («переворот») дип атый, бу актны Казандагы шәрекъ фиркасенең бик зәгыйфьләнүе, Казан халкының милли үзаңы нык төшүе, горурлык хисенең җуела башлавы белән аңлата.

[8] Мәскәү хөкүмәте Габдел-Латыйф фигурасын зур сәясәт уенының бер уенчыгына әйләндерә, аны бер кулга алып, бер төрмәдән чыгарып, биләмәгә теге яки бу шәһәрне биреп яисә яңадан колак кактырып, Кырым хөкүмәтенә карата төрле хәйләләр оештыра, урыс идарәче даирәләренә якынлаштыргалап ала, ләкин Казан тәхетенә яңадан кайтармау өчен барысын да эшли.

[9] Икенче бер чыганакларда, 1517 елның 19 ноябре, дип күрсәтелә.

[10] М. Г. Худяков, Габдел-Латыйфның үлемен Мәскәүнең сәяси планнарына туры килүен шәрехләп, аны, политик омтылышларның («замыслов») корбаны булды, дип билгеләп үтә.

Габдел-Латыйфның үлеме күп нәтиҗәләргә китерә. Мөхәммәд Әминнән соң Казан тәхетендә Олуг Мөхәммәд сөляләсе киселә. Аның да, Габдел-Латыйфның да ир балалары калмый. Аларның сеңелләре Гәүһәршад бу вакытта Казанда яшәсә дә, аның кандидатурасы мәсьәләсе күтәрелми. Олуг Мөхәммәд

нәселенең соңгы вәкиле шаһзадә Ходайкул, 30 елдан артык Русиядә яшәгәнлектән, күптән урыслашкан була. Ул, шаһзадә Мәлик-Таһирның уллары кебек үк, чукына (Петрга әйләнә), марҗага өйләнә һәм Казан тәхетенә хокукын югалта.

Сүнгән династиянең иң якын кардәшләре соңгы ике ханның борадәрләре — Кырым ханы Миңле Гәрәйнең уллары, Кырым шаһзадәләре тора. Нур Солтан Миңле Гәрәйгә кияүгә чыкканлыктан, боларның уллары үги туганнар (сводные братья) хисаплана. Шул сәбәпле Кырым сөляләсе Казан тәхетенә дәгъвасын белдерә.

Габдел-Латыйф һәлак булганнан соң, Кырым хөкүмәте Василий III белән шаһзадә Сәхиб Гәрәйне Казан ханлыгының тәхет варисы итеп тану турында сөйләшүләр алып бара.

СӘХИБ ГӘРӘЙ ХАН

(1500—1551 елда вафат)

Мөхәммәд Әмин хан тумасы Сәхиб Гәрәй бине Миңле Гәрәйне хан итеп кую турында васыять итеп вафат булды. Һәм дә Кырым ханы Мөхәммәд Гәрәй бине Миңле Гәрәй тарафыннан җибәрелгән илче Аппак мирза белән Мәскәү кенәзе Сәхиб Гәрәйне хан итү хакында гаһед ясамышлар, ягъни килешү төзегәннәр иде.

Фәкать, эш болайга китсә, Казан белән Кырым бер ноктага җыелу лязим киләчәкне, ягъни тиеш булачакны вә бу хәл Мәскәү сәясәтенә мәхыз, ягъни бары тик зарар гына икәнен фикерләп, Василий бу килешүне бозды[1], вә шул көннәрдә Мәскәү кул астында Мещар (Касыйм) шәһәрендә торган Шаһ Гали бине Аллаярны Казан ханы итеп куярга карар бирде. Казан халкының бу турыда ризалыгын алыр өчен билкасд, ягъни атап, алдан уйлап, адәм күндерде. Казан халкы исә Шаһ Галинең хан булуына (Карамзин сүзенә күрә) риза булды һәм Шаһ Галигә үз тарафыннан илче җибәрде.

Ошбу сәбәптән Василий махсус адәмнәр вә гаскәрләр белән Шаһ Гали бине Аллаярны Казанга җибәрде вә, Казан тәхетенә утыртып, халкыннан бигать алдырып, ягъни буйсынуларын белдергәннәрен күрсәтеп, ант иттерде.

Кырым ханы Мөхәммәд Гәрәй тарафыннан илче сыйфатында Мәскәүдә торган Аппак мирза Василий янына кереп: «Мөхәммәд Гәрәй хан белән Сәхиб Гәрәйне Казан ханы итү хакында гаһед ясадың, ягъни килешү төзедең, моны вафа итәчәк җирдә, ягъни сүздә торасы урынына безнең дошманыбыз булган Сәед Әхмәд хан хафиде, ягъни оныгы Шаһ Галине Казан ханы итеп билгеләдең, бу

исә хыянәттер, Казан ханлыгы Шаһ Галигә түгел, бәлки Сәхиб Гәрәйгә тиешле»,— дип шелтә итсә дә, Василий: «Бу эш минем ихтыярымда булмады, мин Сәхиб Гәрәйне хан итәр өчен тырыштым, фәкать Казан мөселманнары, үзләренә ханлык өчен хаслап, Шаһ Галине сорадылар вә шуннан башкага риза булмаячакларын бәян кылдылар»,— дип җавап бирде һәм мирзаның да кесәсен тутырды. Шуңа күрә Аппак мирза, Кырымга кайтып, Казан турында Василийны гаепсез итеп күрсәтте[2]. Ләкин Мөхәммәд Гәрәй хан Василий турында хәсән зан итмәде, ягъни яхшы фикердә булмады вә Казан эшләрендә хәйлә (бу турыда Казан мөселманнары тарафыннан мөфассал, ягъни җентекле сурәттә язылган хат алуы мәзнундыр, ягъни уйланыладыр) коруын уйлап, үч алу чарасына кереште. Ниндидер бер форсат табып, Русиягә һөҗүм итте вә Мәскәү кенәзлегенә хисапсыз зарар салды.

Василий бу турыда үзен кыерсытылган итеп күрсәтеп, Төркия солтанына Мөхәммәд Гәрәй өстеннән шикаять итте вә шуңа күрә Төркиянең иң шөһрәтле солтаны булган Сөләйман Кануни Русиягә бу рәвештә зарар салмасын өчен Мөхәммәд Гәрәй ханга катгый фәрман бирде. Гәрчә Мөхәммәд Гәрәй махсус илче җибәреп: «Мәскәү кенәзлеге көннән-көн көчәядер, һәр җирдә исламнарга зарар тидерәдер, басып алган урыннарында мәчетләрне чиркәү итәдер, әгәр дә бу хәл дәвам итсә, бер вакыт моның бөтен әһел ислам өстенә мөсәлләтъ булачагында, ягъни җиңеп, кул астына алачагында шөбһә юк, шуның өчен беркадәр ихтият, ягъни саклык юлында булырга тиешле!» — дисә дә, ул вакыт Василий солтан тарафына йөрүче муллалар белән пашаларның догаларын алган иде. Шул сәбәпле солтанның муллалары вә пашалары Василийны хаклы, Мөхәммәд Гәрәй ханны хаксыз таптылар. Мөхәммәд Гәрәй хан да моннан соң Василийның һәрбер яхшы вә яман эшләренә «ярхәмәкә Алла», ягъни «бирсен Алла» укып утырырга мәҗбүр булды.

Истанбул тарафыннан бәрәкәтле эш тапмагач, Мөхәммәд Гәрәй хан Казан халыклары белән могарәфә итәргә, ягъни белешергә вә алар белән хәбәрләшергә кереште. Хәлбуки Казан халкы Шаһ Галинең Мәскәү файдасына хәрәкәт итүеннән риза түгел иде. Бу хәлне белеп һәм Казан халкыннан сүз алып, [Мөхәммәд Гәрәй хан] Кырым гаскәре белән Сәхиб Гәрәйне[3] Казанга җибәрде.

1521 ел яз көне Сәхиб Гәрәй Казан шәһәренең капкасына килеп туктады, Казан шәһәренә кереп тәхеткә утырды[4],

Шаһ Галине вә рус тарафында торучы назыйрларны, ягъни идарә башындагы кешеләрне барысын да кулга алдырды[5]. Моннан соң Шаһ Галигә теләгән җиренә китәргә рөхсәт бирде. Шаһ Гали, хатыны вә балаларын алып, балыкчылар көймәсенә утырып, Мәскәүгә юлланды[6].

Василий Казан вакыйгалары белән әвәрә булып торган бер сәгатьтә Мәскәүгә: «Нугай вә Польша халыклары белән иттифак итеп, ягъни берләшеп Мөхәммәд Гәрәй хан Русиягә һөҗүм итәдер»,—дигән куркыныч бер хәбәр килде. Великий кенәз Кырым чирүенә, ягъни гаскәренә каршы гаскәр җибәрде. Ләкин гаскәр башлыклары сугыш гыйлемен үзләре белмәгәнгә вә белүчеләргә дә киңәш итмәгәнгә яки белүчеләрнең киңәшләрен тотмаганга, хан гаскәре белән сугыша алмадылар. Хан исә Ока елгасыннан чыкты, рус гаскәре качты. Кенәз Владимир Курбский, кенәз Шереметев кебек баһадирлар сугышта һәлак булдылар, кенәз Федор Оболенский әсир төште. Нәкъ шул вакыт Сәхиб Гәрәй ханның Идел буенча Казан гаскәре белән Мәскәү өстенә килүе ишетелде. Ошбу сәбәптән ни кылырга белмичә, Василий тәмам хәйранлыкта калды.

Казан вә Кырым чирүләре Коломна шәһәре янында бер-беренә кушылдылар, Мәскәү гаскәрен кырдылар, һәлак иттеләр, әсир алдылар. Бату хан белән Туктамыш хан вакыйгаларын икенче мәртәбә кабатладылар. Ике гаскәр берлектә мөнтазам, ягъни тәртипле рәвештә Мәскәү өстенә йөрделәр. Великий кенәз Василий Мәскәүне чукынчык кияве Петр (Ходай Бирде[7] бине Ибраһим хан әл-Казани) кулына тапшырып, үзе Волок шәһәренә качып китте. Куркуыннан Мәскәү халкы ни кылырга белмәде. 1521 елның 29 июнендә хан Мәскәүдән ерак түгел җиргә килеп туктады. Моны күреп, Мәскәү халкы кремльгә кача

башлады. Урамнар ат, арба, хатын-кыз, бала-чага белән тулды, низам вә тәртип тәмам бетте, капкалардан кергән вакытта бер-берсе өстенә егылып, тыгызлашып торалар иде. Мәскәүдә туп ату гыйлемен белүче бер нимсә, ягъни немец булса да, дары юклыктан туп белән нимсәдән файда булачак түгел иде.

Һәр җирдән өметләре өзелгәннән соң, Мәскәү халкы бүләкләр белән илчеләр җибәреп, хан хәзрәтләреннән солых үтенделәр. Хан исә боларның үтенечләрен кабул итте, Мәскәү тарафыннан һәр ел дань түләнеп тору шарты белән солых язылды[8]. Бу язуны Василийга җибәргәч, [ул] бик шатланып печәтен басты. Хан үз гаскәре белән Кырымга, Казан гаскәре Казанга кайтып киттеләр.[9] (Мөхәммәд Гәрәйнең ашыгып кайтып китүенең сәбәбе: Борһан паша Азовский исемле бер адәмнең хатларыннан аңлашылганча, Карамзин, Әстерхан ханнары тарафыннан Кырым мәмләкәтенә һөҗүм итәргә хәзерләнү хәбәрләре килүедер, дип күрсәтәдер. Т. 7 (X), 22 б.) Мәскәү халкы бу бәладән котылып калуларының шөкеранасы өчен һәр ел 29 июньдә дини бәйрәм итәләр (Питрау бәйрәме)[10].

Мөхәммәд Гәрәй хан, Кырым, Казан, хәтта ки Нугай, Төркестан вә Сибирия вилаятьләрен бергә кушып, көчле бер Ислам дәүләте төзү теләгендә иде. Ошбу планы буенча 1522 елда Әстерхан вилаятен яулап алды[11]. Әгәр дә тәдбир белән, ягъни эшнең ахырын уйлап хәрәкәт иткән булса, Мөхәммәд Гәрәй хан бу морадына, ягъни теләгенә җиңел рәвештә җитәчәк, хәтта ки Иран белән Мәскәүне яулап алып, Ауропаны тетрәтәчәк иде. Фәкать төрек вә татар халкында баһадирлык булса да, тәдбир, ягъни эшнең ахырын уйлау юктыр, шушы тәдбирсезлекләре сәбәпле баһадирлыклары белән хасил иткән дәүләтләрен бер сәгать эчендә харап һәм әрәм итмәктәләр. Шул сәбәпле Мөхәммәд Гәрәй хан бу морадына ирешә алмады. (Бу сүзләрне Карамзин сөйләмештер. Чыннан да, төрек вә татарларның тарихларын тикшергәннәргә боларның гадәттән тыш баһадир вә гайрәтле, мөрәүвәтле, ягъни егетлекле, мәрхәмәтле вә шәфкатьле, әмма тәдбирсез икәнлекләре ачык күренеп торыр.)

Мәскәү кенәзе Василий Мөхәммәд Гәрәй ханның бу фикерен тәмам белеп торыр һәм шуңа күрә Кырым белән Казанны бер-береннән аерыр өчен чара вә форсат күзәтер иде.

Мөхәммәд Гәрәй ханның Әстерханны яулап алуын ишеткәннән соң Сәхиб Гәрәй хан Казанда булган Мәскәү

илчесе Василий Юрьевны[12] вә Мәскәү иярченнәрен үтертте һәм малларын кулга төшерде[13]. Моны ишетеп Мәскәү халкы бик мөтәәссир булды, ягъни кайгы-хәсрәткә төште вә ифрат дәрәҗәдә кайгырды. Бу вакыйга 1523 елның яз көнендә булды. Фәкать Мәскәүгә ошбу хәбәр белән берлектә Кырым ханы Мөхәммәд Гәрәйнең үтерелү хәбәре дә ирешеп (Нугай мәфсидләреннән, ягъни провокаторларыннан Мамай белән Агиш тарафыннан үтерелде, яше 85 тә иде. «Камусел-галәм» вә Карамзин хезмәте), Мәскәү халкының шатлануына сәбәп булды[14].

Сәхиб Гәрәй ханнан үч алыр өчен великий кенәз Василий гаскәр җыеп Казан өстенә бару теләге белән Нижгород шәһәренә килде вә шуннан Казан өстенә Шаһ Гали хан белән башкаларны җибәрде. Болар исә Сура суы Иделгә кушылган җиргә Васильсурск шәһәрен бина иттеләр вә моннан башка да Русия гаскәре сыенып вә казанлыларга һөҗүм итәргә ярдәм бирәчәк кальгалар, ягъни крепостьлар ясадылар. Казан тәбәгаләрен, ягъни подданыйларын күп мәшәкатьләргә төшерделәр, җәй буе шул эш белән шөгыльләнеп, көз җиткәч Мәскәүгә кайттылар. Ошбу ел вөҗүдкә китерелмеш шәйләр, ягъни ясалган нәрсәләр ярдәмендә киләсе елда Казанны яулап алачакларында шикләре калмады. Бу вакыт иң ихлас белән хезмәт итүче вә рус гаскәрен тәртипкә салып, планнар корып йөрүче Шаһ Гали хан булыр иде.

Сәхиб Гәрәйнең, бу хәлләрне күреп, алдагы елда русларның Казан өстенә киләчәкләрендә шөбһәсе калмады. Фәкать, бердән, Казан эче тыныч булмаганга вә, икенчедән, Казан гаскәре белән генә русларга каршы торырга мөмкин күрмәгәнгә, Истанбулда солтан Сөләйман Кануни хозурына илче җибәреп, Казан мәмләкәтен үзенә табигъ, ягъни буйсынган хисап итүен һәм Казанны Василийдан саклавын үтенде.

Солтан Сөләйман Кануни бу вакытта бөтен җиһанны тетрәтеп торган куәтле вә шәүкәтле бер падишаһ иде. Әгәр дә [ул] Истанбулда тәхетендә яткан вакытта Василийга бармак кына селексә дә, Василий Казан тарафына хәтта күз дә салачак түгел иде, фәкать солтан Казанга гаскәр дә җибәрмәде вә җитди сурәттә Казан мәсьәләсенә керешмәде дә. Анчак, ягъни бары тик сәүдә мәсьәләсе белән Мәскәүгә җибәрелгән Искәндәр Мәнкубский[15] исемле (бу кеше солтан тарафыннан Мәскәүгә өч мәртәбә килде вә 1530 елда Мәскәүдә вафат булды. Карамзин, Т.

7, 156 б.) бер грек аркылы ошбу мәсьәлә хакында сөйләшергә кушты. (Христиан бер грек Мәскәүдә великий кенәз сараенда Казан мәмләкәтен Истанбул солтанына бирергә тырыша, мөселманнарны бер җиргә җыеп, көч хасил иттерергә тырыша, имеш! Карамзинның: «Төрек вә татарлар баһадирлар, әмма идарә вә тәдбирләре юк!» — дигән сүзе дөрестер. Хәлбуки солтан Сөләйман Кануни Төркиядә иң шөһрәтле падишаһларның берсе иде. Мондый зур мәсьәләне христиан грек зиммәсенә, ягъни җаваплылыгына тапшыру хәмес халкының яһүди мөәзин яллап куюларыннан да гаҗәптер!)

Мәнкубский исә Казан мәмләкәтенең күптән бирле Мәскәү кул астында булуын вә шул сәбәпле Сәхиб Гәрәй ханның [аны] төрек солтанына бирергә хакы юклыгын рәсми сурәттә игълан итте. Шулай итеп, Сәхиб Гәрәй вә Казан мәмләкәте һич яклаучысыз вә ярдәмчесез калды.

Сәхиб Гәрәй хан Истанбулда сүзе үтмәвен вә солтан илчесе тарафыннан Казанның Мәскәү кул астында булып, үзенең бары тик ихтилялчы, ягъни фетнәче булып игълан ителүен ишеткәннән соң бөтенләй мәэюсь булды вә кай тарафка карарга да белми гаҗиз калды. Ахырда үзе солтан хозурына барып сөйләшсә, үзенең сүзе кабул ителәчәген, шул сәбәпле солтан исеменнән, Казан мәмләкәте солтан кул астында, дип игълан кылынуын өмет итеп, үзе махсус Истанбулга сәфәр кылырга карар бирде.

Казан мәмләкәтен бөтенләй басып алып, Мәскәү кенәзлегенә кушу нияте белән великий кенәз Василий 150.000 гаскәр тәртип итеп (икенче бер җирдә Карамзин бу гаскәрнең 180.000 икәнен риваять итәдер, Т. 7 (X), 26 б.), Казан өстенә җибәрде. Гаскәр башлыклары исә Шаһ Гали вә башкалар иде.

Бу хәбәрне ишеткәч, Сәхиб Гәрәй хан өчен бөтен дөнья тар булды вә элек биргән карарына нигезләнеп, [ул] Истанбулга барып солтаннан ярдәм сорарга кирәклеге турында катгый карарга килде.

Үзенең якыннарына шушы фикерне сөйләгән хәлдә, калган халыкка хаҗга баруын игълан итте вә үзенең бер тумасы Мәхмүд Гәрәй бине Миңле Гәрәй углы Сафа Гәрәйне урынына наиб, ягъни урынбасар рәвешендә куеп, үзе Казаннан чыгып китте. Бу вакыйга 1524 елның язында булды.

Чын хәлдән хәбәрсез булган халыклар Сәхиб Гәрәй ханның бу вакытта хаҗга китүеннән риза булмадылар,

җәбин вә данилегә, ягъни куркак һәм түбәнлеге сәбәпле качып китте, дип төһмәт иттеләр, ягъни яла яктылар[16].

Сәхиб Гәрәй хан Истанбулга барып максатын сөйләсә дә, сүзе илтифатсыз калды. Казан мәмләкәтен үз химаясендә, ягъни карамагында икәнен игълан итеп, Сәхиб Гәрәйгә гаскәр вә фәрман биреп Казанга кайтарып җибәрәсе урынга, солтан Сәхиб Гәрәй ханны Кырым ханы итеп Кырымга җибәрде, Казан күңелләрдән, хатирәләрдән чыгып, мөһмәл, ягъни ташланган килеш калды[17]. Ахырда төрек солтаннарының тәдбирсезлекләре (ахырын уйламый эшләүләре) сәбәпле Сәхиб Гәрәй хан 50 яшендә вакытта үтерелде[18]. Бу вакыйга 1551 елда Кырым вилаятендә булды.

Сәхиб Гәрәй хан Бакчасарай шәһәрендә хан сарае янында җәмигъ шәриф, ягъни җәмәгать мәчете белән берничә мәчет вә мәдрәсәләр бина иттерде, Итил, Җаек, Кубань, Дон, Днепр, Җөм, ягъни Эмба елгалары буенда чатыр белән йөрүче татарларны Кырым вилаятенә китереп берләштерде һәм һәрберсенә тиешле дәрәҗәдә җир биреп, биналар салып урнаштырды.[19] (Мөстәфадел-әхбар, Т. 1, 131—132 б.)

ИСКӘРМӘЛӘР (СӘХИБ ГӘРӘЙ ХАН):

[1] Мөхәммәд Әмин вафатыннан соң Казанда вакытлы хөкүмәт хасил була. Бу хөкүмәт Русия белән союз килешүе нигезендә Мәскәү хөкүмәтенә Казан тәхете мәсьәләсе буенча мөрәҗәгать итә, чөнки яңа хан дус дәүләт (союзное государство) хуплаган тәкъдирдә генә тәхеткә күтәрелә алган. Мәскәүгә Кол Дәрвиш дигән кеше илче итеп җибәрелә. Ул Мөхәммәд Әминнең үлү хәбәрен ирештерә һәм Мәскәүдән Казандагы тәхет варисы турында үз сүзен әйтүен үтенә. Русия хөкүмәте Габдел-Латыйф үлгәннән соң ук инде бу мәсьәләне үз файдасына хәл иткән була: Кырым хөкүмәте куәтләгән Сәхиб Гәрәй кандидатурасы кире кагыла, чөнки Мәскәү Кырымның бер династия ханнары нигезендә бик якынайган ике ханлык белән идарә итеп көчәюеннән курка. Мәскәү, Кырым ханы белән тыштан дустанә сөйләшүләр алып барса да, үз планнарын аннан яшерә һәм тәхет варисының исемен Мөхәммәд Әмин үлгәнче сер итеп саклый. Сарай ханы Әхмәд нәселе белән Кырым ханы Миңле Гәрәй һәм аның токымының аяусыз дошманлыгын истә тотып, Мәскәү хөкүмәте Кырым белән Казанны бер-берсеннән аеру

максатында Казан тәхетенә Гәрәйләрнең явыз дошманнарыннан булган Шаһ Галине куярга карар бирә.

[2] С. М. Соловьев язганча, Аппак мирза Шаһ Гали кандидатурасына риза булмавын белдерә, ләкин аңа, монысына риза булмасагыз, Гәрәйләргә тагын да дошманрак булган икенче бирәүне табарбыз, дип җавап бирәләр.

М. Г. Худяков күрсәткәнчә, әле 1516 елда ук Кырым хөкүмәте Шаһ Галинең мәрхүм атасы Аллаяр урынына Касыйм ханы итеп куелуына ризасызлык белдерә һәм Касыймның шаһзадә Сәхиб Гәрәйгә тиешлеге мәсьәләсен күтәрә. Ләкин урыс хөкүмәте моны кире кага.

[3] Сәхиб Гәрәй Миңле Гәрәй ханның улы һәм Кырым династиясенә нигез салган Хаҗи Гәрәйнең оныгы була, Бакчасарайда 1500 еллар тирәсендә туа, бөтен бала чагын Кырымда үткәрә. 1510—1511 елларда яшь шаһзадә үзенең үги анасы Нур Солтанны зур чит ил — Мәскәү һәм Казан сәфәрләрендә озата бара. В. Д. Смирнов, татар чыганакларына таянып, Сәхибне искиткеч гүзәл кыяфәтле итеп тасвирлый: «Он был красив лицом — совершенное полнолуние, льющее свет в созвездии миловидности».

[4] Сәхиб Гәрәйнең Казан тәхетенә бик ансат менүе шулар белән аңлатыла: Шаһ Галинең Казанда бернинди абруе булмый. Худяков сүзләре белән әйткәндә, яшь хан сараенда урыс кысымы («русское засилье») ахыр чиккә җитә. Дәүләт белән гамәлдә урыс илчесе Федор Карпов идарә итә, ул барлык эчке эшләргә тыкшына. Казанда даими рәвештә урыс хәрби отряды тора. Отряд, 1505 елдагыдай, урысларны сую кабатламагае, дигән сылтау белән кертелгән була. Урыска һәм ханга карата ризасызлык ике ел дәвамында куера. Наразыйларның башында углан Сәеди (Сиди) утыра. Оппозиция Кырым хөкүмәтендә табигый яклау таба. Бакчасарайга Казан тәхетенә Сәхиб Гәрәйне чакыру мәсьәләсе буенча илчелек җибәрелә. Сөйләшүләр көткән нәтиҗәләргә китерә, һәм 1521 елның язында Казанга тәхет варисы белән берлектә 300 кешелек Кырым отряды җибәрелә.

[5] Бу борылыш урыс илчесе Карпов белән воевода Поджогин өчен һич көтелмәгән хәл була. 300 кешелек отряд килүен белгәч, рәсми хакимият югалып кала һәм һичнинди каршылык күрсәтә алмый. Шаһзадә Сәхиб бернинди тоткарлыксыз шәһәргә керә. Казанда гарасат башлана: урыс кибетләре ватыла, Касыймнан килүчеләрнең һәм урыс сәүдәгәрләренең йортлары талана, барлык урыслар кулга алына. «Казан Елъязмачы»сының хәбәренә күрә, бу мәхшәрдә хан гвардиясендәге 5 мең Касыйм татары һәм Поджогин отрядындагы 1000 урыс сугышчысы һәлак була.

[6] Башка мәгълүматларга караганда, Шаһ Гали хан гвардиясе калдыклары (300 ләп кеше) белән качып котыла, Мәскәүгә кайтып Василий III тарафыннан кабул ителә, аңа яшәү урыны итеп Мәскәү билгеләнә.

[7] Башка чыганакларда Ходайкул дип күрсәтелә.

[8] М. Г. Худяков язганча, Василий III кимсетүле солыхка («унизительный договор») кул куярга — Кырым ханына формаль яктан буйсынырга һәм «борынгы заман уставы буенча», ягъни Сарай ханнарына түләнгәнгә, салым түләргә мәҗбүр була.

[9] Бу шанлы («блестящий») поход, дип күрсәтте Худяков, казанлыларга биниһая күп хәрби ганимәт, бихисап әсирләр һәм урыс хакимлегеннән («протекторат») азатлык алып килде.

[10] Шул ук шатлык һәм котылу хөрмәтенә Сретение дигән зур монастырь да бина ителә.

[11] Мөхәммәд Гәрәй Әстерханны нугай мирзасы Мамай белән берләшеп ала. Нәкъ шул вакытта Әстерхан ханы Хөсәен Мәскәү кенәзе белән союз төзү буенча сөйләшүләр алып барган була.

[12] Башка чыганакларда: Василий Юрьевич Поджогин.

[13] 1505 елдагы кебек үк, Казанда тагын бер суеш була, аерым алганда, барлык урыс сәүдәгәрләре үтерелә. Урыс елъязмалары билгеләп үткәнчә, «кан су урынына ага».

[14] Кайбер чыганакларга караганда, үтерелгән хан урынына тәхеткә менгән Сәгадәт Гәрәй (Мөхәммәд Гәрәйнең энесе) бу вакыйгадан соң Василий III дән 60 мең алтын һәм Сәхиб Гәрәй өчен тынычлык (солых) таләп итә һәм шул шартлар үтәлгән очракта Мәскәүгә союз вәгъдә итә. Күрәсең, зәгыйфьләнгән Кырым хөкүмәтенә ташламалар ясарга Василий III риза булмый, чөнки бу вакытта Кырым үзенең элекке союзниклары — нугайлар һөҗүменә юлыга.

[15] Икенче язылышы: Мангупский (Мангуп — Кырымдагы грек шәһәре, удел кенәзлеге үзәге). Худяков бу кешене Мәскәүдәге Төркия илчесе, грек-мөселман дип күрсәтә. Н. М. Карамзин язуынча, Искәндәр Мангупский урыс хөкүмәтенә рәсми рәвештә Казанның хәзердән Төркия йорты икәнен белдерә. Мәскәү хөкемдары моны инкяр итә һәм үз тарафыннан, Казан элек тә, хәзер дә, киләчәктә дә урыс патшасына буйсынуда булачак, Сәхиб Гәрәй фетнәче һәм аның Казанны солтанга бүләк итәргә хакы юк, дип белдерә.

[16] Зәки Вәлиди моның өчен Сәхиб Гәрәйне шелтәләп, «хакыйкатьтә сугыштан качып» китте, дип белдерә. С. М. Соловьев та шул фикердә. Ләкин урыс чыганакларының күбесендә аның Василий III яуларыннан куркып качуы турында мәгълүматлар

юк. М. Худяков язганча, Сәхиб Гәрәйгә кырыс табигатьле, төн ягы Казаны ошамый, ул яңадан Казан тәхетенә кайту турында уйламый, бәлки Кырым ханы булу хыялы белән яши һәм бу теләгенә ирешә дә.

[17] Шул ук М. Худяков Сәхиб Гәрәйнең төрек солтаныннан Казан өчен катгый рәвештә хәрби ярдәм соравын шик астына ала, аның төп максаты Кырым ханлыгы тәхете булган булырга тиеш, дигән фикерне алга сөрә.

[18] Сәхиб Гәрәй 1532 елда Төркия солтаны Сөләйман Кануни тарафыннан Кырым тәхетенә утыртыла. Тарихчылар аның хакимлеген мәгърур («блестящий») дип атыйлар, «Чыңгыз йортының шанын кайтаручы» дип тасвирлыйлар, бәрәкәтле реформаларын уңай яктан телгә алалар. 19 ел Кырым тәхетендә утырган Сәхиб Гәрәй 1551 елда Кавказга яу чаба һәм шул вакыт үзенең 13 яшьлек улы Шаһбаз Гәрәй белән берлектә Казан ханы Сафа Гәрәйнең улы шаһзадә Бүләк (Булюк) Гәрәй тарафыннан үтерелә.

[19] М. Г. Худяков бу зат турында язганда үтә җылы буяуларны кызганмый, аны бик югары бәяли. Мәсәлән, ул болай ди: «Хан Сагиб-Гирей был одним из замечательнейших государей на крымском престоле, но в Казанском ханстве он не успел себя проявить». Сәхиб Гәрәй, ди ул, төксе Идел ярларына караганда, Кара диңгезнең зәңгәрсу яр кырыенда падишаһлык кылуны артыграк күрде.

САФА ГӘРӘЙ ХАН

(1510—1549 елда вафат)

Сәхиб Гәрәй хан Казаннан киткәндә үз урынына наиб, ягъни урынбасар итеп Сафа Гәрәй ханны куйганы язылган иде. Сафа Гәрәй хан Сәхиб Гәрәй белән бер тума Мәхмүд Гәрәй бине Миңле Гәрәй углыдыр. (Карамзинның Фәеш Гәрәй угылы диюе ялгыш булса кирәк. Т. 7 (X), 26 б.) Казан тәхетенә чыкканда яше бары 13 тә иде[1].

Мәскәү гаскәре Казан мәмләкәтен басып алу нияте белән Казан тарафына юлланганнан соң[2], Сәхиб Гәрәй Казаннан китте вә Сафа Гәрәй хөкүмәт башына килде. Казан мөселманнары Сафа Гәрәй ханга бигать бирделәр, ягъни буйсынуларын белдерделәр, диннәре юлында җаннарын фида итәргә һәм ватаннарын сакларга ант иттеләр. Чуаш вә чирмеш кавемнәреннән гаскәрләр җыеп, Казан тарафын мәхкәм итәргә, ягъни ныгытырга вә Мәскәү гаскәренә бөтен көчләре белән каршы торырга керештеләр.

Ошбу 1524 ел 7 июльдә[3] Мәскәүнең су гаскәре, Казан янына килеп, Казаннан югары Гостиный остров исемле җиргә төште, вә шул урында үзләренең атлы гаскәре килеп җитүен 20 көн көтеп торды. Казан гаскәре боларга каршы чыкса да, җитди сугыш булмады, бары тик җиңел генә каршы торулар була иде[4].

Ошбу вакыт Шаһ Гали Сафа Гәрәйгә: «Казаннан яхшылык белән чыгып үзеңнең ватаныңа кит, бу кадәр каннар түгелүгә сәбәп булма!» — дип хат җибәрде. Моңа каршы Сафа Гәрәй: «Кем галиб булса, ягъни җиңсә шул падишаһ булыр, тәҗрибә итәргә тиешле!» — дип җавап бирде. Шул сәгатьтә, Казан эчендә торып та, Мәскәүгә сатылган мөселманнар Казан шәһәренең агачтан салын-

ган бер кальгасына, ягъни ныгытмасына ут салып яндырдылар[5]. Мәскәү гаскәре әлеге кальганың янып көл булуын карап торды. Аз гына булса да бер хәрәкәт күрсәтә алмады. Казан халкы бу янган кальга урынына иркенләп агачтан койма куеп, тәмам ныгытты[6].

28 июльдә Мәскәү гаскәре Иделдән Казан тарафына чыкты вә Казан елгасы буена урнашты, бу вакытта зур сугыш булмады. Фәкать казанлылар тирә-якта азыкларны яндырып бетергәнлектән, Мәскәү гаскәрләренең ашарларына бетте, [казанлылар] барлык юл вә кичүләрне дә үз кулларына алганнар иде. Һәкъ шул вакыт Мәскәү гаскәре арасында: «Мәскәүнең атлы гаскәрен Казан халкы бозган һәм тараткан, имеш»,— дигән бер хәбәр таралды. Мәскәү сәргаскәрләре, ягъни гаскәр башлыклары бу хәбәрдән тәмам шашып калдылар, кире китәргә дә курыктылар. Чөнки артларын чуашлар, чирмешләр тәмам урап алмышлар, юлларын кисмешләр иде... Ул-бу була калса, Кама елгасына чыгарга вә аннан кайтып китәргә кирәк, дип карар биргәч кенә, атлы гаскәрләренең бик сәламәт булып, Казаннан бары 20 чакрымдагы «Свияга» исемле урында булуларыннан хәбәр алынды. Чыннан да, болар чуашлар, чирмешләр тарафыннан уралып алынсалар да, беркадәр сугыштан соң сафларын ерып чыкмышлар, чуаш вә чирмеш гаскәрләрен кумышлар, имеш. Мәскәү гаскәре арасында таралган хәбәрнең асылы шул иде. Бу атлы гаскәр сугышында казанлылардан яралы һәм үлүчеләр барлыгы 42.000 булмыштыр. Сәргаскәрләре Отучы Көчле белән кенәз Аталык иде.

Нижгородтан Идел буенча көймәләр белән азык, гаскәр, корал, дары вә ядрәләр төяп килүче кенәз Иван Палецкийга чирмешләр каршы чыктылар. Иделгә таш вә бүрәнәләр салып, юлын кистеләр, шул сәбәпле көймәләр бер-беренә һәм дә таш вә бүрәнәләргә сугылып, бозылып, гарык булып, ягъни батып беттеләр. Кенәз Палецкий көч-хәл белән качып котылды, янында булган әсбапларын чирмешләр вә татарлар ганимәт итеп алдылар. Мәскәү гаскәрен дә утын урынына турадылар, күбесе суга батып үлде (Рычков).

Кенәз Палецкий янында калган адәмнәре белән Казан янында Мәскәү гаскәренә кушылды[7]. 15 августта сугыш башланып, казанлыларның маһир, ягъни оста тупчыларыннан булган бер мәшһүр адәмнәре шәһид булды. Шуның сәбәбеннән казанлыларның туп атулары зәгыйфьләнде вә араларына зур курку төште. Моны күргәч,

Мәскәүгә ялланып килгән Литва нимсә тупчылары Казан өстенә һөҗүм итәргә ниятләсәләр дә, Мәскәү сәргаскәрләре рөхсәт бирмәделәр[8].

Казанлылар никадәр курыксалар да, Мәскәү сәргаскәрләре алардан артык куркырлар, фәкать берберенең хәлләрен белмәсләр иде. Ахырында солых булып, Мәскәү гаскәре кайтып китте. Казанлылар тарафыннан Мәскәүгә бер илче һәйәте, ягъни миссиясе баруы, Сафа Гәрәй ханны хан итеп великий кенәз тарафыннан раслатуы, Казанның Русия химаясендә, ягъни йогынтысы астында игътибар ителүе — шушы солыхның шартларыннан иде. (Солых мәсьәләсе кайсы тарафтан гарыз ителгән иде? Русча тарихларда бу турыда мәгълүмат күренмәде. Әмма рус тарихчыларының бу җирдән (мәсьәләдән) гаҗәлә, ягъни ашыгыч тайпылуларына игътибар итсәң, [солых] Мәскәү тарафыннан тәкъдим ителгәндер, дигән фикер урынлы булыр[9].)

Моңа муафыйк, ягъни бәйле рәвештә Казан тарафыннан Василий хозурына бер илче миссиясе килде. (Илче миссиясе Аппак углан, Бәхет Килде кенәз вә башкалардан тора иде.) Василий исә казанлылардан рәһен, ягъни әманәт-заложник алып солых килешүенә кул куйды[10]. Ләкин рус сәүдәгәрләрен һәр ел җәй көне Казан шәһәрендә була торган мәшһүр ярминкәгә (Макарья ярминкәсе элек вакытта Казан шәһәрендә булмыштыр) барудан тыйды, вә Азия халкы белән рус халкы мал алмашыр өчен Идел өстендәге Нижгород вилаятендә Макарьев исемле урынны тәгаен итте, ягъни билгеләде[11]. Ошбу солых 5 ел дәвам итте. Һәрхәлдә Сафа Гәрәй хан белән Мәскәү арасы бу вакытта тыныч торды. Мәскәү тарафыннан [Казанга] илче булып барган Андрей Пильемов хан һәм зур дәүләт эшлеклеләреннән ямин вә гаһед, ягъни ант һәм вәгъдә алды.

Василий тарафыннан Казанга җибәрелгән Иван Палецкий, Нижгородтанмы, әллә Казан шәһәренә үк җитепме, кире кайтканнан соң, Сафа Гәрәй хан өстеннән Василийга шикаять итте һәм: «Сафа Гәрәй Казан халкын Мәскәүгә каршы котырткан вә аларны үзенә иярткән, үзләренә файдалы икенче бер солых төзергә хисап итәләр»,— дип сөйләде[12]. Василий исә, моның сүзенә ышанганлыктан, [Казан] өстенә барырга дип гаскәр җыйды.

Хисапсыз гаскәр вә Иван Бельский, Михаил Глинский, Горбатов, Кобенский, Оболенский кебек мәшһүр гаскәр

Татар яугирләре. Рем Шәмсетдинов рәсеме.

башлыклары белән берлектә корыдан һәм судан Казан тарафына сәфәр иттеләр. Бу вакыйга 1530 елда иде.

Сафа Гәрәй хан бу хәбәрне ишетеп, Мәскәү гаскәренә каршы торырга хәзерләнә башлады. Чирмешләрдән гаскәр җыйды да каенатасы булган нугай ханы Мамай тарафыннан 30.000 атлы гаскәр китертте. Болак белән Арча кыры арасына вә аннан Казан елгасына кадәр булган урыннарга, ике тарафына да койма салдырып, уртасына туфрак белән таш тутыртты.

10 июльдә казанлылар белән мәскәүлеләр арасында сугыш башланды. Казанлылар үлемнән һич курыкмый сугышырга керештеләр. Фәкать көндез гадәттән тыш гайрәт белән сугышкан хәлдә, кичләрен игътибарсыз булырлар, сугыштан туктагач, иркенләп йокларлар иде. Каравылчыларның йоклауларын Мәскәү гаскәре ай яктысында күреп белгәнлектән, ныгытмага кадәр барып, агач диварларга сумала вә май сөрттеләр, коры печән китереп ут төрттеләр. Ныгытманың шушы җире янып ачылды, бу җирдән Мәскәү гаскәре шәһәргә керде, йоклап яткан халыкны өйләргә кереп үтерделәр. Төрле җирләргә ут салдылар, 60.000 кадәр җан иясен кылыч белән вә яндырып тәләф, ягъни һәлак иттеләр. Казан баһадирларыннан мәшһүр сугышчы Аталык шул вакыт тәләф булды. Сафа Гәрәй хан Казаннан чыгып Арча шәһәренә качты. Бу вакыйга июльнең 16—17 көннәре арасында булган иде. Әгәр дә бер һөҗүм итсәләр, Мәскәү гаскәренең тәмам шәһәргә кереп басып алачакларында шөбһә юк иде. Чөнки Казанда сәламәт калган гаскәрнең мәҗмугы, ягъни барлыгы 12.000 микъдарында гына торып калган иде. Чирмешләр рус гаскәрләренең ни кадәр азыкларын, малларын талап алсалар да, Мәскәү гаскәре һәмишә, ягъни һаман да күп вә көчле иде. Сафа Гәрәй ханның гаскәр җыеп килүеннән куркып булса кирәк, Мәскәү гаскәре ошбу сәгатьтә казанлылар белән солых итте дә, Мәскәүгә кайтып китте[13].

Казанлыларның мәшһүр вә абруйлы адәмнәреннән булган Тагай, Тәүкил, Ибраһим кебек кемсәләр, ягъни кешеләр, Мәскәүгә килеп, кенәздән гафу үтенделәр. Кенәз исә Казан халкыннан ямин вә гаһед, ягъни ант һәм вәгъдә алмак, чирмешләр тарафыннан таланып алынган сугыш коралларының кире кайтарылып бирелүен шарт итте һәм әлеге Казан илчеләрен рәһен, ягъни әманәт-заложник хисап итеп, Казан халкыннан вә Сафа Гәрәй ханнан гаһед алыр өчен илче җибәрде. Сафа





Сугыш атының корыч битлеге. XVI—XVII гасырлар.
Алтынланган корыч баш киеме. XVI—XVII гасырлар.

Гәрәй моны ишеткәч, бу шартларны рәд кылды, ягъни кире какты, вә Василийның илчесен тотып алды да Василийга: «Безнең илчеләребезне кайтарыгыз, бездән алынган әсирләрне вә сугыш коралларын да үзебезгә сәламәт җибәрегез, юкса шартларны җиренә җиткерергә мөмкин түгел»,— дип язды.

Бу хатны укыгач, Мәскәү боярлары Казан илчеләрен каты орыштылар. Моңа каршы кенәз Тагай: «Без монда хәйлә белән түгел, бәлки чынлап торып солых итәргә вә Мәскәү белән яхшы торыр өчен килешү ясарга килдек. Безнең бөекләребез вә баһадирларыбыз сугышта үлеп беттеләр. Сафа Гәрәй үзенең кырымлылары вә нугайлары белән теләсә ни эшләр, безнең үзебезнең фикеребез

бар, без үзебез бу көндә сәламәтләрбез, Сафа Гәрәйне куарбыз, великий кенәз безгә үзе теләгән кешене хан итеп куйсын!» — диде.

Моңа каршы исә боярлар кенәз исеменнән: «Мәскәү өчен Сафа Гәрәй хан булса да, башка хан булса да — барыбер, фәкать сүзегездә торыгыз!» — диделәр. Тагай исә сүзендә дәвам итеп: «Шаһ Гали хан великий кенәзгә мохлис, ягъни ихласлы иде, халык өчен дә зарарсыз иде, фәкать аны дошманнар җиңделәр, шунлыктан ханлыгын дәвам итә алмады. Шуңа күрә безнең белән бергә Шаһ Галине Васильсурск шәһәренә кадәр җибәрегез, аннан исә казанлылар, чирмешләр вә Арча түрәләре белән хәбәрләшербез. Без Шаһ Галине алып килдек, Сафа Гәрәйне газел итеп, ягъни төшереп Казаннан чыгарыгыз, диярбез. Әсирләрне сәламәт кайтару өчен һичбере бу фикергә каршы тормас», — диде.

Великий кенәз, үзенең боярлары белән киңәш иткәннән соң, Казанга илчеләрен җибәрде, Казан ханы итеп куелыр өчен Шаһ Галине Нижгород шәһәренә юллады. Кенәз Тагай сүзендә торыр өчен Казан халкына Сафа Гәрәйне төшереп, Шаһ Галине хан итү хакында хат язды, бу эш булса, Казан әсирләренең Мәскәүдән кайтарылачагын бәян итте. Бу хатны алгач, Казан халкы Сафа Гәрәйне урыныннан төшерде. Сафа Гәрәй үзенең хатынын атасына — нугай ханы Мамайга кайтарып җибәрде, үзе дә кырымлылар вә иярченнәре белән Казаннан чыгып китте. Сафа Гәрәйне урыныннан төшерергә вә Казаннан чыгарырга, моның урынына Шаһ Галине китереп, хан кылырга тырышлык итүчеләрнең башында Мөхәммәд Әмин хан тумасы Гәүһәршад бикә (Ибраһим хан кызы) булыр иде. Моннан соң Сәед углан, кенәз һәм мирзалар тарафыннан Сафа Гәрәй ханның урыныннан төшерелеп, Казаннан китүе игълан ителде[14]. Һәм дә [болар], әгәр дә Шаһ Гали хан булып килсә, беренче мәртәбә үзен ханлыктан төшерүгә сәбәпче булганнарга зарар китерер, шуның өчен Шаһ Гали урынына Җан Гали хан булсын иде, дип Василийдан үтенделәр. Шуңа күрә Василий Җан Галине хан итеп җибәрде[15]. Бу вакыйга 1530 яки 1531 елда булды. Сафа Гәрәйнең бу чорда булган ханлыгы 6 ел микъдарында булмыштыр.

Сафа Гәрәй Кырым вилаятенә үзенең атасы белән бер тума Сәхиб Гәрәй хан хозурына кайтып китте. Сәхиб үзе, Мәскәү тарафыннан мәҗбүр буларак, Казанны ташлап чыгуы өстенә Сафа Гәрәй ханның да шул рәвештә кайтып

килүенә, табигый, шат булмады, Мәскәүдән үч алырга карар бирде. Сафа Гәрәйнең үзенең дә шундый фикердә булуында шөбһә юк.

Сафа Гәрәй ханның дәляләте, ягъни юл күрсәтүе белән 1533 елның августында Кырым гаскәре Русия өстенә килде[16]. Великий кенәз үзе 15 августта Коломна шәһәренә килде вә кыйммәтле әйберләрне кремльгә ташырга боерды. Кырым чирүсе, ягъни гаскәре, тәмам галәбә илә, ягъни җиңүче сыйфатында Рязань вилаятенә килеп керде. Мәскәү гаскәрен каршыларында күргәч, куркуларыннан кире чигенгән кебек булдылар. Мәскәү гаскәре боларны куарга кереште. Бу хәл кырымлыларның бары тик уеннары гына булганлыктан, мәгълүм бер җиргә җиткәч, кире борылып, Мәскәү гаскәренә һөҗүм иттеләр, беркадәр гаскәр башлыкларыннан башкаларны тәмам кылычтан кичерделәр. Биш көн эчендә тәмам җиңеп, сугышны тәмам иттеләр.

Менә бу вакыт Сафа Гәрәй великий кенәз Василийга: «Казанда хан булып торган чагымда һич вакыт синең җиреңә кермәдем, усаллык кылмадым, киресенчә, син үзең һәрвакыт миңа золым итеп тордың вә һәрвакыт өстемә гаскәр җибәрдең, хәтта мине ханлыкны ташлап чыгарга мәҗбүр иттең, фәкать барыбер Аллаһе Тәгалә миңа куәт бирде вә синнән үчемне дә алдым, моның белән эш бетмәс, моннан соң да гафил тормасам кирәк, ягъни абайламый калучы булмам»,—дип хат язды. (Рус тарихчылары һәрвакыт Казан ханнарын вә Казан халыкларын гаеп иткән кебек, Сафа Гәрәй ханлыгы дәверендә дә һәрбер кабахәт[лек]не Сафа Гәрәй өстенә ташларлар. Фәкать боларның мондый пәрдәләре кайбер вакыт рәгымнарына хилаф уларак, ягъни белә торып начарлык кылуларына карамыйча ачылыр. Сафа Гәрәй ханның бу хаты да рус тарихчыларының хаксыз икәнен күрсәтер.) Ләкин бу хат килгәндә Василий шушы вакыйга кайгысы белән хәстәләнеп, түшәгенә кермеш вә соң сулуларын сулап, үлем көтеп ятмыш иде[17].

Казанда Җан Гали хан үтерелгәннән соң[18], Казан халкы ханлык итәр өчен яңадан Сафа Гәрәйне чакырды. Сафа Гәрәй, вакыт үткәрмәстән, Кырымнан Казан шәһәренә килеп кердә вә, тәхеткә чыгып, хөкем итә башлады[19].

Казан халыклары Сафа Гәрәйгә Җан Галидән тол калган Сөен Бикәне никахландырдылар. Казан халкы элеккечә ике фирка, ягъни партия булып, бере Казанның

мөстәкыйль тору тарафында вә икенчесе Мәскәү тарафында булып, Мәскәү теләгәнчә хәрәкәт итә, һәрбер зур вә кечкенә эшләрдә великий кенәзгә хәбәр биреп тора иде.Сафа Гәрәй бу мәртәбәсендә Казанга кереп хан булганнан соң, Мәскәү тарафдары булган мөселманнар Мәскәүгә: «Гәүһәршад бикә Ибраһим хан кызы белән Булат мирза Мәскәү тарафындалар, әгәр дә Мәскәүдән Шаһ Гали җибәрелер булса, аны кабул итәрләр вә Сафа Гәрәй ханны да урыныннан куарлар, Мәскәү идарәсенә буйсынырлар»,—дип яздылар. Шул сәбәпле Мәскәү тарафыннан Казан өстенә гаскәр җибәрелде вә казанлылар белән сугыш булды. Мәскәү гаскәренең бер өлеше җиңелеп, казанлылардан качты вә икенче бер өлеше сугышып, мөселман вә чирмешләрдән әсирләр алып кайтып, Мәскәүдә бөтен халык хозурында әсирләрне үтерделәр. Бу вакыйга 1536 елда булды[20].

1537 елның январендә Сафа Гәрәй Муром тарафына барса да, Мәскәүдән гаскәр чыгуын ишетеп, Казанга кайтып китте. Мәскәүлеләр Казанны басып алыр өчен дип зур гаскәр җибәрергә хәзерләнгәндә, Сафа Гәрәй хан тарафыннан илчеләр килеп, солых сорадылар. Мәскәүлеләр башта солыхны кабул итмәсәләр дә, бу хосуста, ягъни хакта Кырымнан Сәхиб Гәрәй ханнан да хат килү сәбәпле, чар-начар, ягъни ирекле-ирексез кабул иттеләр[21].

1540 елның декабрендә Сафа Гәрәй хан Нижгород вә Муром тарафларына һөҗүм итсә дә, бер яктан Мәскәү гаскәре, икенче яктан үзенең татарлары белән Шаһ Гали каршы килде, болар белән беркадәр сугышканнан соң, Казанга кире кайтырга мәҗбүр булды.

Сафа Гәрәйнең Булат мирза кебек дошманнары һәм Мәскәү файдасына хәрәкәт итүчеләре хат язып, Мәскәүдән Казанга гаскәр җибәрүне үтенделәр, әгәр дә шулай булса, Сафа Гәрәй ханны тотып Мәскәүгә җибәрәчәкләрен вәгъдә иттеләр. Фәкать бу вакыт Мәскәү өстенә Кырым ханы Сәхиб Гәрәй хан килгәнлектән, Мәскәү кенәзлеге Казан хаинәренең, ягъни хыянәтчеләренең теләгенә имтисал итә, ягъни ияреп үти алмады. Сәхиб Гәрәй хан сугышта җиңә алмаганлыктан, мәскәүлеләр шатландылар вә Казан тарафына җасуслар, ягъни шымчы-шпионнар җибәреп, Казанны кайнатырга керештеләр. Фәкать бу мәртәбәсендә Булат мирза үзенең кулыннан эш килмәячәген игътизар итеп, ягъни гафу үтенеп язды вә Гәүһәршад бикә дә Иван Грозныйга: «Казан бетәдер, Мәскәү бөекләнәдер!»—дип шатлык хаты юллады[22].

1546 елда[23] Мәскәү кенәзлеге Мәскәү белән Вяткадан Казан өстенә гаскәр җибәрде[24]. Болар һәр икесе бер көн вә бер сәгатьтә Казан шәһәренә килеп җитеп, бергә кушылдылар. (Бу гаскәр җибәрүнең сәбәбен Карамзин: «Казанлылар килешүгә турылыклы булмадылар, һаман Мәскәү җирләренә кереп, талап вә җәфа итеп бизар иттеләр, ягъни аптыраттылар», дип язса да, нинди килешүнең бозылуын вә ни җирдә мәскәүлеләргә җәбер вә җәфа салуларын күрсәтмидер. Рус тарих китапларын бик дикъкать белән моталәга итәргә, ягъни тикшереп хөкем чыгарырга, тиешле.) Казан халкының бу вакыйгадан бөтенләй хәбәре юк иде. Ошбу гаскәр Казан тарафларын яндырды, монда исә ханның үзенең махсус бинаралары да янды. Күп адәмнәрне үтерделәр. Күп ганимәтләр вә күп әсирләр алып кире кайтып киттеләр[25].

Сафа Гәрәй хан мөҗәррәд зан иләме, ягъни коры шик беләнме яки дәлил белән исбат иткәннең соңындамы, бу вакыйгада Казанда булган кайбер татар түрәләренең катышы барлыгын бәян итеп, шуларның кайсыберләрен Казаннан куды, ә кайберләрен үтертте. Бу түрәләрнең тарафдарлары Сафа Гәрәй ханга ачуландылар вә Иван Грозный исеменә хат язып, гаскәр сорадылар һәм Сафа Гәрәйне 30 лап Кырым түрәләре белән берлектә тотып бирәчәкләрен сөйләделәр. Иван, гаскәр җибәрергә вәгъдә итеп, бу түрәләргә хат язды, ләкин аңа кадәр Сафа Гәрәйне кулга алып торырга кушты. Хаин түрәләр Сафа Гәрәйне кулга алырга хәзерләнгәндә, Сафа Гәрәй, моны сизеп, үзенең иярченнәре белән Казаннан чыгып качты. Бу вакыт Казан шәһәренең эчендә фетнә вә сугыш чыкты. Кырымлылар һәм казанлылар ике тараф булып сугыштылар вә һәр ике тарафтан күп адәмнәр харап һәм әрәм булды[26]. Шул вакыт Сәед углан кенәз белән башка түрәләр Иван Грозныйга хат язып, үзләренә ханлык өчен Шаһ Галине җибәрергә сорадылар вә Русиягә турылыклы вә ихласлы булачакларына ант иттеләр, шуңа күрә Мәскәү ярдәме белән килеп, Шаһ Гали хан булды, ләкин бер айдан соң Казанны ташлап, яңадан качты[27].

Бу вакытта Сафа Гәрәй үзенең хатыны Сөен Бикәнең атасы нугайның Йосыф мирза хозурында тора иде. Казанда фетнә һаман басылмады, Казан халкы Сафа Гәрәй ханны яңадан чакырды. Сафа Гәрәй исә, өченче мәртәбә Казанга кереп, тәхетенә утырды[28]. Чура мирза кебек монафикъ, ягъни икейөзле түрәләрне үтертте вә боларның тарафдарларыннан 70—80 ләп түрәләр качып, Мәскәүгә

Иван Грозный хозурына киттеләр вә, Казан өстенә гаскәр алып килеп, Казанны алачакларын вәгъдә иттеләр. (Бу хәлләрдән хәбәрдар булганнан соң, Сафа Гәрәй хан Казан халкына инабәт итмәс, ягъни ышанмас булды, үзенең сакчыларын да нугай гаскәрләреннән куйды.)

Иван Грозный 17 яшенә чыккач хатын алды, үзенә «кайсар», ягъни цезарь, патша титулын бирде дә, үзе гаскәр башлыгы булып, Казан мәмләкәтен басып алу теләге белән беренче мәртәбә буларак сәфәргә чыкты. Бу 1548 елның декабрендә иде. Фәкать әлеге сәфәр Иван өчен мөбарәк, ягъни уңышлы булмады. Яңгыр явып юллар бозылды. Туп вә пушкалар юлларга ятып калыр иде. Нижгородтан 15 чакрым ераклыкта булган Ельняга мең төрле мәшәкать белән 2 февральдә килеп җиттеләр. Волга өстеннән барганда, боз өстенә су чыкты вә боз ватылып күп нәрсә су төбенә китте.

Иван Грозный исә, сәфәр мәшәкатеннән гаҗиз булып, Мәскәүгә кире кайтып китте. (7 мартта Мәскәүгә кайтып кермештер[29].) Бельский командасында булган гаскәрен Казанга Сафа Гәрәй өстенә җибәрде. Касыймда булган Шаһ Гали үзенең гаскәрләре белән Мәскәүгә ярдәм өчен сәфәр итеп, Бельский гаскәренә кушылды вә барысы бергә Казанга киттеләр.

Сафа Гәрәй хан боларны Арча кырында көтеп тора иде. Русларның алда булган гаскәрләре белән очрашып сугыштылар, ләкин бу сугышта Сафа Гәрәй гаскәре бозылды. Азык исемле баһадир вә башка мәшһүр сугышчылар мәскәүлеләр кулына төштеләр. Казанлылар үч алыр өчен Галицкий карьясенә, ягъни авылына килделәр исә дә, бу җирдә дә җиңелделәр вә иң шөһрәтле баһадир Арак монда үтерелде (1548 елның октябрендә[30]).

Сафа Гәрәй Казан шәһәрендә үзенең сараенда 1549 елның март (сәфәр) аенда вафат булып[31], хатыны Сөен Бикә белән ике яшендә булган угылы Үтәмеш Гәрәй калды. (Сафа Гәрәй ханның кабере Сөен Бикә манарасы янында булуы зан ителәдер, ягъни ихтимал күреләдер.) Соңгы мәртәбәдәге ханлыгы 14 ел микъдарында булды. Шулай итеп, Казанда ханлыгы тәхминән, ягъни якынча 22 ел булып, үлгән вакытта яше 40 та булмыштыр[32]. (Бөгелмә өязендәге Зәй елгасы буенда Надир авылында булган Котлукай карт балалары кулында булган иске шәҗәрәдән бер нөсхә күчереп җибәргәннәр иде. Шуның бер җирендә «Мөхәммәд Әмин Баһадир хан биргән тарханлык ярлыгыдыр. Вилаяте Казан шәһәрендә тарих ту-

гыз йөз егерме бер иде»,— дип вә икенче урынында: «Янә июль (?) фәттах, ягъни яулап алучы Сафа Гәрәй Бәһадир хан тарафыннан Болгари шәһәренә биргән тарханлык ярлыгыдыр. Тарих 933 тә иде, мөбарәк шәгъбән, ягъни бәхетле шәгъбан ае өстендә бирелде»,— дип язылмыштыр.

ИСКӘРМӘЛӘР (САФА ГӘРӘЙ ХАН):

[1] Кайбер чыганаклар буенча, Сафа Гәрәй Кырымда 1510 елда туа. М. Худяковның язуына караганда, ул Мөхәммәд Гәрәй, Сәхиб Гәрәй һәм Сәгадәт Гәрәйләрнең ир туганы Фатих Гәрәйнең улы була.

[2] 1524 елда Мәскәү хөкүмәте Казанга каршы яңа поход оештыра. Бу максат белән гаять зур гаскәр юлга чыга. «Казан Елъязмачысы» сугышчылар санын 150 мең, С. Герберштейн 180 мең, дип күрсәтә. Яу белән Казан тәхетен дәгъвалаучы Шаһ Гали дә килә. Урыс гаскәре Казан өстенә өч аерым чиру — ике су һәм бер коры җир гаскәре белән юнәлә. Яз көне җәелгән су белән килү планы тормышка ашмый, өч гаскәр килү вакытларын төгәл килештерә алмыйча, Казан төбенә төрле вакытларда килеп җитә. Өч чиру аерым-аерым Бельский, Симский һәм Палецкий тарафыннан җитәкләнә. Гомуми җитәкчелек кенәз Иван Бельский кулында була.

[3] Зәки Вәлиди бу датаны: 7 май дип күрсәтә.

[4] М. Худяков билгеләп үткәнчә, казанлылар Зөя елгасында урыс атлы гаскәренең юлын кисмәкче булып һөҗүм итәләр һәм 500 кешелек атлы отрядны кырып бетерәләр. С. Герберштейн бу турыда, әлеге отряд чирмешләр тарафыннан һәлак ителеп, күп булса 9 кешесе качып котылгандыр, ә авыр яраланган гаскәр башлыгы өч көн үткәч дошманнар кулында үлә, дип язды.

[5] С. Герберштейн сүзләренә караганда, Казанның крепость диварын урыс шпионнары («русские шпионы») яндыра.

[6] Урыс гаскәре бу мөмкинлектән файдалана алмый, чөнки көймәләренә һөҗүм вакытында тупларын югалткан була.

[7] Мәскәү гаскәренең икенче флотилиясе зур югалтуларга дучар була. Аларга Тау ягы чирмешләре уңышлы һөҗүм итә. Су гаскәре җитәкчесе Палецкий, казанлылар кулында һәркайсында 30 ар кеше булган 90 зур көймәне калдырып, үз көймәсендә көчкә качып котыла һәм төп гаскәргә килеп сыена. «Казан Елъязмачысы»ның теркәвенә караганда, бик күп эре һәм вак туплар су төбенә китә, бихисап кеше батып үлә яки куркудан суга сикерә. Җәй көне су кайткач, җирдә бик күп сугыш кирәк-

яраклары, туплар табыла. Чирмешләр аларны Казанга озаталар. М. Худяков язуынча, казанлыларның бу гүзәл җинүе мәшһүр 1469 елгы сугышны хәтерләтә.

[8] Мәскәү гаскәре Казанны урап алса да, хәрби уңышка ирешә алмый. Казанлыларның атлы гаскәре ныгытманың тышында кала һәм камаучыларга даими рәвештә һөҗүм итеп тора. Уңышка өметләнмичә, урыс командованиесе солых турында сөйләшүләр башлап җибәрә. Урыс елъязмасында язылганча, Мәскәү гаскәре Казан төбендә бер генә көн дә артык тормый, Русиягә бөтенләй буш килеш («с тщетою»), шатлык белән түгел, ә зур хәсрәт белән («с печалию великою»), кайтып китә.

[9] Зәки Вәлиди болай дип язды: «Василий бу сугыштан бик күп файдалар өмет иткән иде, соңында бик кайгырды һәм казанлылар белән, Сафа Гәрәйнең ханлыгына риза булып, солых итәргә мәҗбүр булды».

[10] Солых шартлары буенча, Мәскәү Сафа Гәрәйне Казан ханы итеп танырга мәҗбүр була. Ләкин С. М. Соловьев сүзләренә караганда, Василий III моның белән үз ихтыярына каршы килеп кенә ризалаша, казанлыларга каршы гаять ишле гаскәрен ул Сафа Гәрәй тәхеттә ныгысын өчен җибәрми. Кыскасы, яу чабу тиешле нәтиҗәне бирми, урыс хөкүмәтенең өметләре акланмый.

[11] Мәскәү хөкүмәте моның белән уңышсыз походының үчен кайтармакчы була. Ләкин бу адым үзен бик акламый. «Бу ярминкәне күчерүдән Московия казанлылардан ким зарар күрмәде»,— дип язды М. Худяков. Чөнки моның нәтиҗәсе буларак, Идел юлы белән Каспий диңгезеннән, Әстерхан базарыннан, Персиядән, Әрмәнстаннан килә торган малларның бәяләре бик нык күтәрелә яисә җитешми башлый, бигрәк тә Иделнең Казан тирәләрендә тотыла торган затлы балыкка, шул исәптән, кырпы балыгына, мохтаҗлык коточкыч арта. Урыс хөкүмәтенең тыю чаралары беренче чиратта урыс сәүдәгәрләренең кесәсенә суга. Әлеге товарларны алар хәзер ярминкәдә ала алмыйлар, бәлки базар бәяләреннән күп артык түләп, арадашчылардан сатып алырга мәҗбүр булалар. Русия сәүдәгәрләре хөкүмәтнең бу адымына зур ризасызлык белдерәләр. Н. М. Карамзин болай ди: «[Сәүдәгәрләр], падишаһ үзенә дошманнар эзли, дип зарландылар, шулай ук Казан җирендә шәһәр салуын да гаепләп чыктылар». Ярминкә урыс дәүләте территориясендә, Макарий монастыре янында тернәкләнгәнче шактый вакытлар үтә.

[12] Хәрби хәрәкәтләрнең яңадан башлану сәбәпләре үтә томанлы. Урыс елъязмасы бу турыда Сафа Гәрәйне гаепле итеп күрсәтә, янәсе, ул антын бозган һәм Василий IIIнең илчесе Пильемовны каты мәсхәрә иткән («нечесть и срамоту учинили велику»). Чынлыкта исә, Мәскәү хөкүмәтенә яңа баскынчылык өчен бер сылтау гына кирәк булган.

[13] Урыс елъязмасына таянып, М. Худяков бу вакыйганы икенчерәк тасвирлый. Һөҗүм итүчеләр Болак буендагы бер кальганың диварын алып, посад эчендә кисү-сую оештыралар, ләкин крепостьның үзен ала алмыйлар, чөнки бу вакытта казанлылар урыс укчыларына арбаларда китерелгән барлык ату коралларын, шул исәптән пищальләрен, тартып алалар. Урыс гаскәре ягыннан 5 воевода, шул исәптән алдынгы полкның командиры кенәз Оболенский-Лопата үтерелә. Казанлылар Аталык исемле баһадирларын югалталар. Урысларга парламентерлар — кенәз Булат, Апай углан һәм кенәз Табай (Тагай?) җибәрелә һәм тиз арада сугыш хәрәкәтләре туктатыла. С. М. Соловьев фикеренчә, төп ату коралы — пищальләрнең югалуы воеводаларның казанлылар тәкъдимен кабул итүе өчен җитәрлек сәбәп булган.

[14] Шулай итеп, Мәскәү яклы Казан түрәләре тарафыннан сарай түнтәреше (переворот) ясала. Сафа Гәрәй куылу белән шәрекъ фиркасенең иң мәшһүр вәкилләреннән Себер кенәзе Раст, Сафа Гәрәйнең аталыгы (остаз-тәрбиячесе) Гали Шаһкол һәм башкалар үтерелә. Казанда Гәүһәршад бикә җитәкчелегендә вакытлы хөкүмәт төзелә, аның составына мирзалар Кече Гали һәм Булат Ширин да керә.

[15] Василий III хөкүмәте Җан Гали кандидатурасына шунда ук фатиха бирә. Чөнки, ди Вельяминов-Зернов, бөек кенәзгә үз сүзендә торырга артык ихтыяҗ юк иде: теге борадәрме, монысымы — аңа барыбер, Казан тәхетендә бары тик Русиягә бирелгән кеше генә утырсын.

[16] Кырым гаскәренең башында, С. М. Соловьев язуына күрә, Ислам Гәрәй һәм Сафа Гәрәй тора.

[17] Василий III 1533 елның 3 декабрендә үлә.

[18] Җан Гали 1535 елның 25 сентябрендә үтерелә.

[19] Сафа Гәрәй Казан тәхетенә икенче мәртәбә сарай түнтәрше нәтиҗәсендә менә. Түнтәрештән риза булмаган Мәскәү яклы түрәләр Русиягә качалар һәм Казан тәхетенә Шаһ Галине күтәрү турында хыялланалар. Ватаннарын ташлап китүчеләр

арасында Шәгъбән һәм Шаһ Булат Япанчылар, Карамыш һәм Йәвлүш (Евлуш) Хурсулилар һ. б. була.

[20] М. Худяковның язуынча, 1536 елның гыйнварында Казан чирүе Нижний Новгородка килеп җитә һәм Балахнаны яндыра. Казан юнәлешендә чыккан Мәскәү гаскәре, Лысков тирәсендә хан чирүен очраткач, рухы төшеп, сугышырга кыймый һәм кире борыла. Шактый урыс сугышчылары чирүләрен ташлап китәләр һәм казанлылар кулына төшәләр. Шул ук елның җәендә казанлылар Кострома вилаятенә яу чабалар, урыс гаскәрен тар-мар итәләр һәм Кострома воеводасы кенәз Засекинны үтерәләр.

[21] Мәскәү хөкүмәте көчле Кырым ханлыгы белән арасын бозарга теләми, чөнки Сәхиб Гәрәй рәсми рәвештә үзенең Казан белән союзда икәнлеген һәм аны хәтта үз канаты астына алуын белдерә. Мәскәү хөкүмәте дә 1487 елдан соң беренче мәртәбә «Казан — безнеке, чөнки аны безнең бабабыз яулап алган иде», дип рәсми сурәттә игълан итә. Шулай да Сәхиб Гәрәй басымы астында Казанга яңадан кылыч тарту уеннан вакытлыча ваз кичә.

[22] Сафа Гәрәйнең икенче мәртәбә ханлык итүе бик тынычсыз була. Каршылыкларның сәбәбе Казан хөкүмәтенең үз эчендә ята, чөнки анда төрле фирка һәм юнәлешләрнең вәкилләре, шул исәптән Сафа Гәрәйне 1531 елда төшерүдә катнашкан Сафа һәм Булат мирзалар да керә. Табигый, хан үзенә тугрылыклы булган кырымлыларга таянырга мәҗбүр була, ә бу хәл җирле түрәләргә урыс хакимиятеннән дә яманрак булып күренә. 1541 елның язында Сафа Гәрәйгә каршы оппозиция оешып җитә. Башында Булат мирза торган бу төркем Мәскәү тарафын ала һәм Русия хөкүмәте белән ханны төшерү турында яшерен сөйләшүләр алып бара башлый. Мәскәү хөкүмәте Казанга каршы кичекмәстән походка әзерләнә башлый. Ләкин кенәз Иван Бельскийның хөкүмәте (Иван IV гә әле 11 генә яшь) 1542 елның гыйнварында төшү аркасында, яу булмый кала. Кенәз Шуйскийлар хөкүмәтенең чит ил сәясәте йомшак була һәм хәрби әзерлекләр туктатыла.

[23] Башка чыганакларда 1545 ел күрсәтелә.

[24] Бу поход Казандагы оппозиция инициативасына бәйле була.

[25] Әлеге поход стратегик яктан уңышсыз беткән 1469 елгы яуны хәтерләтә. Бер чирү Нижний Новгородтан, калган икесе

Вяткадан һәм Чердыньнан юлга чыга. Урыс берләштерелгән гаскәре Казан төбендә сарай түнтәреше хәзерләнеп беткәч һәм хакимиять ансат кына Булат мирза кулына күчкәч килеп җитәргә тиеш, дип планлаштырыла. Әмма гамәлдә заговор әле өлгермәгән һәм түнтәреш әле ясалмаган булып чыга. Поход нигездә уңышсыз бетә, елъязмачы теркәгәнчә, «күп казанлыларны үтерәләр һәм хан кабакларын яндыралар». Львов командалыгындагы Пермь отряды урыс гаскәрләренә кушылу өчен соңга кала һәм казанлылар тарафыннан тар-мар ителә.

[26] Сафа Гәрәйгә каршы заговор 1546 елның гыйнварында оештырыла. Хан икенче мәртәбә тәхеттән төшерелә. Кусәкнең юан башы кырымлыларга төшә, аларны күпләп үтерәләр.

[27] Бу турыда Шаһ Гали турындагы материалда тәфсиллерәк язылыр.

[28] Сафа Гәрәй, нугай мирзалары белән килешү төзеп, алардан зур гына хәрби көч ала һәм Казан тәхетен кайтарып алу өчен походка чыга. Шаһ Галинең көчсез хөкүмәте аңа бернинди дә каршылык күрсәтә алмый, җитмәсә, халык Мәскәү куйган ханга зур нәфрәт белән карый.

[29] С. М. Соловьев язганча, яшь патшаның бу беренче походы бик уңышсыз бетә, өстенә су чыккан Идел бозы ярылып, бик күп пушка һәм пищальләр, сугышчылар су төбенә китә. Роботка утравында Иван Грозный юл төшкәнен 3 көн көтә, ләкин көтеп җиткерә алмый. Иван IV Мәскәүгә күз яшенә күмелеп кайта.

[30] Сафа Гәрәйгә С. Микулинский җитәкчелегендәге алдынгы полк һөҗүм итә. Моннан соң воеводалар Казан төбендә 7 көн торалар, тирә-якны харап итәләр, ләкин үзләре дә шактый зарар күрәләр, аерым алганда Шереметев дигән бик абруйлы затларын югалталар.

Зәки Вәлиди казанлыларның соңгы еллардагы уңышсызлыкларын болай аңлата: «Ошбу көнгә кадәр казанлыларның үзләреннән чагыштыргысыз күп булган русларга җиңелми килүләре зур егетлектән башка бер эш түгел иде. Руслар белән өзлексез сугышу аларны какшата иде, ләкин Казанның асыл зәгыйфьлеге бу сәбәптән генә түгел иде. Олуг Мөхәммәдтән соң Казан тәхетенә зур икътидар иясе, ягъни булдыклы, көчле, бик тәдбирле ханнар утырганнары юк иде».

[31] Сафа Гәрәй хан көтмәгәндә бик тиз вафат була. Кинәт үлүенең сәбәпләре томанлы, һәрхәлдә, урыс елъязмасында

язылганча, исерек килеш битен-башын юганда юынгыч корпусына башы бәрелеп үлүе бер дә ышаныч уятмый, М. Худяков моны, хәзергечә әйтсәк, мигә кан саву (инсульт) белән аңлата(«с ханом произошел внезапный удар»).

[32] XVII йөз Кырым тарихчысы Мостафа әҗ-Җәннәби аның турында: «Сафа Гәрәй хан иң бөек һәм куәтле падишаһларның берсе булды. Ул 27 ел дәвамында хөкүмәт сөрде. Аның заманында дәүләт иминлектә яшәде, биләмәләре моның җиңүчән коралы химаясендә чәчәк аттылар»,— дип язды.

Вәлиди дә үз чиратында бу ханга югары бәя бирде: «Ул Казан ханнарының иң зурларыннан вә, артык тәдбирле булмаса да, икътидарлыларыннан иде. Сафа Гәрәйнең ханлык вакытлары Казанның иң мәгъмүр, ягъни төзек, бай вә сәүдәсе куәтле вакытлары иде».

ҖАН ГАЛИ ХАН

(1516—1535 елда вафат)

Җан Гали хан Сарай ханнарының балаларыннан вә Касыйм шәһәренең ханнарыннан булган Аллаяр ханның угылы иде[1]. (Алтын Урдада булган Әхмәд ханның хафиде, ягъни оныгы икәне риваять ителәдер.)

1531 елда Казан кенәзләреннән Булат, үзенең иярченнәре белән берлектә, Сафа Гәрәй ханны урыныннан төшереп, Казаннан куып җибәргәннән соң, Мәскәү кенәзеннән үзләре өчен хан итеп Шаһ Гали ханның бер тумасы булган Җан Гали бине Аллаярны җибәрүен сорадылар[2]. Великий кенәз үзенә садыйк, ягъни тугры хезмәт итү хакында ант иттереп, күп адәмнәр белән Җан Галине Казан шәһәренә җибәрде. Бу вакыт Җан Гали унбиш яшендә иде.

Иң олугларыннан башлап иң кечекләренә кадәр Казан халкы барысы Җан Галигә ант итте, падишаһ хатын (Гәүһәршад бикә булса кирәк) вә сәедләр, ягъни аксөякләр, һәммәсе бигать бирделәр, ягъни буйсынуларын белдерделәр[3].

Бу вакытларда нугайлар белән казанлылар арасында яңа бер тиҗарәт, ягъни алыш-биреш, сәүдә ачылып, берберсенә катыша башлаганнар иде. Нугай мирзалары җәй көне күчеп йөргән вакытларда казанлыларга якын килеп аралашалар иде. Ошбу ихтилят, ягъни аралашу, катнашу сәбәпле Казан шәһәрендә булган нугай фиркасе көчәеп китте, болар эш башына килделәр. Шушы нугай фиркасенең мәхәббәтен җәлеп итү өчен, Җан Гали хан нугай мирзаларыннан кыз алып булса да якынлык пәйда кылырга мәҗбүр булды, бу турыда великий кенәз белән киңәш итте һәм рөхсәт сорады. Великий кенәз өчен Казан мөселманнары белән нугай мөселманнарын дуслаштыру вә

катыштыру матлаб, ягъни теләнгән эш булмаса да, Җан Гали ханның Казанда тора алмаслыгын аңлагач, мәҗбүри сурәттә мондый никахка рөхсәт бирде. Шул сәбәпле Җан Гали хан нугай мирзаларының могтәбәрләреннән, ягъни абруйлыларыннан Йосыф мирза бине Муса кызы Сөен Бикәне никахлап алды вә шуңа күрә үзен нугай фиркасе тарафыннан тәэмин иттем дип уйлады, ләкин бу хыялы бушка чыкты[4].

Сөен Бикә гакыллы, тәдбирле, ягъни алдын уйлап эш итүче вә гайрәтле бер хатын булганлыктан, Мәскәү кенәзенең ишарәте буенча хәрәкәт итеп торучы Җан Галинең бу мөгамәләсенә риза булмады, Мәскәү кенәзенә хадим, ягъни хезмәтче сыйфатында торучы бер хан хатыны будан наразый булып, Казандагы сәяси эшләрне үз фикере белән йөртергә икъдам итә, ягъни тырыша, көч куя, башлады. [Сөен Бикә] Казан эчендә булган Кырым фиркасен үз тарафында булган нугай фиркасенә кушып, боларның көчләрен күбәйтте, хәтта Кырым фиркасе белән табын-табанә зыйдд, ягъни килешмәүчән дошман, вә татар фиркасенең иң йогынтылы әгъзаларыннан булган Булат кенәзне дә нугай вә Кырым фиркасенә кушуга иреште.

Сөен Бикә фикеренә муафикъ бу фиркаләр, Казан идарәсен үз кулларына алып, гүзәл бер тәртипкә салырга торган вакытта Мәскәү кенәзе Василий вафат итеп, угылы Иван тәхеткә чыкты. Килешү һәм солыхны яңартыр өчен дип Мәскәүдән адәмнәр килгәч, Җан Гали хан, үзенең куркаклыгыннан вә Сөен Бикә фиркасе теләкләренә каршы буларак, Мәскәү тарафыннан таләп ителгән рәвешләр белән солых вә килешү ясады. Менә шуннан соң Казанда тынычлык тәмам бетте, Сөен Бикә ризалыгы беләнме-түгелме, Булат мирза яшерен сурәттә Кырым вилаятенә адәм җибәреп, Сафа Гәрәй ханны яңадан Казан ханлыгына дәгъвәт итте, ягъни чакырды[5].

Булат мирзаның адәмнәре бер форсат, ягъни җайлы вакытта Җан Гали ханны Казан шәһәренең тышына алып чыгып, Казан елгасының ярында үтерделәр. (Карамзин, Т. 8, 31 б.) «Мөстәфадел-әхбар»ның: «Җан Гали Казаннан тared вә әбгад ителдеге соң, ягъни сөрелгәннән һәм ераклаштырылганнан соң, Мәскәүдә үтерелде»,— дигән сүзнең чыганагы безгә мәгълүм булмады. («Мөстәфадел-әхбар», Т. 1, 132 б.) Бу вакыйга 1535 елның көзендә, сентябрь аенда булды[6].

Ияр һәм өзәңгеләр. XVI гасыр.

Җан Гали ханны үтерү турында Гәүһәршад бикәнең дә катышы булуыннан хәбәр бирүчеләр бардыр.

Җан Гали ханның Казанда булган ханлык вакыты бары 4 кенә ел булып, үтерелгәндә яше 20 дә иде.

Казан мирзаларының беренең кызы булган хатыннан булса кирәк, [Җан Галинең] бер кызы бар иде. Аны Әстерхан кенәзләреннән Кайбула кенәз Аккүбек угылы никахлап алып, гомерен Мәскәүдә кичерүе риваять ителәдер.

ИСКӘРМӘЛӘР (ҖАН ГАЛИ ХАН):

[1] Җан Гали Касыйм шәһәрендә 1516 елда туа. Абыйсы Шаһ Гали Казан тәхетенә менгәннән соң, 1519 елда, 3 яшьлек шаһзадә Касыйм ханлыгының идарәчесе («владетельный государь») дип игълан ителә һәм бу дәрәҗәне абыйсы Казан тәхетеннән сөрелгәннән соң да саклый.

[2] Казандагы дәүләт түнтәреше нәтиҗәсендә вакытлы хөкүмәт хасил була. Аның башында Мөхәммәд Әмин ханның сеңелесе — иске Олуг Мөхәммәд сөлаләсенең (династиясенең) исән калган бердәнбер вәкиле — ханәкә Гәүһәршад (урыс чыганакларында Ковгоршад дип бирелә) тора. Хөкүмәт составына мирза Кече Гали (Кичи Али) һәм Булат Ширин да керәләр. Вакытлы хөкүмәт Мәскәү тага торган Шаһ Гали кандидатурасын кире кагарга карар бирә: бу адәм казанлыларга үзенең шәхси сыйфатлары белән ошамый. Шаһ Галине кире какса да, вакытлы хөкүмәт, телиме-теләмиме, урыс ориентациясендә кала. Ханлык өчен иң кулай кеше дип Мәскәүгә тугрылыклы Җан Гали табыла.

[3] Русия хөкүмәте өчен Казан тәхетендә бу ике агай-эненең кайсы утыруы мөһим булмый: ханлык башында бары тик Мәскәүгә бирелгән адәм генә булсын. Җан Гали тәхеткә 1531 елның 29 июнендә күтәрелә. Хан белән берлектә Русиядән Казанга ханлыктагы фетнәне оештыручылардан Табай (Тагай) һәм Тәвәккәл (Тәукил) мирзалар, Ибраһим бакшы, шулай ук урыс илчесе Я. Морозов киләләр.

Унбиш яшьлек хан дәүләт белән исем өчен генә идарә итә. Бу вакыт хакимият регентша сыйфатында башында Гәүһәршад ханәкә торган хөкүмәт кулында була. Мәскәү үзенең грамоталарын яшь ханга гына түгел, аның белән беррәттән ханәкә һәм мирзаларга да юллый. Казан хөкүмәте дә Мәскәүгә ханәкә, мирзалар һәм барлык Казан җире кешеләре исеменнән яза. Гәүһәршад исеменнән башка грамоталарда хөкүмәт әгъзалары буларак түнтәрешне оештыручылардан Булат Ширин һәм Табай мирзалар да телгә алына. Яңа хөкүмәт Мәскәү белән тыгыз элемтә тота, аңа муафикъ сәясәт үткәрә, әмма ил эчендә абруй казана алмый, гел халык кузгалышыннан, фетнәдән куркып яши.

[4] 1533 елның июнендә Аппак углан, Кадыш кенәз, Евтек бакшы (Җәүдәт?), Касыйм кенәзе Котлыг Булат составындагы илчелек Мәскәүгә Җан Гали ханның нугай ханәкәсенә өйләнү мәсьәләсе һ. б. «зур эшләр» буенча бара. Урыс елъязмасының хәбәренә күрә, «Казан җирендә иминлек булуы хакына» Мәскәүдә никахка рөхсәт бирелә. Бу абруйлы илчелекнең Мәскәүгә

баруы, мөгаен, никах мәсьәләсен хәл итү белән генә чикләнмәгән. Өйләнгәннән соң унҗиде яшьлек хан, регентша йогынтысыннан чыгып, мөстәкыйль идарәчегә әверелергә тиеш булган. Шунлыктан ике хөкүмәт арасындагы мөнәсәбәтләр яңа шәкелдә хәл ителү ихтыяҗы килеп туган.

Чыганаклар Җан Гали белән Сөен Бикә арасында аңлашу да, мәхәббәт тә булмавына ишарә итәләр.

[5] Василий III нең үлүе Мәскәү-Казан мөнәсәбәтләрендә шактый үзгәрешләр китереп чыгара. Елена Глинская хөкүмәте чит илләр белән булган сәясәтендә элекке идарәченең кырыс һәм экспансив курсын кабатлый алмый. Казан хөкүмәте, тезгеннең бушый төшкәнен күреп, мөстәкыйль политикага йөз тота башлый. Урыс илчелегенең абруе шактый төшә, көнчыгыш партиясенең йогынтысы үсә, нугайлар белән актив сәүдә итүчеләрнең «базары» нык күтәрелә. Гәүһәршад хөкүмәте бу үзгәрешләрдән файдаланып калырга омтыла һәм урыс басымчылыгыннан гарык булган татар җәмгыятенең хөррият омтылышларына йөз белән борыла. Казан сәясәтендәге кискен борылыш сарай түнтәреше белән тәмамлана. Урысларга каршы погром булмый, ләкин урыска буйсынуны гәүдәләндергән Җан Галинең җаны кыела. Шаһ Галине чакыру тарафдарлары Мәскәүгә кача. Бушаган тәхеткә яңадан Сафа Гәрәй чакырыла.

[6] Җан Гали 1535 елның 25 сентябрендә үтерелә. Ләкин бу үтерүнең тәфсиле, шартлары, урыны турында чыганаклар бик каршылыклы мәгълүматлар бирәләр.

ШАҺ ГАЛИ ХАН

(1505—1567 елда вафат)

Шаһ Гали хан Касыйм шәһәрендә хан исемен алып торган Аллаяр ханның угылы вә Казанда 4 ел микъдары хөкүмәт сөргән Җан Гали ханның тумасы иде[1]. Бу зат Мәскәү хөкүмәтенең ярдәме белән Казан шәһәренә кереп, өч мәртәбә хан булса да, һичберсендә карар таба алмады, ягъни рәтләп хакимлек итә алмады.

Беренче мәртәбәсе. Мөхәммәд Әмин хан вафат булганнан соң. Мөхәммәд Әмин хан вафат булган вакытта үзенең ана ягыннан бер тумасы Сәхиб Гәрәйне хан кылырга васыять иткән хәлдә великий кенәз Василий Касыйм шәһәрендә торган ошбу шаһзадә — Шаһ Гали бине Аллаярны хан куярга иҗтиһад итте, ягъни тырышты вә ахырда үзенең мәэмүрләре, ягъни башкаручылары белән Шаһ Галине Казанга җибәреп тәхеткә утырттырды һәм халыктан бигать алды. Бу вакыйга 1518 елда булды[2].

Әмма Кырым ханы Мөхәммәд Гәрәй ярдәме белән Казан тәхетен Сәхиб Гәрәй алып, хөкүмәт сөрергә керешүе белән Шаһ Гали хан мәҗбүри сурәттә Казанны ташлап Мәскәүгә китте. Бу вакыйга 1521 елда булмыштыр[3]. Шулай итеп, Шаһ Галинең бу мәртәбәсендә Казанда хөкемдар булып торуы 4 ел микъдары вакыт булды. Сәхиб Гәрәй хан Шаһ Галине кулга алгач, азат итеп җибәрүе хакында югарыда язылган иде[4]. (Дусларыбыздан бер зат: «Казан өстенә килгән бу күпме бәла вә казаның килүенә сәбәпче шушы Шаһ Гали булган, дип фикер кылам. Әгәр дә Сәхиб Гәрәй вакыйгасында азат ителәсе урынга үтерелгән булса, бәлки Казан эшләре икенче бер хәлгә кергән булыр иде», — диде.)

1530 елда Казаннан Мәскәүгә барган илчеләр Тагай, Тәүкил (Тәвәккәл), Ибраһим һәм башкалар соравына күрә, Мәскәү кенәзлеге Казан мәмләкәтенә Шаһ Гали ханны яңадан куярга карар биргән иде. Фәкать бу вакыт Казан халкы элекке мәртәбәсендә [Шаһ Гали] ханның Казанга килеп тә үзенең газел ителүенә, ягъни төшерелүенә сәбәп булган кешеләрдән үч алуы, җәбер вә золым кылуы бар, дип курыкты һәм шул сәбәпле Шаһ Галинең бер тумасы Җан Галинең хан итеп җибәрелүен сорады. Шуңа күрә, табигый, Җан Гали хан Казан ханы итеп куелды, ә Шаһ Гали тәхеттән мәхрүм торып калды[5].

Шаһ Гали Казан ханы булыр өчен бөтен тырышлыгын сарыф итеп йөреп тә, теләгенә ирешә алмавыннан гаять мәэюсь вә мөкәддәр, ягъни кайгылы, хәсрәтле булды. Мәскәү кенәзеннән яшерен рәвештә Казан ханлыгын алыр өчен Әстерхан вә Нугай ханнарыннан ярдәм сорап хатлар язды. Ләкин моның бу хәлләрен великий кенәз сизде вә, Белоозерга җибәреп, хатыны белән берлектә төрмәгә утыртты[6].

Җан Гали хан Казан шәһәрендә үтерелгән вакытта, бәлки моннан күп еллар элек, Нугай вә Кырым фиркасе һәм дә Казан татарлары фиркасеннән Булат кенәз вә аның иярченнәре тарафыннан Кырым вилаятендә булган Сафа Гәрәй хан Казан ханлыгы өчен чакырылган иде. Әмма Казан фиркасенең калган өлеше, бигрәк тә Мәскәү тарафын куәтләгәннәр, тегеләргә каршы хәрәкәт иткәнлектән, Мәскәү кенәзеннән Казан ханлыгы өчен Шаһ Галине чакыралар иде. Бу каршылыкның асыл мәншае, ягъни төп чыганагы һәрвакыт Мәскәү дәүләте үзе булып килмештер. Мәскәү, гаскәреннән дә бигрәк, игъвасы, ягъни котыртуы сәбәбеннән Казан халкы арасына ихтиляф, ягъни капма-каршылык салып, үз теләгенә җитмештер.

Мәскәү тарафында булган татарлар Идел белән Мәскәүгә бардылар һәм дә: «Безнең артыбызда мирзаларыбыз, кенәзләребез, казакларыбыздан 60 лап адәмебез бар, без 500 адәмнең карары белән килдек, без великий кенәзгә ихласлы бәндәләрбез, аның хезмәтен итәргә һәрвакыт әзербез»,— дип тугрылыкларын белдерделәр вә, Җан Гали ханның үтерелүен сөйләп, аның урынына Шаһ Гали ханның Казан ханлыгына җибәрелүен үтенделәр. Ибраһим хан кызы Гәүһәршад бикәнең дә бу фиркагә нисбәте барлыгын бәян иттеләр[7].

Мәскәү хөкүмәте моны белгәч, Белоозерда мәхбүс, ягъни тоткын булган Шаһ Галигә адәмнәр җибәреп, шул

елның декабрендә Шаһ Галине Мәскәүгә китертте[8]. Великий кенәз Иван хозурында Шаһ Гали, үзенең гаепләрен игърар итеп, ягъни танып, тезләнеп гафу үтенде. (Шаһ Гали хан гозерләренең сурәтен Соловьев җентекләп язмыштыр. Т. 6, 24 б.) Тумасы Җан Гали вафаты өчен тәәссеф изһар итеп, ягъни көенечен белдереп: «Мәскәүгә хезмәт итү юлында җанын фида итте, мондый фазыйләт, ягъни күркәм эш безгә дә булса иде!» — диде. Великий кенәз тарафыннан (чөнки бу вакыт үзе сабый иде) кенәз Карпов: «Әй хан! Үткән эшләрне сөйләмәгез, сезне кенәз гафу итте, инде моннан соң раст хезмәт кылырга тырышыгыз!» — дип җавап бирде.

Великий кенәз сараенда Шаһ Гали хөрмәтенә бөек зыяфәт бирелеп, ягъни зур хөрмәт күрсәтелеп, Шаһ Гали хатыны Фатыйма Солтан да ошбу мәҗлестә иде. Великий кенәзнең анасы Елена ФатыймаСолтанга бөек әкрәмнәр, ягъни бик зур илтифатлар, хөрмәтләр күрсәтте. Ләкин бу вакыт Сафа Гәрәй Кырымнан килеп җитеп, Казан тәхетен үз кулына алды. Шуның өчен Шаһ Гали хан ханлык нигъмәтеннән мәхрүм калды[9].

Икенче мәртәбәсе. Сафа Гәрәй хан икенче мәртәбә ханлыгыннан төшкәннән соң Иван Грозный, Дмитрий Бельский вә Палецкий исемле кешеләр белән Шаһ Галине җибәреп, Казан тәхетенә утыртты. Бу көнне Казан шәһәрен гадәттән тыш зиннәтләп, бөек бәйрәм иттеләр[10].

Шаһ Гали хан хөкемдар булып тора башлаганнан соң һәрбер эшендә Мәскәү тарафын тотар вә Казан файдасына күп илтифат итмәс иде. Казан халыклары моның мондый мөгамәләсеннән риза булмадылар, үзләрен алданган дип хис иттеләр. Ахырда һәрбер эшне берәмберәм үз кулларына алдылар. Шаһ Гали ялгыз, ягъни бары тик ханлык исемен генә күтәреп торыр булды. Тарафдарларыннан кайберләрен кудылар, кайберләрен үтерделәр, беркадәрен төрмәгә утырттылар. Шаһ Гали [үз] сараенда мәхбүс, ягъни тоткын хөкемендә буларак калды[11].

Мәшһүр түрәләрдән Чура мирза Шаһ Галине никадәр мәдех итеп, ягъни мактап, «аңа ихласлы һәм итагатьле булырга тиешле», дип Казан халкына нәсихәтләр әйтеп йөрсә дә, сүзе тәэсир итмәде, [халыкның], Сафа Гәрәй булмаганда, Казан мәмләкәтенең үз кулларында тормаячагында шөбһәсе калмады. Шуның өчен Сафа Гәрәй ханны яңадан ханлык итәргә чакырдылар.

Татар яугире. С. Герберштейн буенча.

Бу хәлләрдән хәбәрдар булган Чура мирза, Шаһ Гали хозурына кереп, форсат кичмәстән мөкаддәм, ягъни җай бетмәстән элек ничек булса да качарга кирәк, юкса эшләрнең харап булачагын аңлатты. Шаһ Гали гаед кичендә (Соловьевның әйтүе буенча, бу вакыйга 1546 елда була) Казаннан качып чыкты вә, көймәгә утырып, Волга белән Мәскәү шәһәренә китте. Шаһ Гали ханның бу икенче мәртәбәдә булган ханлыгы бары тик бер ай кадәре булмыштыр. («Мөстәфадел-әхбар». Т. 1, 132 б. Соловьев аңлатуларыннан да шулай булганлыгы аңлашыла.)

Өченче мәртәбәсе[12]**.** Үтәмеш Гәрәй хан белән анасы Сөен Бикә әсирләр сыйфатында Мәскәүгә җибәрелгәч, Шаһ Гали хан өченче мәртәбә буларак, 1551 елның 16 августында (К. Фукс әйтүенчә) Казан тәхетенә чыкты[13]. Шушы ук сәгатьтә Казандагы рус әсирләренең азат булуы игълан ителде. (Вятка вә Пермьгә кайтып китүчеләрне исәпкә алмаганда, Карамзин 60 мең рус гаскәре, ягъни сугышчысы азат булды, дип яза. Фәкать бу сүз мөбаләгале, ягъни күпертүле булса кирәк. Бу кадәр әсире булган шәһәрнең халкы аздан бер миллион булырга тиешле.) Электән Казан мәмләкәте булган бөтен Тау ягы Мәскәү кул астына алынды. Сафа Гәрәй ханнан тол калган хатыннарыннан берсен Шаһ Гали никахлап алды.

Казан мәмләкәтенең ярымын хисап иткән Тау ягының Мәскәүгә бирелүеннән Казан халыклары наразый булдылар, ягъни ризасызлык белдерделәр, вә моны Шаһ Гали ханның хыянәтенә сылтадылар, моның тулысынча рус боярлары сүзе белән йөрүен тәхәммел итә, ягъни күтәрә алмадылар.

Казанлылар, Сөен Бикә һәм Кырым фиркаләренең фикеренә каршылык кылып, Кырым кенәз вә мирзаларының һәлакәтләренә сәбәп булуларына көенделәр, ләкин бу вакыт эш үткән иде. Шаһ Гали бөтен Казан мөселманнарының күзеннән төшүеннән вә әманиятен гаиб иттекеннән, ягъни ышаныч-таянычын югалтуыннан мәэюс булып, мәхәббәтләрен җәлеп итү өмете белән великий кенәздән Тау ягының Казан дәүләтенә кире кайтарылуын сорап караса да, бу эш хакында великий кенәз авыз да ачмады. Һәрхәлдә Казанда фетнә һәрҗ вә мәрҗ улды, ягъни Казанның асты-өскә килде. Казанлылар, Шаһ Гали ханнан хәер чыкмаячагын гүзәл аңлау сәбәпле, мәмләкәтләрен сакларга бәлки сәбәп булыр дип, яшерен сурәттә оешып, нугай кенәзләреннән Казан ханлыгы өчен адәм сорап, Йосыф мирзага хәбәр җибәрделәр. Моны Шаһ

Стрельцы XVI столетия

XVI гасыр урыс укчылары (стрелецлар).

Гали хан сизде вә гүя моңа бер чара табу өчен бу эшкә катнашы булган адәмәрне бетерергә карар бирде.

Көннәрнең берендә хан сараенда кунак мәҗлесе тәртип итеп Казандагы могтәбәр затларны дәгъвәт итте, ягъни чакырды, вә электән хәзерләп вә яшереп куйган рус гаскәрләреннән үзенең шикләнгән, шымчылары тарафыннан хәбәр бирелгән кешеләргә һөҗүм иттереп, 70 адәмне суйдырды[14]. Менә бу вакыйга аркасында Казанда зур хәвеф калыкты. Казан могтәбәрләре һәр тарафка кача башладылар, әманиять, ягъни тынычлык тәмам бетте. Урамнарда үтерү максатында һөҗүм итү, сугышу, кыры-

лышу хөкем сөреп, Казан урамнарында тоташтан ике тәүлек вакыт мөселманнар бугазланып, үтерелеп, бөтен шәһәр кассабханә хөкеменә чуерылды, ягъни сую урынына, бойняга әверелде. Халыклар Шаһ Галигә нәфрәт иттеләр, ләгънәтләр укыдылар.

Иван Грозный тарафыннан килгән Адашев исемле илчегә Шаһ Гали: «Казан кенәзләре вә могтәбәрләре мине яратмыйлар, шуның өчен монда хан булып тору миңа мөмкин түгел, әгәр дә Иван мәрхәмәтеннән ташламаслык булса, монда булган һәрбер сугыш кораллларын, дарыларын бозып чыгармын, шуның сәбәпле Казанны бик җиңел алырсыз»,— дип сөйләде. Бу хәбәрне Адашев Мәскәүгә кайтып великий кенәзгә ирештерде. Бу вакыт Мәскәүдә Миргали, Кастров, Галимәрдән (суелган 70 кеше арасында боларның якыннары булмыштыр) исемле мирзалар бар иде. Болар исә великий кенәзгә: «Шаһ Гали хан залим, усал, мәрхәмәтсез, шуның өчен аны урыныннан төшерергә һәм дә аның урынына рус түрәләреннән наместник куярга тиешле. Казан Мәскәүгә табигъ улыр, ягъни буйсыныр, әмма мөселманнар читләргә таралып, карьяләр, ягъни авыллар ясап утырырлар, без, әлбәттә, синең итагатьле бәндәләрең, шуның өчен мәслихәтне сөйләргә мәҗбүрбез!» — дип акыл бирделәр[15].

Великий кенәз Иван Грозный Адашевны яңадан Шаһ Галигә җибәрде. Адашев килеп Шаһ Галигә: «Мәскәү гаскәрләрен Казанга сугышсыз гына кертер булсаң, Иван Грозныйның илтифатына вә ихсаннарына ирешерсең!» — диде. Шаһ Гали хан моңа рәхмәт әйтте һәм дә: «Инде мин ханлыкны теләмим, минем бәхетем юкмы яки идарәм юкмы? Казанда өч мәртәбә хан булсам да, карарлана, ягъни даими урнашып тора алмадым, инде бу көн гомерем дә куркыныч астында, мәмләкәтне түгел, үз-үземне саклардык та көчем юк, Казанда миннән башка адәмнең хан булып торуын да күрәсем килми, Казанны алырсыз!» — диде.

[Шаһ Гали] яшерен сурәттә пушка вә тупларны бозды, дары сандыкларын бикләде дә, Мәскәү кулында булган Зөя шәһәренә җибәрде, шуннан соң сунарга, ягъниауга чыгу сылтавы белән олуг адәмнәрне вә 500 кадәр Мәскәү гаскәрен алып Казаннан чыкты[16]. Моның ишарәсе буенча боларның һәммәсен рус гаскәрләре урап алдылар. Бу хәлгә олуг адәмнәр зияда тәгаҗҗеб иттекләрендә, ягъни гадәттән тыш гаҗәпләнү белдергәч, Шаһ Гали: «Ни өчен гаҗәпләнәсез? Сез миңа риза булмадыгыз, мине үтерергә

теләдегез, минем өстемнән Иванга шикаять иттегез, Иваннан наместник сорадыгыз, менә теләгегез хасил булды, бу көннән башлап Казан рус хөкүмәтенә табигъгыйр, ягъни буйсынадыр»,— диде (бу уңайдан, руслар Казанны Шаһ Гали хан кулыннан алдылар, димәк тулысынча хата түгелдер), вә һәммәсен Зөя крепостена алып киттеләр (1552 ел 6 март). Шаһ Гали ханның бу мәртәбәдә ханлыгы бер елдан азрак булса кирәк.

Казан халыклары Шаһ Гали хан гаиләсен Казан шәһәреннән Зөя крепостена җибәрделәр вә аннан Иван Грозный әмере буенча Шаһ Гали хан Касыйм шәһәренә китте.

Шаһ Гали Казан алынган вакытта, үзенең иярченнәре белән Казан шәһәренә килеп, руслар белән берлектә сугышты вә Казанны берлектә Иванга алышып бирде[17].

Шаһ Гали хан 1535 елдан башлап Ханкирмән, ягъни Касыйм ханы санала иде. Ләкин мондагы ханлык коры бер исемнән генә гыйбарәт булганлыктан, [ул] Казан хөкемдары булырга тырышты, ләкин «күпне өмет иткән, аздан коры калган» дигән кебек, теләгенә ирешә алмады.

Һәрхәлдә үзе хан булып, кәеф вә сафа корып тора алмаса да, Казанда үзеннән башка хан булмавы турындагы теләгәнә иреште. Яше алтмыш бердә вакытта, 1567 елда шәввәлнең 10 нчы көнендә, дүшәмбе көн вафат булып, Касыйм шәһәрендә мәдфүн улмыштыр, ягъни күмелмештер.

Рус гаскәрен татар гаскәрләре тәртибендә үзгәртеп коручы Шаһ Гали хан булды, диләр[18].

ИСКӘРМӘЛӘР (ШАҺ ГАЛИ ХАН):

[1] 1505 елда туган Шаһ Гали — Касыйм удел кенәзлегенең (формаль рәвештә: ханлыгының) хөкемдары Шәех Аллаяр (Әүлияр)ның өлкән улы. Шәех Аллаяр — Сарай ханы Әхмәднең энесе Бәхтияр улы. Мәгълүм булганча, Әхмәд хан заманында Иван III үзенең Алтын Урдадан бәйсезлеген игълан итә. Шаһ Гали ыругы Тимер Котлыг нәселеннән килә. Тимер Котлыг исә үз вакытында Туктамыш хан, ягъни әле генә сүнгән Казан сөяләләсенә нигез салучы белән бик зур дошман була. Бу дошманлык нәтиҗәләре тәхет өчен көрәшүләрнең төп нигезен тәшкил итә.

Касыйм сөяләләсенең Казан тәхетенә менү белән тәгәлләнгән шәҗәрәсе мондый:

Тимер Котлыг

|

Тимер

|

Кече Мөхәммәд

|

Әхмәд — Бәхтияр

|

Шәех Аллаяр (Әүлияр)

| |

Шаһ Гали —— Җан Гали

Әхмәд ханның уллары Сарайда хакимлек иткән соңгы ханнар булалар. 1502 елда Сарай Кырым ханы Миңле Гәрәй тарафыннан җимерелә. Әхмәд ханның уллары һәм туганнары (племянниклары) Русиягә качалар, Мәскәү хөкүмәте аларга, гадәт буенча, волостьлар һәм шәһәрләр бүлеп бирә. 1502 елда Шаһ Галинең атасы Шәех Аллаяр Мәскәү волостындагы Сурожикка ия була, Литва походында катнаша. Аның нугай кенәзе Ибраһимның кызы Шаһи Солтан белән булган никахыннан 1505 елда Шаһ Гали исемле улы дөньяга килә. 1512 елда Шәех Аллаяр Касыйм удел кенәзлегенең хөкемдары («владетельный государь») дип игълан ителә. 1516 елда үлгәннән соң бу урын аның унбер яшьлек улы Шаһ Галигә тәгаен кылына.

Кырым ханнары Сарайдан куылган һәм Русиядә сыеныр урын тапкан Әхмәд хан нәселенә коточкыч нәфрәт саклыйлар. 1516 елда Кырым хөкүмәте Шаһ Галинең Касыйм хөкемдары итеп билгеләнүенә шикаять белдерә һәм Касыйм уделының Сәхиб Гәрәйгә бирелүен дәгъва итә. Ләкин Мәскәү үзенең Алтын Урданы бетерү буенча элеккеге ышанычлы союзнигы Кырымның сүзенә бөтенләй илтифат итми. Инде хәзер Мәскәү хөкүмәте Сәхиб Гәрәйнең Казан тәхетенә дәгъвасын да кире кага һәм бу очракта да Шаһ Гали фигурасын алгы планга куя.

Шаһ Гали тышкы кыяфәтендә шыксыз, җирәнгеч бер бәндә була. Бу мәсьәләдә барлык чыганаклар да уртак фикердә. Мәсәлән, урыс елъязмачысы аны болай тасвирлый: «Оный Шеяль [Шаһ Гали] зело был взору страшного и мерзкого лица и корпуса, имел уши долгие, на плечах висящие, лице женское, толстое и надменное чрево, короткие ноги, ступни долгие, скотское седалище». Сигизмунд Герберштейн Шаһ Галине инглиз догы белән чагыштыра. Урыс елъязмачысы Шаһ Галинең Казан ханы итеп билгеләнүен татарларны мәсхәрә итү өчен махсус эшләнгән булуын шәрехләп үтә: «Такого им, татарам,

нарочно избраша царя в поругание и посмеяние им». Соңыннан тулган ай кебек гүзәл Сөенбикәне шушы җирәнгеч бәндәгә хатын итеп бирү дә бу мыскыллауның бер чагылышы булып тора. Монда ирексездән В. Гюгоның Квазимодосы белән Эсмеральдасы искә төшә.

[2] Русиядә туган һәм урыс мохитендә тәрбияләнгән Шаһ Гали Казан ханы буларак та Мәскәүгә каршы гамәл кыла алмый, билгеле. Шуның өстенә малайның бик яшь булуы (13 яшь) урыс хөкүмәтенә аның белән четрексез идарә итүне гарантияли. Бу фкторлар Шаһ Галине Мәскәү өчен алыштыргысыз кеше итәләр. Казанга үз тарафдарын куя урыс хөкүмәте өчен шулкадәр мөһим була ки, хәтта аны бу җирлектә Кырым белән мөнәсәбәтләрнең кискенләшүе дә туктата алмый.

Казанлылар Мәскәү тәкъдим иткән Шаһ Гали кандидатурасын кабул итәләр. 1519 елның февралендә Мәскәүгә бу турыда хәбәр итү һәм килешү төзү максатында яңа илчелек күндерелә. Казан ханы итеп Шаһ Галине Мәскәүдә игълан итәләр (1 март). Кырымлыларның кискен протесты кабул ителми. Килешү тулысы белән Урыс хөкүмәте мәнфәгатьләрен яклый, Казан ханлыгының төп гамәле нигездә үз җирендә урыс интересларын саклауга кайтып кала. Яраннары, Казан һәм Мәскәү илчеләре белән Казанга килгәннән соң, апрель аенда Шаһ Гали урыс илчеләре катнашында тәхеткә күтәрелә.

[3] Казанда Шаһ Галине бер дә яратмыйлар. Үсмер хан сараенда урысларның басымчылыгы чиктән тыш көчәя. Гамәлдә дәүләт белән урыс илчесе Федор Карпов идарә итә, бөтен җирле эшләргә тыкшынуны ул үзенең төп вазифасы итеп саный. Казанда 1505 елгы сую кабатланмасын өчен дигән сылтау белән кертелгән урыс хәрби отряды тора. Урыска һәм Мәскәүгә сатылган ханга каршы наразыйлык ике ел буена куера. Оппозицияне Сиди (Сәед?) углан җитәкли. Кырым хөкүмәте бу хәлгә теләктәшлек белдерә. Бакчасарайга яшерен илчелек җибәрелә. Ул кырымлылар белән союз төзергә һәм Казан тәхетенә шаһзадә Сәхибны чакырырга тиеш була. Сөйләшүләр уңышлы төгәлләнә һәм 1521 елның язында 300 кешелек отряд белән тәхет варисы Сәхиб Гәрәй юлга чыга. Дәүләт түнтәреше Карпов, воевода Поджогин һәм Шаһ Гали өчен шулкадәр көтмәгәндә була ки, алар хәтта саклану да оештыра алмыйлар. Шаһ Гали яраннары белән Мәскәү ягына чыгып кача.

[4] Сәхиб Гәрәй турындагы мәкаләне карагыз.

[5] 1530 елда Мәскәү хөкүмәтенең Казанга ясаган һөҗүме нигездә уңышсыз бетә. Сугыш юлы белән эш барып чыкмасын белгәч, Василий III дипломатик хәйләләр юлына баса. Казанның кенәз, мирза һ. б. түрәләренең кылларын тартып карау

эшенә керешелә. Тиздән Сафа Гәрәйгә каршы оппозициядә торган олуг кешеләрнең исемнәре ачыклана (Гәүһәршад ханәкә, мирзалар Кече Гали, Булат Ширин, бакшы Ибраһим). Русия хөкүмәте Сафа Гәрәйгә каршы оешкан хәрәкәтне хуплый һәм Сафа Гәрәй бәреп төшергән Шаһ Гали кандидатурасын яңадан күтәреп чыга. 1530 елның 10 декабрендә Шаһ Гали Мәскәүдән Нижний Новгородка чыга һәм, мөмкинлек булу белән үк, Казан тәхетенә күтәрелергә әзер булып тора. 1531 елның маенда заговор ачыла. Сафа Гәрәй урыс илчеләренең җанын кыярга карар бирә, ләкин оппозиция берләшеп бердәм һөҗүмгә күчә һәм Сафа Гәрәйне Казанннан куугa ирешә. Тик Казан вакытлы хөкүмәте үзен төшерүгә сәбәп булучыларны харап итәр, дип, Шаһ Гали кандидатурасын да хуп күрми. Нәтиҗәдә тәхеткә Җан Гали чыга.

[6] Шаһ Гали 1533 елның гыйнварында кулга алына, Кашира һәм Серпухов шәһәрләреннән колак кага, хатыны Фатыйма белән берлектә сак астында традицион сөрген урыны булган Белоозерога озатыла. Моның белән генә чикләнмичә, урыс хөкүмәте Шаһ Галидә хезмәттә торган кешеләрне рәхимсез җәзага тарта. Угланнар, мирзалар, кенәзләр һәм башка шәхесләр, элекке хан кешеләре буларак, хатыннары һәм балалары белән кулга алынып, Тверь, Псков, Новгород, Орешек, Карела төрмәләренә озатылалар. Алар көчләп чукындырылалар, ачка интектереләләр, буып үтереләләр һ. б. Шаһ Гали татарлары процессы буенча барлыгы 200 ләп кеше җәзалап үтерелә. Ләкин бу имәнеч хәлләр, күрәсең, Шаһ Галинең урысларга булган чиксез мәхәббәтен сүрелдерә алмый, ул аларга аннан соң да эт тугрылыгы белән хезмәт итә.

[7] Белоозерога сөрелгән Шаһ Гали тоткынлыкта 3 ел чамасы яши. Ләкин аның язмышы Җан Гали үтерелгәннән соң бик тиз уңай якка үзгәреп китә, чөнки, энесе һәлак булганнан соң, ул Русия тарафын каерган Мәскәү фиркасе өчен бердәнбер тәхет варисы булып кала. Шаһ Галине азат итү турындагы фикерне Мәскәүгә килгән Казан эмигрантлары әйтә. Кырымлыларның Казан тәхетенә булган дәгъваларын кисәр өчен, алар ханлыкка Белоозеро тоткынын чакыралар.

[8] Елена Глинская хөкүмәте бу тәкъдимне хуп күрә һәм, бояр думасы карары белән, Шаһ Гали 1535 елның декабрендә азат ителә.

[9] Шаһ Гали һәм аның хатынын «хөрмәтләгән» арада Мәскәүгә Сафа Гәрәй илчелеге килә һәм урыс хөкүмәте белән килешү төзи. Шаһ Гали яңадан нәүмиз булып кала, ләкин аңа үзенең әүвәлге Касыйм уделы кайтарыла. Казан тәхетен дәгъвалаган чорда ул урысларның Казанга каршы яуларында катнаша: 1537

елда урыс гаскәренең Владимирдагы штабында була, 1540 елда Муром юнәлешендә казанлыларга кашы хәрәкәт итә. 1541 елда ул яңадан Владимирда урыс гаскәрләренең җыелу пунктында була.

[10] Шаһ Гали икенче мәртәбә ханлык тәхетенә 1546 елда чыга. Тәхеткә күтәрелү церемониясе урыс илчеләре күзәтүендә 13 июньдә үткәрелә. Бу вакыйга турында рәсми төстә хәбәр бирү өчен Мәскәүгә Чапкын Отучев мирза җибәрелә.

[11] М. Худяков Шаһ Галинең тоткын хөкемендә тору ихтималын кире кага. Чынлыкта, Мәскәү мәнфәгатьләре өчен генә тырышкан, Казан халкының милли интересларын аяк астына салып таптаган хөкемдарның позициясе нык була алмаган.

[12] «Өченче мәртәбәсе» дигән сүзләр «Шура» журналы текстында төшеп калган.

[13] Шаһ Гали белән бергә ханлык башкаласына чит ил гарнизоны — 300 касыйм татары һәм 200 урыс укчылары кертелә һәм сарайга якын гына йортларда урнаштырыла.

[14] Шаһ Галигә һәм ханлыкның яртысын басып алган урысларга, аларның Казандагы илчесенә каршы оппозиция ныгый. Аның башында Себер кенәзләре Бибарыс Растов һәм аның борадәрләре тора, алар нугайлар белән бәйләнешкә керәләр. Әмма Шаһ Гали хөкүмәтенә заговор мәгълүм була һәм ул, урыс илчелегенең фатихасы белән, фетнә әзерләүчеләрне зур мәкер белән юк итәргә карар бирә. Сарайны алдан ук урыс укчылары уратып алган була, шуңа күрә, эчтәге суюдан котылып, ишек алдына чыга алганнарны урыслар кыра. Заговорны оештыручылардан ике көн эчендә 70 ләп кеше үтерелә, алар арасында бертуган Растовлар — кенәз Бибарыс, мирза Енбарыс һәм мирза Кулай, баһадир Кадыш, Карамыш углан һ. б. була.

[15] Казанга урыс наместнигы кую планы Мәскәүнең күңеленә хуш килә, чөнки Казан ханлыгын сугышсыз гына яулап алырга юл ача.

[16] Шаһ Гали наместник файдасына тәхеттән ваз кичә һәм 1552 елның 6 мартында Казаннан урыс гарнизонын алып чыга һәм аның белән Свияжскига юл тота. Шуннан соң булса кирәк, ул ялган сәбәп (ауга яки балык тотарга чыгу булгандыр) белән Казаннан 84 кенәз һәм мирзаны алып чыга һәм аларны рәһен (заложниклар) сыйфатында урысларга тапшыра.

[17] Казанлыларга каршы берничә походта катнашкан Шаһ Гали бу юлы да Мөдһиш Иванның (Иван Грозный) йөзенә кызыллык китерми. Ул Касыйм гаскәрен җитәкли, камау вакытында Болак артындагы позицияне тота, Казанны алуда урысларның үзләреннән дә артыграк тырышлык күрсәтә.

[18] Шаһ Галинең хәрби оештыру сәләте мәсьәләсендә чыганаклар беркадәр каршылыклы. Бер ише чыганаклар аның чыннан да зур хәрби стратег булуын таныйлар, моны дәлилләү өчен аның бик күп урыс походларында гаскәр башлыкларының берсе сыйфатында катнашуын мисал итеп китерәләр, патшаларның аны гел үзләре белән алуына игътибарны юнәлтәләр. Икенчеләре моңа шик белдерәләр. Мәсәлән, Рим императорының илчесе барон С. Герберштейн аның кыяфәте, физик әзерлеге һәм хәрби сәләте турында болай ди: «Великую ненависть к нему подданных умножали безобразие и слабость его тела, ибо это был человек с выпятившимся вперед животом, с редкою бородою, с лицом почти женским: все это показывало, что он нисколько не способен к войне».

ҮТӘМӘШ ГӘРӘЙ ХАН

(1546—1566 елда вафат)

СӨЕНБИКӘ

(1519—1557 елда вафат)

Сафа Гәрәй хан вафат булгач, аның ике яшендәге сабый угылы Үтәмеш Гәрәй[1] Казан мәмләкәтенә хан игълан ителеп, бигать алынды (1549 ел, март).

Сафа Гәрәй ханның Бүләк Гәрәй исемендә тагын бер угылы булса да, ул Кырым вилаятендә яшәгәнлектән, сабый бала хан итеп куелды. (Кайбер кешеләр ике яшендә булган Үтәмеш Гәрәйнең хан итеп куелуның сәбәбен аңлатып: «Анасы Сөен Бикәне яратканы өчен, Сафа Гәрәй хан [тәхетне] Үтәмешкә васыять иткән иде, шул җәһәттән Сафа Гәрәйнең өлкән угыллары ханлыктан мәхрүм булып, сабый бала хан булды»,— диләр. Сафа Гәрәй вафаты вакытында җиткән бер угылы булып, Казан сугышында шәһид булуы мәгълүмдер. Нугай фиркасе вә Сөен Бикә тырышлыгы белән Үтәмешнең хан булуы хәтергә килер[2].) Анасы исә, Җан Гали ханнан тол калганнан соң, Сафа Гәрәй ханга никах ителгән Нугай урдасы мирзаларыннан Сарайчык шәһәрендә торучы Йосыф мирза ибне Муса мирза кызы иде. (Моны исә Карамзин «Прекрасная Сююнбека» дип тәгъбир итәдер.)

Сөен Бикә Казан ханнары гаиләсендә вә хан сарае эчендә хөсне җәмал, ягъни искиткеч гүзәл, гакыл вә тәдбир белән иң шөһрәтле бер хатын булган кебек, рус тарихларында да мәшһүр бер хатындыр. Үтәмеш Гәрәй хан игълан ителгәч, анасы Сөен Бикә васый, ягъни опекун сыйфаты белән мәмләкәт эшләрен карап торды[3] вә Казан

крепостенда бу көнгә кадәр сәламәт булып та, мөселманнар арасында «хан мәсҗеде» дип шөһрәт алган манараны Сөен Бикә бина иттерде, диләр[4].

Сөен Бикә Сафа Гәрәй хан белән гүзәл тормыш итеп, хан каршында башка хатыннарының барысыннан да игътибарлы вә якыны булмыштыр. Атасы Йосыф мирза да могтәбәр адәмнәрдән булып, Төркия солтаны Сөләйман Кануни үзенә язган хатында [аңа] «бәкләр бәге» (әмирелөмәра) дип мөрәҗәгать итүе риваять ителәдер. (Карамзин. Т. 8, 139 б.) Йосыф мирза элек вакытта Мәскәү белән дус торса да, соңрак Казан эшләре, бигрәк тә кызы Сөен Бикә вә оныгы Үтәмеш Гәрәй сәбәбеннән[5] аралары бозылган иде. Үзе вафат булгач[6], бертуганы Исмәгыйль Нугай кенәзе буларак интихаб ителде, ягъни сайланды. Моңа үпкә белдереп, Йосыф мирзаның Ибраһим мирза, Илмирза исемле угыллары, Урданы ташлап китеп, 1563 елда Мәскәүгә барып Иван Грозный хезмәтенә керделәр[7].

Йосыф мирзаның тумасы Котым мирзаның Хәйдәр мирза вә Гали мирза исемле угыллары һәм ничә йөзләр, бәлки, меңнәр белән саналган иярченнәре (татар вә мөселманнар) болар белән берлектә булдылар. Иван Грозный бу кенәзләргә Ярослав губернасында булган Романов шәһәре белән өязне бирде. Моңа мокабил, ягъни алмашка болар үзләреннән Мәскәүгә 250 татар сугышчысы биреп торырга йөкләмә алдылар. Башлыклары Илмирза 1611 елда вафат булып, Сөеш мирза, Баймирза, Илмирза исемле угыллары калды. Гали мирза вафатыннан соң, Барай мирза исемле угылы калды. XVII гасыр башында Романов өязендә Сөеш мирза Йосыпов белән Барай мирза Котымов сәламәт булырлар иде. Ошбу нугай мирзалары Михаил бине Федор гасырына кадәр Романов өязен идарә итеп тоттылар. Өяздә торган хәлдә, шәһәрдә дә йортлары булыр иде. Мәскәү хөкүмәте көчәеп, татар вә нугай мирзаларына хаҗәт калмаганнан соң, Романов мирзаларының руслар өстеннән баш булып идарә итеп торулары манигъ ителде, ягъни тыелды. Ияреп килгән татарларны 1629 елларда гомумән чукындырып, җирле вә чи руслар белән катнаштырдылар. Шулай итеп, Ярослав губернасында мөселман вә татарларның исеме дә калмады. Бу көндә Романов өязендә булган руслар үзләренең бабалары татарлар вә мөселманнар булганын хыялларына да китермәсләр. Йосыф мирза балалары вә Сөен Бикә кардәшләренең гакыйбәтләре, ягъни азаклары менә шулай булмыштыр... Русиядә Юсупов дигән мәш-

Сөенбикә ханбикә. А. П. Ракштуль (1798—1877) картинасыннан.

һүр фамилия ошбу Йосыф мирза әнсабы, ягъни нәселе булса кирәк.

Үтәмеш Гәрәй хан бишектә ятканлыктан, никадәр гакыллы вә тәдбирле булса да, васыясе, ягъни регентша-опекуншасы хатын булганлыктан, бигрәк тә хан итеп сабый бала билгеләнгәнне ишеткәч, великий кенәз Иван Грозныйның җир вә күге белән шатланып, «инде Казанны алырга форсат килде» дип, хәзерләнә башлавын белгәнлектән, Казан халыклары эш башында моктәдир, ягъни көчле бер ир булуын лязим күрделәр.

Карарларына бинаән, ягъни нигезләнеп, Казан халыклары Кырымда Сафа Гәрәй ханның атасы белән бер тума

булган вә электән Казанда ханлык иткән Сәхиб Гәрәй ханга хат язып, Сафа Гәрй ханның вафат иткәнен, угылы сабый хәлендә калганын, Мәскәү гаскәре һөҗүм итеп торуын бәян итеп, Казан ханлыгы өчен Сафа Гәрәй хан угылы Бүләк Гәрәйнең Казан шәһәренә җибәрелүен илтимас иттеләр, ягъни үтенделәр. (Соловьев ошбу хатны Кырым вилаятенә алып баручы илчеләрнең Мәскәү казаклары тарафыннан тотылганлыкларын, хат алынып, Мәскәүгә великий кенәзгә җибәрелүен бәян итә. Шул хатның икенче бер нөсхәсе икенче бер тарафтан (яки хатның Мәскәү кулына төшүен белгәннән соң) Казан халкы тарафыннан башка юллар белән җибәрелгән булса кирәк. Әмма бу хатның Кырымда булган Сәхиб Гәрәй хан кулына җитүендә шөһбә юктыр.)

Бүләк Гәрәй яшь булу сәбәпле Сәхиб Гәрәй хан Казан ханлыгы өчен үзенең бер тумасы Мөбарәк Гәрәй угылы Дәүләт Гәрәйне мөнасиб, ягъни яраклы күрде. Дәүләт Гәрәй бу вакыт Истанбулда булганлыктан, вакыйганы бәян итеп, Сәхиб Гәрәй хан Истанбулдагы солтан Сөләйман Канунига хат җибәрде һәм Дәүләт Гәрәйнең Казан шәһәренә җибәрелүе лязим икәнен аңлатты. Солтан исә, үзенең пашалары белән киңәш иткәннән соң, Сәхиб Гәрәй ханны төшереп, аның урынына Дәүләт Гәрәйне куярга карар бирде[8]. (Төрек пашаларының сәясәтләренә тәгаҗҗеб итмәк, ягъни гаҗәпләнмәскә мөмкин түгел.) Ошбу сәбәптән бөтен әһел вә әүляде илә, ягъни кешеләре һәм балалары белән Сәхиб Гәрәй хан мәкътүл улды, ягъни үтерелде, Казан хөкүмәте дә хансыз калып[9], русларга ганимәт ителде.

Казанда булган түрәләр, мирза вә кенәзләр Сәхиб Гәрәйгә илче җибәргән кебек, сугышны туктатып тору һәм солых ясау өчен великий кенәз Иван Грозныйга да Үтәмеш Гәрәй исеменнән хан юллаганнар иде. (1549 елның июль аенда. Соловьев, Т. 6, 64 б.). Иван исә моңа каршы: «Мондый олуг булган солых мәсьәләсен хат белән түгел, бәлки илче васитасы илә, ягъни илче аркылы сөйләшәләр»,—дип җавап бирде һәм башсыз калган Казанны тизрәк алу максаты белән гаскәрен җыярга кереште. Мәскәү чирүсе, ягъни гаскәре хәзерләнеп бетү белән Иван Грозный шушы елның 24 ноябрендә Мәскәүдән кузгалып чыкты. Тумасы Юрий белән Шаһ Гали ханны да үзе белән алды. Казаннан качкан түрәләр вә мирзалар һәммәсе Мәскәү гаскәре белән берлектә Казан мөселман-



Иван IV һәм аның рухани атакае поп Сильвестр.

нары белән сугъшырга вә Казанны Мәскәү өчен сугышып алырга киттеләр вә 14 февральдә Казан янына җитеп туктадылар (1550)[10].

Иван Грозный дворяннар вә үзенең хас гаскәре белән Кабан күле ярына, Шаһ Гали белән кенәз Дмитрий Бельский гаскәрләре белән Арча кырына, бер бүлек гаскәрен Казан елгасы артына урнаштырдылар, пушка вә тупларны Болакка куйдылар. Димәк, Казан шәһәрен гаскәр белән урап алдылар вә шул сәгать үк Казан өстенә атарга керештеләр. (Бу сугышта булган Мәскәү гаскәренең 150 меңнән артык булуы мәгълүмдер. Күп кешеләр 200 мең дип исәплиләр.) Великий кенәз Иван Грозный үзе гаскәр эченә кереп, кылычын чыгарып йөрер, халыкларны тәхризъ идәр улмыштыр, ягъни дәртләндереп йөрер иде[11]. Бу Мәскәү тарафыннан Казанның икенче мәртәбә камалуы иде.

Казан ханы бишектә ятар вә Казанның мирзалары берәм-берәм качып, Мәскәү гаскәре тарафына кушылырлар, Иван Грозныйдан илтифат күрер өчен, Казан хәбәрләрен сөйләрләр иде[12].

Мәскәү гаскәреннән 20.000 кеше берләшеп Казан тирәсендә булган агач ныгытмага һөҗүм иттеләр. Фәкать Казанның соң сәгате әле җитмәгән иде, казанлылар гаять зур гайрәт белән каршы тордылар вә көн буенча тоташ сугыштылар[12а]. Бик күп кешеләр әсир төштеләр вә күпләр һәлак булдылар. Кырымның олуг мирзаларыннан Чәлбак мирза белән Сафа Гәрәйнең Сөен Бикәдән башка хатыныннан туган бер угылы бу сугышта шәһид булдылар[13].

Бу вакыт көннәр эсселәнеп китте, яңгырлар ява башлады, кар эреп юллар бозылды, Мәскәү гаскәренең ашарына да бетте. Иван Грозный ирекле-ирексез 25 февральдә кире кайтып китте (1550, сәфәр аенда).

Иван Грозный Казанны тәмам алу фикере белән килеп тә ун көннән соң кире кайтып китәргә мәҗбүр булуына гаять кайгырды вә хәсрәтләнде, шулай булса да, Казан халкының һич хисап ителмәгән рәвештә каршы торуы вә көннәрнең дә кире килүе сәбәбеннән Казан тирәсендә тору хәтәр иде.

Кайтып киткәндә, мөселманнарның куа чыгу ихтималын уйлап[14], гаскәрен гаять ихтиятлы сурәттә, ягъни саклык күрсәтеп тәртип итте. Алга туп вә пушкаларны һәм төп гаскәрне куеп, атлы гаскәр белән үзе арттан

Сөенбикә ханбикә. Рәшит Төхфәтуллин картинасынан.

барды. Юлларны, һәр тирә-якны үз күзе белән карап, берәмләп дикъкать итәр, яңадан килгән чакта ни рәвештә йөрергә кирәк булачагын фикерләр иде.

Зөя елгасының Иделгә койган җиренә җиткәч, түгәрәк рәвештә бер тау күреп, гаять гаҗәпләнде вә, Шаһ Гали ханны да алып, шул тауның башына китте. Казанның Иванга сатылган мирзалары, рус түрәләре дә биредә иделәр. Тауның башыннан Казан күренеп торыр, Нижгород, Вятка, Сенбер тарафлары гаять ачык рәвештә җәелеп ятыр иде. Иван Грозный һәр тарафны озак вакыт тамаша итте вә урынның мәнзарәсенә, ягъни күренешенә хәйран калды вә: «Казанны Алла безгә бирер, без аны алырбыз, менә бу җиргә дә бер шәһәр салырбыз, монда христиан шәһәре булыр»,—диде. Моны исә Шаһ Гали хан белән татар түрәләре бик муафикъ күрделәр, бу җирләр гаять файдалы җирләр булганлыктан, күп байлык китерәчәген бәян иттеләр. Боларның бу дәрәҗәдә вөҗдансыз булып, диннәре вә милләтләре өчен тузан кадәр кайгыртмауларын күргәч, великий кенәзнең Казанны алачагында шөбһәсе калмады вә [ул] шатлык белән Мәскәүгә кайтып китте.

Мәскәү гаскәренең болай Казанны ташлап кайтып китүеннән Сөен Бикә вә Казан халыклары имин булмадылар һәм яңадан киләчәкләренә шөбһә итмәделәр. Шуның өчен солых ясауны мөнасиб күреп, моның өчен Сөен Бикәнең атасы Йосыф мирзаны Казан дәүләтеннән илче итеп Мәскәү шәһәренә юлладылар.

Йосыф мирза, бердән, кызы Сөен Бикә белән нәбирәсе, ягъни оныгы Үтәмеш Гәрәй ханны яклау вә, икенчедән, Казан мәмләкәтен исляһ кылу, ягъни төзәтү теләге белән солых өчен Иван хозурында күп гайрәт итте. Урынсыз җирдә кан агызу Коръән шәриф вә Инҗил хөкемнәре белән тыелган икәнен сөйләде. (Йосыф мирза тол калган кызы Сөен Бикәне Шаһ Гали ханга бирергә риза булачагын да сөйләде.—Карамзин.) Моңа җавап итеп Иван: «Әгәр дә казанлылар үзләренең 4—5 мирзаларын җибәреп, солых сорасалар, бәлки, сөйләшергә мөмкин булыр иде»,—диде. (Бу сүзе бары тик бер сылтау гына икәне мәгълүмдер. Менә шушы вакыйгадан соң, Йосыф мирза Мәскәү белән бозылышып, дошман булмыштыр.)

Иван Грозный, бу турыда үзенең сарай боярлары, поплары, Шаһ Гали һәм дә Казаннан качып киткән мирзалар белән киңәш иткәннән соң, Казан тарафына зур гаскәр җибәрде. Шаһ Гали белән Казан мирзалары бер-

лектә Казан мөселманнары белән сугышыр өчен киттеләр. Иван Грозный боларга Зөя шәһәрен бина итәргә кушты вә, агачтан чиркәү ясатып, шуны сүттереп, Мәскәүдән җибәрде.

Иван Грозный кушуы буенча Касыйм шәһәреннән кенәз Халиков, Вяткадан Бәхтияр Рузин килделәр. Шулай итеп, Казанның һәр тарафыннан юллары бикләнеп, 1551 елның 16 маенда Казан рәсми сурәттә камап алынды.

18 майда иртә белән Казан өстенә кинәттән һөҗүм итеп, меңнән артык сугышчыны вә йөз кадәр түрәләрне үтерделәр, бик күп рус әсирләрен азат иттеләр. Төп гаскәр Волгада көймәләр белән бары тик 24 майда гына килеп җитте.

Зөя шәһәре урынына Мәскәү галәмен, ягъни әләмен, галәмәтен, кададылар. Мәскәүдән китергән агач чиркәүне кордылар, өйләр салдылар. Җиде һәфтә, ягъни атна эчендә Зөя (Свияжск) крепостен тәмам бина кылдылар[15]. Бу хәлләрне күргәч, Казан кул астында торган чуашлар, чирмешләр үз тарафларыннан вәкилләр җибәреп, Мәскәү тәбәгасе, ягъни подданыйлары булырга теләүләрен Шаһ Гали ханга әйттеләр. Шаһ Гали исә боларны үзенең сарай мәэмүрләре, ягъни эш башкаручылары булган Шаһбаз кенәз Шам угылы белән Мәскәүгә Иван хозурына җибәрде. (Карамзин, Т. 8, 20 б. (Х).)

Бу мәмләкәттә булган чуаш, чирмеш вә мордва, гомумән, фин халыкларын татарлар сугышып, үзләренең баһадирлыклары белән кул асларына алсалар да, үзләренә ни тел җәһәтеннән вә ни дин җәһәтеннән һичбер яктан мөнәсәбәт тәхсил иттермәмешләрдер, ягъни кулга төшерергә омтылмадылар. Ошбу сәбәптән татарлар өстенә килгән беренче бәла сәгатендә бу халыклар, алардан аерылып, Мәскәү кул астына керделәр.

Чуаш, чирмеш вә мордваларның вәкилләрен Иван Грозный илтифат белән кабул итте, 3 елга кадәр һәрбер салымнардан азат булачаклары хакында алтын мөһер басып язу бирде. Шуннан башлап Казанның көньяк тарафында булган Җәбәлстан [Тау ягы] Мәскәү милке хисап ителде. Никадәр җир вә никадәр халык бер мылтык атмыйча Мәскәү кенәзенә табигъ улды, ягъни буйсынды.

Иван, боларның ихласларының мәртәбәсен белер өчен, Казан татарлары белән сугышырга кушты. Болар да билгаен вәррәэс, ягъни «баш өсте» дип, кабул иттеләр, татарлар белән сугышып, вәгъдәләренең рас икәнен исбат иттеләр. Җәй буена чуашлар, мордвалар

вә чирмешләр Мәскәүгә йөрүдән туктамадылар. Иван Грозный аларга медальләр вә һәдияләр, ягъни бүләкләр таратып торды[16], шулай ук Шаһ Галигә дә күп илтифатлар итте. Шаһ Галинең хезмәтләре әрәм булмады, морадына җитте.

Казан халкы бу вакыт тәмам михнәт астында калды. Араларында фетнә вә мәшәкать, нифак, ягъни күз буяучылык вә хыянәт күбәйде. Тыштан юллар эзләнмеш, эчтә булган гаскәрнең бөтенесе нибары 20 мең микъдарында калмыш иде. Мирзалар, кенәзләр яшерен сурәттә Шаһ Гали белән хәбәрләшеп торырлар, хан исә бишектә бернәрсәдән хәбәрсез ятыр, Сөен Бикә, бердән, угылы Үтәмеш Гәрәй хан өчен вә, икенчедән, Казан халкының харап булуыннан куркып, тоташ аһ орыр вә һәртөрле чараларга ябышып карар иде. Кырым түрәләреннән Кушак углан халыкны сугышка өндәр вә гайрәтләр күрсәтер иде, әмма аның дошманнары аңа төрле ифтиралар, ягъни ялалар ягалар, хәтта Сөен Бикә белән никах итәчәк вә, Үтәмеш Гәрәйне үтереп, хан булачак, дип сөйлиләр иде. Казан мирзалары Иванга бирелергә теләгән хәлдә, Кырым мирзалары сугышырга өндиләр, Кырым, Нугай вә Әстерханнан ярдәм киләчәген халыкка вәгъдә итәләр иде.

Кырым мирзаларының Казан халкыннан тәмам өметләре өзелгәч, үз араларында сүз беркетеп, Казанны ташлап качып чыктылар. Барысы 300 кеше иделәр, ләкин котылу насыйп булмады. Вятка елгасында рус гаскәре белән очрашып сугыштылар, Кушак углан үзенең кырык бишләп иярчене белән әсир алынды, Мәскәүгә җибәрелеп, һәрбере шунда үтерелделәр.

Кырымлылар киткәннән соң, Казан халыклары Иван Грозныйга илче җибәреп солых сорадылар вә Шаһ Галинең хан булуына ризалык күрсәттеләр[17]. Иван исә Казанны алып, үз мәмләкәтенә кушу никадәр мөмкин икәнен белсә дә, бөтенләй алуны икенче бер мәслихәт вакытка калдырып, солых итәргә ризалык күрсәтте. Чыннан да, Шаһ Галинең хан булуы [Казан] Мәскәү кул астына керде димәк иде. Чөнки Шаһ Гали ханның Казанны үз кулы белән тапшырачагына шик тотмый иде.

Шулай итеп, [Иван Грозный] ошбу шартлар белән солых итәргә риза икәнен Казан илчеләренә бәян итте: 1) Мәскәү тәбәгалеген, ягъни подданствосын кабул иткән чирмешләр, мордва вә чуашлар вә аларның җирләре бөтенләй Мәскәү милкендә калачак. 2) Берсе дә калмый,

Сөенбикә ханбикә. Рәшит Төхфәтуллин рәсеме.

рус әсирләре азат ителәчәкләр. 3) Сөен Бикә вә Үтәмеш Гәрәй хан һәм дә алар тарафында булган Кырым халыклары һәм аларның балалары вә нәселләре һәммәсе әсир сыйфатында Мәскәүгә җибәреләчәкләр.

Казан халыклары ошбу шартларга риза булдылар. Бу солых сәбәбеннән Казан мәмләкәте икегә аерылып, иң гүзәл вә бай җирләре Мәскәү милкенә күчте[18]. Сөен Бикә үзенең вә угылының Казанда ризыклары бетүен белде. Казаннан Зөя кальгәсенә, ягъни крепостена вә аннан Мәскәүгә җибәреләчәкләрен тәмам аңлады. Сәфәргә хәзерләнгәч, зәүҗе, ягъни ире Сафа Гәрәй хан кабере янына барып зиярәт итте, аның белән гүзәл вә мәхәббәт илә тереклек иткәнен һәм аның аркасында нинди рәхәт вә кадер эчендә дөнья кичергәнен фикерләп, күзләреннән яңгыр мисалында яшь түкте. Моны күреп һәм дә үзләренең гыйззәтлү, ягъни кадерле хан хатыны белән ханнарының әсир сыйфатында Мәскәүгә җибәрелүе өчен Казан халыклары гарьләнделәр, кызгандылар, үз-үзләрен манигъ итә, ягъни тыя алмый кычкырып егълаштылар. Сөен Бикә Казанның түрәләренә вә хөкүмәт башында йөрүчеләренә бер сүз әйтмәде. Аллаһы Тәгалә хөкеменә риза булуын белдерде. Моннан соң хәзерләнгән зиннәтле арбага утырып, Казан елгасына барды[19].

Аны алып китәчәк көймә хәзерләнеп тора иде. Угылы Үтәмеш Гәрәй белән көймәгә керделәр, кырымлыларның гаилә вә балалары һәммәсе шунда тулган иде. Кайгысыннан, күп егълавыннан Сөен Бикәнең йөзе сап-сары булмыш вә күзләре эчкә батып калмыш иде. Бөтен Казан халкы диярлек, бигрәк тә хатын вә кызлар ошбу хатын падишаһ белән угылын озатырга төштеләр. Көймә китәргә хәзерләнеп җиткәч, Сөен Бикә Казан халыкларына ишарәт белән видагъ итте, ягъни саубуллашты. Моны күргәч бөтен халык берьюлы тезләнде вә бер тавыш белән егъларга кереште. Тәмам кыямәт галәмәте булды. Кенәз Оболенский Иделдә көймәсе белән көтеп торадыр иде. Сөен Бикәне, Үтәмеш Гәрәй вә барлык иптәшләрен көймәсенә йөкләп, Мәскәүгә алып китте[20]. Мәскәүгә 5 сентябрьдә барып керделәр. Бу вакыйга 1551 елда булганлыктан, Үтәмеш Гәрәй ханның хөкемдарлыгы 2 елдан бераз артыграк булыр.

Үтәмеш Гәрәйне сабый хәлдә Мәскәүдә чукындырып, Александр исеме бирделәр вә Иван Грозный сараена алып тәрбия иттеләр[21]. Казан сәфәренә барган вакытта Иван Грозный Касыйм шәһәреннән Шаһ Гали ханны

Сөенбикә 1551 елда Мәскәүгә озатылыр алдыннан ире Сафа Гәрәй хан кабере янында. Рушан Шәмсетдинов рәсеме.

китертеп, Сөен Бикәне аңа бирде. Сөен Бикәнең атасы Йосыф мирза Мәскәүгә адәм җибәреп, Сөен Бикә илә угылы Үтәмеш Гәрәйнең каттый сурәттә үзенә кайтарылып бирелүен таләп итсә дә, Иван: «Ул Сөен Бикә Шаһ Галигә үзе теләп барды»,— дип җавап кайтарды, ни Сөен Бикәне вә ни Үтәмеш Гәрәйне бирмәде[22]. (Карамзин, Т. 8, 25 б. (Х).) Фәкать Сөен Бикә Шаһ Галигә мәҗбүри сурәттә барганлыктан, яратмады вә хөсне мәгашәрәтләре, ягъни матур аралашулары да булмады, бәлки ире Сафа Гәрәй, бигрәк тә угылы Үтәмеш Гәрәй хәсрәте белән янып-көеп вафат булды, диләр[23]. Ул 38 яшьләрендә, 1557 елда вафат булмыштыр.

ИСКӘРМӘЛӘР (ҮТӘМЕШ ГӘРӘЙ ҺӘМ СӨЕНБИКӘ):

[1] Үтәмеш Гәрәй 1546 елда туган.

[2] Сафа Гәрәй вафатыннан соң көн тәртибенә тәхет варисы мәсьәләсе килеп баса. Мәрхүм ханның, кайбер чыганаклар буенча, биш хатыны була. Аларның берсе нугай мирзасы Шәех Мамай кызы, икенчесе Җан Галидән тол калган Сөенбикә, калганнары Себер, Әстерхан, Кырым ханәкәләре. Ләкин берсенең ниндидер «шанлы кенәзнең кызы» — урыс әсирәсе булуы турында да сүз бар. Төрле хатыннарыннан өч өлкән (балигъ), бер сабый улы (Үтәмеш Гәрәй) булуы мәгълүм. Ике балигъ шаһзадә, Мөбәрәк Гәрәй һәм Бүләк Гәрәй, Кырымда Сәхиб Гәрәй хан сараенда яшиләр. Тагын берсе — урыс әсирәсенең улы — хан тәхетен дәгъвалау хокукыннан мәхрүм була. Иң кечесе Үтәмеш Гәрәй, Сөенбикәнең улы, бишектән төшеп килүче сабый гына әле. XVIII йөз Кырым тарихчысы Сәед-Мөхәммәд Ризаның язуына күрә, Сафа Гәрәй вафатыннан соң, казанлылар, Кырымга кеше җибәреп, Казан тәхетенә Сафа Гәрәй улы Бүләк Гәрәйне сорыйлар. Ләкин Сәхиб Гәрәй, шаһзадәнең Казан ханы булуын теләмичә, аны зинданга сала. Сәхиб Гәрәйнең планы буенча, Казан тәхетенә Истанбулда яшәүче шаһзадә, ягъни Мөбәрәк Гәрәйнең улы һәм Миңле Гәрәйнең оныгы Дәүләт Гәрәй утырырга тиеш була. Сәхиб Гәрәй Дәүләт Гәрәйдән курка һәм аны Казанга барышлый Кырымда харап итәргә карар бирә, имеш. Төрек солтаны исә Дәүләт Гәрәйне, Казан ханы итәсе урынына, Кырым ханы итеп билгели. Төрмәдән котылган Бүләк Гәрәй үч алу йөзеннән абзасы Сәхиб Гәрәйне үз кулы белән буып үтерә. Болар инде, дөрес булса, 1551 елда булган вакыйгалар. Әмма ничек кенә булмасын, Бүләк Гәрәйгә Казанга килеп, атасы тәхетенә утырырга насыйп булмый. Хан

итеп, анасы Сөенбикә регентлыгында, сабый Үтәмеш Гәрәй игълан ителә.

[3] Казан хөкүмәте Кырым татарларыннан оеша. Аның башында Сафа Гәрәй хан заманында хан гвардиясен тәшкил иткән Кырым гарнизоны җитәкчесе Кучак углан (Кощак) тора. Хөкүмәт, дәүләткә янаган куркыныч шартларында, тулаем дип әйтерлек хәрби характерда була һәм коралллы көчкә таянып эш итә.

[4] Сөенбикә манарасының («Хан мәчете») XVI йөз ядкяре булуын бик күп тарихчылар раслый. Алар арасында байтак урыс галимнәре дә бар.

[5] Сүз боларның 1551 елда әсир ителүе, Үтәмеш Гәрәйнең чукындырылуы турында бара. Алдагы текст моны тулысынча ачыклый.

[6] Сөенбикәнең атасы Йосыфны үз энесе, Мәскәү хөкүмәтенә баштан-аяк сатылган Исмәгыйль мирза 1555 елда үтерә.

[7] Башка чыганаклар күрсәткәнчә, бу шаһзадәләрне Исмәгыйль мирза Русия хөкүмәтенә рәһен (әманәт-заложниклар) сыйфатында озата.

[8] Тәхет варисы хакындагы мәсьәләнең драматик тәфсиленә һәм үзенчәлекләренә Искәрмәләрнең 2 нче пунктында тукталынды. Р. Фәхретдин версиясе белән башка чыганаклардагы хәбәрләр арасында җитди генә аермалыклар бар.

[9] Хансыз калуны Үтәмеш Гәрәйнең сабыйлыгы аркасында дип кабул итәргә кирәк.

[10] Башка чыганаклар Казанга җитүне һәм шәһәрне камауны 12 февраль белән билгелиләр. Бу урыс походында Мәскәү ягыннан Шаһ Галидән башка ике елдан соң үзе Казан ханы булачак Әстерхан шаһзадәсе Ядкәр дә катнаша. Ул бу вакытта урыс хезмәтендә була.

[11] Мәскәү хөкүмәте, 1549 елдагы кебек үк, бу походка да яшь патшаның үзен тарта. Боярлар аның шәхси катнашуында гаскәрнең рухын күтәрүче бер фактор күрәләр.

[12] Казан мирзаларының сатылу масштаблары хәйран калырлык. Алар үз халкына, иленә генә хыянәт итеп калмыйлар, бәлки күбесе, Мәскәү ягына чыгып, ватаннарына каршы корал да күтәрәләр. Мәсәлән, Үтәмеш Гәрәй хан булгач, Казаннан Мәскәү хезмәтенә керү өчен ун меңләп кеше качып китә (З. Вәлиди).

[12a] З. Вәлиди язуына караганда, «Ошбу куркынычлы вакытларда Казанның гайрәтле, акыллы мәликәсе Сөенбикә, крепость өстенә менеп, үзе командалар биреп йөри».

[13] Сүз Сафа Гәрәйнең урыс әсирәсеннән туган улы турында бара булса кирәк.

[14] Казанлылар, Мәскәү гаскәре бик күп, Кырым гвардиясе бик кечкенә булу сәбәпле, дошманны эзәрлекли алмыйлар, гомумән, көчләре һөҗүм итәргә түгел, стена артында сакланырга да чак-чак кына җитә.

[15] Урыс явы Зөя тамагындагы Түгәрәк тауны 17 майда биләп ала. Казан ягына җибәрелгән разведка урысларга бернинди дә куркыныч янамавы турында хәбәр итә: ханлык башкаласында хәрби хәзерлек турында әле берни дә белмиләр. Урыс гаскәре янында Казан эмигрантлары — кенәзләр Кастров, Чапкын Отучев, Борнаш, барлыгы 500 ләп кеше, шулай ук тәхет варисы Шаһ Гали булалар. 24 майда Зөя тамагында, ягъни Казан ханлыгының эчендә урыс крепосте баш калкыта. Казанны басып алу сәясәте яңа фасылга керә.

[16] Митрополит Макарий җитәкләгән Мәскәү хөкүмәте чирмеш һәм чуашларны сатып алу өчен байлыгын кызганмый. Зөя воеводалары аларның төркемләп Мәскәүгә баруларын һәм патша сараенда бил бөгүләрен оештыра. «Патша Китабы»нда («Царственная Книга») мондый юлларны укырга мөмкин: «А государь их жаловал великим жалованьем, кормил и поил у себя за столом. Князей и мурз и сотных казаков жаловал шубами с бархаты с золотом, а иным чуваше и черемисе камчатные и атласные, а молодым однорядки, и чукна, и шубы бельи, а всех государь пожаловал доспехи и коньми и деньгами... а государево жалованье к ним не оскудевает, но паче государь прибавляет многое множество роздаваше, паче же своих воинов жалючи».

[17] Кырым гарнизонының качып китеп һәлак булуыннан соң, Казан тәхетенең тотрыгы бөтенләй какшый. Власть Русия белән солых тарафдарлары кулына күчә. Казанда вакытлы хөкүмәт төзелә, аның башында углан Ходайкул һәм Нургали Ширин тора. Яңа хөкүмәт шунда ук сөйләшүләр башлап җибәрә, Зөя каласына сәед Колшәриф, кенәз Бибарыс Растов җитәкчелегендәге депутация юл ала. Алар тәхеткә Шаһ Галине чакыралар.

[18] Казан ханлыгының икегә аерылып, Тау ягының урыслар кулында беркетелүенә хәтта Шаһ Гали дә ризасызлык белдерә, ул үзен һаман да камил хокуклы хан итеп күрергә тели. Ләкин Мәскәү воеводалары «Ходай биргән җирдән» баш тартуның һич мөмкин булмавын әлеге «урыс балтасы»ның сабына (Шаһ Галигә) тиз төшендерәләр.

[19] Казанның вакытлы хөкүмәте 1551 елның 11 августында урысларга хан Үтәмеш Гәрәйне, ханша Сөенбикәне, Кучак угланның ике баласын, Ак Мөхәммәд угланның улын тапшыра.

[20] Әсирләрне Казаннан Зөягә кенәз Бибарыс Растов һәм хаҗи Гали Мәргән озата бара. Русия хөкүмәте вәкиле кенәз П.

Серебряный аларны Казансуның тамагында каршы ала. 12 августта әсирләр Зөядән Мәскәүгә кенәз Серебряный, кенәз Кастров, хаҗи Гали, бояр балалары һәм укчылар отряды озатуында юл алалар.

[21] Җиде яшьлек бала әнисеннән тартып алынып, 1553 елның 8 гыйнварында Чудово монастыренда чукындырыла һәм христиан рухында тәрбияләнә башлый. Анасыннан аерылган, ватаны, иманы, диненнән яздырылган Үтәмеш-Александр озак яшәми: 20 яше тулар-тулмас, 1566 елның 11 июнендә вафат була. Мәсхәрә һәм хөрмәт бергә катышкан «тантана» белән ул патша фамилиясе әгъзалары белән берлектә кремльнең Архангел соборында күмелә.

[22] Йосыф мирза кызы Сөенбикәне һәм оныгы Үтәмеш Гәрәйне үзенә бирүне ничек кенә сораса һәм хәрәкәтләр кылса да, Мөдһиш Иванның (Иван Грозный) күңелен йомшарта алмый. Шуның аркасында Йосыф мирза белән Иван IV арасы тәмам бозыла.

[23] Сөенбикәнең кайда һәм ничек үлүе турында версияләр бик каршылыклы, хәтта кайда күмелүе дә мәгълүм түгел. Кайбер чыганакларда әүвәлге ханбикәнең Иван IV котыртуы буенча Шаһ Гали тарафыннан борыны киселүенә һәм үтерелүенә дә ишарәләр бар.

ЯДКӘР ХАН

(1522—?)

1552 елда Шаһ Галинең, Казан хөкүмәтенең пушка вә тупларын бозып, дарыларын да русларга озатып, Казан тәхетен ташлап чыкканын вә Зөя кальгасына, ягъни крепостена барып кергәнен Шаһ Гали ханга багышлап бүлектә язган идек инде[1].

Казан мәмләкәтенә Мәскәү тарафыннан наместник буларак Зөя кальгасы башлыгы Симон Микулинский тәгаен ителгәнгә, бу кеше Казан шәһәренә килде вә халыкка: «Шаһ Гали ханның газел улмакыны, ягъни урыныннан төшерелүен сораган идегез, инде теләгегез кабул булды, великий кенәз аны газел итте. Инде великий кенәзгә буйсыну өчен ант итегез!» — диде[2].

Казан халкы моңа ризалык күрсәтте, фәкать Иваннан мәрхәмәт сорар өчен дип, Зөя кальгасында булган вә Мәскәүгә ихтыярый буйсынуларын белдергән Чапкын мирза белән Бурнаш мирзаның Казанга җибәрелүләрен үтенде. Рус мәэмүрләре, ягъни чиновниклары белән бергә әлеге мирзалар Казан шәһәренә килделәр. Моннан соң тавыш һәм гаугалар басылды, халыклар да Иван Грозныйга ант иттеләр[3]. Хан сараенда Мәскәү наместнигы вә иярченнәре һәм рус гаскәрләре торыр өчен урыннар хәзерләделәр вә, Микулинскийны чакырып, адәм җибәрделәр[4].

Наместник Микулинский Зөя кальгасыннан үзенең адәмнәре белән Казан шәһәренә килде вә Казан халкы истикъбаль, ягъни каршы алу өчен каршы чыкты. Наместникның кирәк-яракларын күтәреп шәһәргә алып керделәр.

«Казан шәһәре вә бөек Казан мәмләкәте бик җиңел рәвештә безнеке булды»,— дип, рус гаскәре шәһәр эченә керергә хәзерләнгән бер дәкыйкадә, ягъни минутта һич-

кемнең күңеленә килмәгән эш булды. Казан шәһәренең капкасы бикләнеп, каршы тора башладылар.

Моның сәбәбе исә менә нәрсәдә иде: Чапкын мирза белән Бурнаш мирза, җәмәгатьләре яннарына кереп, халык белән сөйләшкәннән соң, халыкларга: «Руслардан хәер булачак түгел, алар бөтен Казан халкын кылычтан үткәрәчәкләр!» — дип сөйләделәр һәм дә, иң соңгы сулуга кадәр бөтен халык берләшеп, каршы торырга тиешлеге хакында нәсихәтләр әйттеләр[5]. (Карамзин: «Бу җирдә Казан халыкларының хәбәрләре вә риваятьләре башка төрледер. Ләкин мин рус тарихчыларының риваятен яздым»,— дияр. Әгәр ул казанлылар хәбәрен хашиягә генә булса да, ягъни искәрмә өчен генә булса да язса, фанатизмнан азат бер тарихчы икәнен күрсәткән булыр иде. Ләкин мондый нәрсә иске замандагы рус тарихчылары өчен мөмкин түгел. Алар гыйлемнән бигрәк сәясәткә хезмәт итмешләр вә шуңа күрә күп урында тарихны бәрбад итмешләрдер, ягъни юкка чыгармышлардыр[6]. Тарихчы Соловьев бу җирдә ошбу мирзалар урынына Ислам кенәз белән Кибәк кенәз һәм дә Чура мирза тумасы булган Әликәй мирза исемнәрен атый.)

Микулинский Казанга керергә баргач, Казан капкаларының бикле вә кальга өсте гаскәр белән тулы икәнен күрде. Мәскәү гаскәре хисапсыз күп булса да, великий кенәздән рөхсәт алмау сәбәпле, сугыш башламадылар, бәлки Зөя кальгасына кайтып киттеләр вә Зөядә булган Казан мирзаларын, кенәзләрен һәммәсен кулга алдылар. Вакыйгадан хәбәр бирер өчен бояр Шереметевны Мәскәүгә Иван Грозныйга җибәрделәр. Ул исә 1552 елның 24 мартында ошбу вакыйганы Иван Грозныйга җитештерде[7].

Моннан соң Иван Грозный гаять ачуланып һәм дә Казан сәфәренең нәтиҗәсез булуыннан биззат, ягъни турыдан-туры үзе барырга карар биреп гаскәр җыйды һәм Казанны тәмам Мәскәү кулы астына кертергә карар бирде[8]. Чөнки Казанны алу өчен ошбу вакыт кадәр уңайлы вакыт юк иде: тирә-як падишаһларының җөмләсе, ягъни барчасы Мәскәү кенәзенә тарафчы иделәр. Нугай ханнары Мәскәү белән дус торырлар иде. Әстерхан ханы Ягмурчы хәтта үзе Казанны алдыру турында Иван Грозныйга ярдәм бирер иде. Әстерханның кенәз Кайбула Аккүбек угылы Мәскәүдә торыр вә Иван Грозный аңа Юрьев шәһәрен бирмеш иде. Төркиянең иң гайрәтле вә иң шөһрәтле солтаны Сөләйман Кануни киңәшче муллалары вә пашалары сүзенә карап, казанлыларның җан

бирергә яткан вакытларында төрек солтаныннан эчәр өчен су сораганда шуны бирергә дә тәнәззел итмәде, ягъни кече күңеллелек күрсәтмәде. Су бирмәве генә җитмәде, бәлки иреннәренә канат белән су тидереп торучы Сәхиб Гәрәй ханны, Истанбулдан Дәүләт Гәрәйне җибәреп, шуның арадашлыгы белән үтертте. Сәхиб Гәрәйнең гаебе исә — казанлыларны кызгану вә аларга тарафдарлык итү иде. Хөласа, ягъни җыеп әйткәндә, бөтен җиһан йөзендә Казан мөселманнарын мөдәфәга итүче, ягъни яклаучы булмас иде. Казанлылар әгәр дә чуаш вә чирмешләрдән яхшы сурәттә иганәт, ягъни булышлык сорасалар, әлбәттә, алар ярдәм биргән булырлар иде. Фәкать алар үз диндәшләреннән сорадылар, әмма диндәшләре боларга күз дә салмадылар. Сөләйман Кануни нугай ханнарына: «Казанлыларга ярдәм бирегез! — дип язды, диярләр. Бу хәбәр дөрес булган тәкъдирдә дә, нугайлар Төркия кул астында булмаулары, Сөләйман Канунины тиешле дәрәҗәдә белмәүләре өчен, андый хатларның мәгънәсе булмаячагы мәгълүмдер. Башкаларга боерып торганчы, Казан халкы хан сораганда Дәүләт Гәрәйне Казанга җибәргән булса, вә, ниһаять, казанлылар яклы булган Сәхиб Гәрәй хан өстенә хан җибәреп, Сәхиб Гәрәйнең җанын кыйдырмаган булса, тагын да гүзәл, нугайларга язган хатыннан да сәмәрәле, ягъни нәтиҗәле булган булыр иде[9].

Иван Грозный исә, мөселман ханнарының хәлләрен, табигатьләрен яхшы белгәнлектән, Казан мәмләкәтенең бетүгә йөз тотуы башка ханнар карашында шәм сүнү кадәр дә әһәмияте юк икәнен ганганәсе илә, ягъни традицион рәвештә аңлады, үзенең омтылышын дәвам итте вә, һәр тарафтан гаскәрен әзерләп, Зөя кальгасына җибәрде[10].

Казан халыклары, бер яктан, саклану өчен хәзерләнгән хәлдә, икенче яктан, үзләренә ханлык итәр өчен Нугай улусыннан хан сорап адәм җибәрделәр. Бу вакыт Мәскәүгә буйсынган Тау халыклары (чуаш, чирмеш вә мордвалар) үзләренең Мәскәүгә бирелүләренә үкенеп, килешүләрен, антларын боздылар вә Мәскәү зарарына хәрәкәт итәргә керештеләр. Һәм Казан халыклары тарафына кушылдылар. Зөя кальгасында булган Мәскәү гаскәре эчендә куркынычлы хәстәлек пәйда булды вә шул вакыт Казан шәһәренә ханлык кылыр өчен Нугай улусыннан Ядкәр ханның юлга чыгуы да ишетелде[11]. Ошбу сәбәптән Мәскәү гаскәре арасына курку төште.



Алтын бизәкләр төшерелгән калкан. XVI—XVII гасырлар.

Мәскәү гаскәре Казан шәһәренә юл алган Ядкәр ханны тотар өчен юлларда каравыл торды вә һәр тарафтан саклады, фәкать бу максатларына муафикъ булмады. Чөнки Ядкәр хан үзенең 500 атлы гаскәре белән Мәскәү гаскәренең сафларын ярып, арыслан рәвешендә гайрәт белән үтте вә Казан шәһәренә сәламәт керде. Моны исә Казан халыкларының соравы буенча җиһазлап, җитештереп җибәрүче Сөен Бикәнең атасы Йосыф мирза иде.

Нугайлар, гомумән, руслар белән дус торалар, хәтта ки Мәскәүнең илчесе нугайлар хозурында тора иде, ләкин [хәзер] Йосыф мирза кызы Сөен Бикә белән оныгы Үтәмеш Гәрәй хан сәбәбеннән Мәскәүгә ачулы иде.

Казан халыклары Ядкәрне каршы алдылар вә үзләренә хан күтәреп, бигать бирделәр, турылык һәм ышаныч белән хезмәт итәчәкләренә ант иттеләр[12].

Ядкәр хан Әстерхан шәһәрендә булган Касыйм хан бине Сәед Әхмәд хан бине Кече Мөхәммәд хан иде. (Мөстәфадел-әхбар, Т. 1, 132 б. Карамзин: 1542 елда Әстерхан шаһзадәсе Ядкәр хезмәт итәр өчен Мәскәүгә килгән иде (Т. 8, 83 б.), дип язганнан соң, шушы Казан Ядкәрен сөйләгән җирдә — «Едигер не тот ли самый царевич, который прежде был в Москве?» дияр. Т. 8, 24 б. (Х.) Казан халкының антларына каршы Ядкәр хан да ахыр сулуына кадәр Мәскәү белән сугышу хакында сүз бирде[13].

Мәскәүлеләр һәрбер кирәк нәрсәләрне көймәләргә төяп Волга белән Казанга җибәрделәр. Иван Грозный Касыйм шәһәрендә булган Шаһ Гали ханны үз янына Мәскәүгә чакыртты, күп һәдияләр, ягъни бүләкләр бирде. Шул тирәләрдә булган күп авылларның табышларын да аңа тапшырды, Сафа Гәрәй ханның тол хатыны вә Үтәмеш Гәрәй ханның анасы Сөен Бикәне никахларга рөхсәт итте һәм Шаһ Галинең үзен дә Казан сугышына алып барачагын бәян итте.

Шаһ Галине Казан сугышына алып барудан Иванның максаты: аның хәйлә-мәкерләреннән файдалану иде. Юкса бу хан гаять симез вә моның өстенә дә өркәк вә куркак булганы өчен сугыш мәсьәләсендә файдасы мәэмүл, ягъни ихтимал түгел иде[14]. Гәрчә Шаһ Гали Иван Грозныйга: «Бу вакыт Казан сугышына бару мөнасиб түгел, чөнки Казан урман, агачлык вә зур күлләр белән әйләндереп алынган. Шуның өчен сәфәр йөрү мөшкел, ул җирләрдә күп адәм җыелса, хәстәлекләр була, шуңа күрә кыш көне сәфәр итәргә тиешле», — дисә дә, Иван үзенең максатыннан чигенмәде, гаиләсе белән күрешеп, 16 июньдә Мәскәүдән чыгып китте вә, Коломна шәһәренә килеп, гаскәрен тәртип итте. Бу арада Кырым ханнарының вә Кырым гаскәрләренең бераз хәрәкәте булганлыктан, Коломнада туктап торды. Кырымнан эш чыкмаслыгын белгәч, бөтен гаскәре белән 3 июльдә Коломнадан кузгалып, Казан тарафына йөрде.

Татар түрәләре дә үз татар гаскәрләре белән хәзер булды вә Шаһ Гали хан да көймәләр белән Волгадан китте.

150 мең гаскәре белән Иван Грозный Казан шәһәре янына барып туктады вә электән шул җирләрдә торган гаскәрләре белән кушылды (1552 ел, 19 август)[15].

Иван Грозный кушуы буенча Шаһ Гали үзенең карендәше булган Ядкәр ханга (чөнки Шаһ Гали хан белән Ядкәр хан Сәед Әхмәд хан балаларыннандыр): «Үзеңне Мәскәү кенәзе вә христиан падишаһы белән бер дәрәҗәдә хисап итмә! Инде безне каршы чыгып ал, сиңа һичнәрсә булмас»,— мәгънәсендә бер хат күндерде. Шулай ук Казанда булган түрәләргә дә: «Әгәр дә Иванга каршы котыртучы фетнәчеләрне тотып бирер булсагыз, Иван күләгәсендә вә аңа буйсынып рәхәт гомер сөрерсез, юк җирдә һәлак булмагыз!» — дип икенче бер хат җибәрде.

Иван Грозный кәнди, ягъни үз исеменнән бөтен Казан мәмләкәтендә ислам диненең башлыгы хисап ителгән сәед (шәйхелислам)га (мәшһүр сәедләрдән Колшәриф мулла булса кирәк) да шундый ук эчтәлекле хат җибәрде.

Иван Грозный вә Шаһ Гали хан тарафыннан язылган хатларга җавап буларак, Казан халкы вә Ядкәр хан тарафыннан күндерелгән хатлар 20 августта Иван Грозныйга тапшырылды. Фәкать бу хатларда солых сүзе булмыйча, алар Шаһ Гали ханны зәм итмәктән, ягъни гаепләүдән вә «иң соңгы сулышыбызга кадәр сугышабыз» диюдән гыйбарәт иде[16].

Иван Грозный гаскәре Казан шәһәренә 6 чакрым җирдә Казан шәһәренә карап торыр иде. Идел белән тау арасында Казан шәһәре эчендә булган таш мәсҗедләре, хан сарайлары, биек-биек манаралары белән балкып торыр, ике саф итеп төзелгән имән койма арасына балчык вә таш тутырылган кальгасы күренеп торыр иде.

Мәскәү гаскәре көймәләрдән коралларын вә тупларын чыгарырга вә урнаштырырга кереште исә дә, боларга һичбер тәгъриз итүче, ягъни каршы торучы булмады[17]. Ошбу вакыт Казаннан качып чыгып, Мәскәү гаскәре янына Камай мирза килде вә Казаннан качып чыгуын һәм 200 ләп иптәшләренең казанлылар тарафыннан тотылып калуларын, Ядкәр хан вә мөселманнарның дин башлыклары булган Колшәриф мулла, Нугай кенәзләреннән Зәйниш, Чапкын мирза, Аталык, Ислам, Галикәй бине Нарыйк, Төмәнле Кибәк һәм Дәрвиш Мәскәү гаскәренә каршы торырга вә ихлас белән сугышырга нәсихәт иттеләр, бу җәһәттән солых фикере һичкемдә калмады, кальгада азык күп, корал җитәрлек, Казан гаскәре 30.000 вә нугай гаскәре 2.700 кадәр булып, мирза Япанчы[18]

гаскәр җыяр өчен Арча кальгасына җибәрелде. Япанчы мирза шул җирдә гаскәр төзеп, Мәскәү гаскәренең артыннан һөҗүм итәчәктер, дип Иван Грозныйга сөйләде. (Серне тәмам чишеп бирмештер!). Бу хезмәте өчен Иван Грозный Камай мирзага хөрмәт вә күп илтифатлар итте[19]. Моннан соң [Иван Грозный] гаскәрләрен урнаштырырга керешеп, алдагы фирка, ягъни бүлек гаскәрен Арча кырына, Казан елгасының уң тарафына, икенче фиркане Болак артына, Шаһ Галине каберлек артына куеп, үзе үзенең хас гаскәре белән Хан болынында торды.

23 август, 13 нче шәһри рамазан, ягъни рамазан ае җомга көн иртә белән [урыслар] тәреләрен күтәреп шәһәргә йөрделәр вә, Болак аркылы күпер салып, шул күпер аркылы бер фирка гаскәр Арча кырына үтте. Шәһәр шулкадәр тын булып, һич тавыш юк, манараларда да адәм күренмәс иде. Кальга белән гаскәр арасында 200 колач кадәр җир калгач, кинәт капка ачылып, 15 мең микъдарында булып атлы вә җәяүле гаскәр чыгып, Мәскәү гаскәренә һөҗүм иттеләр. Мәскәү гаскәре бу хәлдән куркып таралырга вә качарга кереште. Фәкать кенәз Шемякин үзенең фиркасе белән килеп җитте, качучы гаскәрләрне туктатты вә җыйды, шул вакыт бояр балаларыннан гыйбарәт булган хас фирка да килеп җитеп, сугыша башладылар. Мәскәү гаскәре артык күбәйгәннән соң, беркадәр әсир биреп, мөселманнар шәһәргә керделәр.

Мәскәү гаскәре, Казан шәһәрен тәмам камап алып, йөрергә вә хәбәрләшергә мөмкинлек калдырмады. Арча белән Острог шәһәрләреннән вә Япанчы мирзадан башка җирдән казанлыларның өмидләре дә юк иде.

Икенче көн гадәттән тыш җил чыкты, киндерәдән корылган чиркәүләрне атып ташлады. Русларның азык төялгән көймәләре мөселманнар тарафыннан батырылды. Гаскәр гаять курыкты, һәлак булабыз, дип фикер иттеләр. Азык булмагач, монда торырга мөмкинлек бетте, дип сөйләр булдылар. Иван, азык вә киемнәр сорап, Зөя кальгасы белән Мәскәүгә адәмнәр җибәрде. Әгәр дә мөхасарә заманы, ягъни камау вакыты тиз бетмәсә, шул җирдә кышларга карар бирде.

25 августта кенәз Шемякин фиркасе Казан елгасы белән Арча кыры арасына барганда, мөселманнар боларга һөҗүм иттеләр вә урыннарыннан кудылар. Шемякин үзе җәрәхәтләнде. Моны күреп, икенче бер фирка рус гаскәре килеп җитте, мөселманнар да шәһәргә керделәр.



Урыс гаскәренең 1552 елның август аенда Казанны камап алуын күрсәтүче карта.

26 август (1552 дә) Мәскәү гаскәре гомуми сурәттә Казан шәһәренә һөҗүм итте. Мөселманнар да боларга каршы чыктылар, кальга өстеннән туп аттылар вә, мәскәүлеләр белән аралашып, кылыч вә сөңгеләр белән сугыштылар. Сугыш көн-төн буенча дәвам итте. Шушы сугышта баһадир Ислам бәк, Сөнчәли баһадир һәм башкалар шәһид булдылар.

27 августта булган сугышта мөселманнардан Карамыш углан исемле мәшһүр адәм әсир төште. Иван Грозный бу заттан Казан хәлләрен сорагач, (Карамыш углан): «Казанлыларда солых фикере юк, җаннарын фида итәргә карар бирмешләр»,—дип җавап бирде.

28 августта мәскәүлеләр Казаннан гаскәр чыгуын көтеп торган вакытта, һич хисап итмәгән җирдә, урман арасыннан бер фирка атлы гаскәр чыгып, Мәскәү гаскәренең йөрәгенә һөҗүм итте вә күп адәмнәрне үтергәннән соң, урман эченә кире кереп китте. Әсир алынган

кешеләрдән сорагач, мәгълүм булуына күрә, әлеге фирка кенәз Япанчы командасындагы гаскәр булмыш, имеш.

29 августта Казан шәһәрен тәмам уратып алдылар. Фәкать моннан соң кенәз Япанчы Мәскәү гаскәренә рәхәтлек бирмәде, бәлки һаман саен һөҗүм итеп торыр, каршысында гаскәр күбәйсә, урман арасына кереп качар иде[20]. Шәһәр эчендә булганнар белән ишарәт итеп сөйләшерләр вә һәрвакыт Казаннан бирелгән ишарәт буенча хәрәкәт итәрләр иде. Шулай итеп, бу кемсә, ягъни кеше Мәскәү гаскәре өчен бөек бер бәла булды, һәрбере Япанчы исеменнән куркып, өркеп тора башладылар. Шуңа күрә Иван Грозный гаскәрен икегә аерып, берсен шәһәргә, икенчесен Япанчыга каршы куйды. Кенәз Япанчыга каршы бер гаскәренең бер фиркасе яшерелеп, бары бер фиркасе күрелде[21]. Кенәз Япанчы фиркасе боларга һөҗүм иткәндә яшеренеп торган фирка артларыннан чыгып юлларын кисте. Ошбу вакыт ике арада олуг сугыш булды. Күп мөселманнар шәһид һәм күпләр әсир булып, кайберләре качып котылдылар. Инде Япанчы гаскәре таралганнан соң, Мәскәү гаскәре көч хасил итте вә һәммәсе шәһәргә каршы тора башлады. Япанчы гаскәреннән алынган әсирләрне шәһәр каршысында баганаларга баглап куйдылар һәм шәһәр эчендә булган кардәшләренә мөрәҗәгать итеп: «Атмагыз, шәһәрне бирегез!» — дип кычкырырга куштылар. Фәкать казанлылар моңа һич илтифат итмәделәр.

Иван ялланып килгән нимсә мөһәндисенә, ягъни немец инженерына[22] дары куеп, кальганы күтәртер өчен Болак ярыннан Аталык белән Түбән капкалары арасына казып барырга дип фәрман бирде, фәкать Камай мирза моңа караганда казанлыларның су юлларын бозу муафикъ булачагын бәян итте. Шуңа күрә Даировы бани[23] дигән урыннан казырга кереште. Ун көн чамасы казыганнан соң, өстә йөргән аяк тавышлары ишетелә башлады. Шуны белгәч, су юлының астына җитүләрендә шикләре калмады вә шул җиргә 11 мичкә дары куйдылар вә ут җибәрделәр.

5 сентябрь[24] (рамазан аеның 26 нчысы, кадер кичәсенә каршы пәнҗешәмбе көн) иртә белән дары күтәрелеп, крепостьне җимерде, һава тузан вә тупрак белән тулды. Мөселманнар чиктән тыш курыктылар вә шашып калдылар, боларның ошбу хәйрәттә, ягъни хәйран булып торган вакытында, җимерелгән урыннан Мәскәү гаскәре шәһәргә керә башлады. Мөселманнар, эшнең хакыйкатен



1552 ел. Казан өчен көрәш.

аңлап, Мәскәү гаскәренә каршы торырга керештеләр һәм дә шәһәрдән чынлыкта куып чыгардылар. Һәр ике тарафтан хисапсыз адәм үлде. Су бетү сәбәпле мөселманнар өметләрен өзә башладылар вә мәга залик, ягъни шуның белән бергә бер минутны да кулдан ычкындырмыйча, кальганы төзәтергә һәм коймаларны әүвәлгечә торгызырга керештеләр. Аз вакыт эчендә әүвәлгедән гүзәл рәвештә төзәтеп куйдылар.

6 сентябрьдә Острог вә Арча шәһәрләренә җибәрелгән гаскәр, бу ике шәһәрне алып, күп маллар, хатын вә кызлар әсир итеп, ун көн эчендә кайтып килде, Казан байларының дачаларын яндырып, һәммәсен һәлак итте. Арчада күбрәк Япанчы кенәзнең әүвәлге сугыштан котылган халыклары тора иде[25]. Моннан соң Мәскәү гаскәренең азыкка ихтыяҗы калмады, чөнки хисапсыз азык төяп кайттылар. Вә икенче яктан Казан халкына ярдәм биреп торучы чирмешләрне тараттылар, балаларын әсир иттеләр. Шулай булса да [мәскәүлеләр] казанлыларның мылтык вә туплары астында һәм дә яңгырлар эчендә торырга мәҗбүр булырлар вә шушы көзге яңгырларны да Казан мөселманнарының сихерләренә хәмел итәләр, ягъни сылтыйлар иде. Гүя мөселманнар һәр көн кояш чыкканда кальга өстенә менеп кычкыралар, яулык вә киемнәре белән рус гаскәренә ишарәт итәләр икән дә, шул сәгать үк җилләр чыгып, болытлар кабарып яңгыр яварга керешә, имеш. Руслар бу хәлгә аптырагач вә яннарында булган тәреләрнең көчләре җитмәгәннән гаҗиз калып, Мәскәүдән падишаһның тәресен китерәләр дә, шуннан соң гына казанлыларның сихерләре батыйль улмыш буладыр, ягъни яраксызга чыгадыр, имеш. (Русларның иң могтәбәр тарихларының мәнбәгъләре, ягъни чыганаклары монахлар тарафыннан язылган нәрсәләрдер, шуның өчен анда моның кебек әйберләргә еш юлыгырга туры килә. Фәкать бу хәбәр Казан сугышына гаскәр башлыгы буларак килгән кенәз Курбский тарафыннан язылган һәм дә үз күзе белән күргәнне бәян итеп теркәгән нәрсәләрнең берседер. Курбский моны күрсә дә, казанлылар башка бер җитди вә нигезле булган нәрсәләрне яшерер өчен русларга шулай итеп күрсәткән булырлар[26]).

Моннан соң, мәскәүлеләр манара рәвешендә 18 аршин, ягъни 12,8 метр, биеклегендә бер нәрсә ясап, тәгәрмәчләр куйдылар вә өстенә туплар урнаштырып, төнлә кальга янына илттеләр вә иртәгәсен шуның өстеннән шәһәрнең эченә ата башладылар. Шуның белән бергә

казанлылар шәһәрнең тышына чыгып сугышырлар, мөнасиб вакытта Мәскәү гаскәренә һөҗүм итеп торырлар иде, үзләре азайган кебек, Мәскәү гаскәрен дә һәр көн йөзләп, меңләп киметәләр иде. Иван һәр көн солых тәкъдим итәр, «балаларыгыз, хатыннарыгыз, малларыгыз вә ханыгыз белән теләгән җиргә чыгып китегез; безгә фәкать шәһәр генә кирәк, чөнки бу шәһәр Болгар җиренә салынмыштыр, ул җир искедән Мәскәү милке булмыштыр»,—дияр иде. (Бу сүзне Карамзин рус тарихчыларыннан күчереп язса да, үзе ышанмый вә: «Болгар җире бу вакытка кадәр Мәскәү милке булганы юк!»—диядер. Ләкин әгәр дә шул сүзне Иван әйтсә, Казанның көн тарафында булган чуашлар, чирмеш һәм мордваларны күздә тотып әйткән булса кирәк. Алар, болгар җире булган хәлдә, русларга буйсыналар иде.) Ләкин казанлылар бу сүзләргә бөтенләй илтифат итмиләр, һаман үзләренең кылыч вә сөңгеләре белән җавап бирәләр иде. Мәскәү гаскәрләре күп булганлыктан, нәүбәт белән хәл җыеп сугышсалар, казанлылар бик аз калганлыктан тоташ сугышырлар иде.

Арча капкасында булган Мәскәү гаскәре сугыштан туктап ашарга утырган вакытта шәһәрдән кинәт 10 мең кадәр мөселман чыкты, боларның башлыклары Карача мирза иде. Шул вакыт ике чирү арасында гаять бөек сугыш булды, һәр ике тарафтан бик күп адәм һәлак булып, русларның мәшһүр гаскәр башлыклары яраланды яисә үтерелде, әгәр дә яңа гаскәр килеп җитмәсә, казанлылар мәскәүлеләрнең тупларын ганимәт итеп алган булырлар иде.

Мәскәү гаскәренең Казан янында тора башлавына биш атна булып, казанлылардан 10 меңнән артык җан хисабын һәлак итсәләр дә, казанлылар һаман да үзләренең гайрәтләренә кимчелек китермәделәр вә һаман да саклануда, сугышуда булдылар. Ошбу сәбәптән Мәскәү гаскәре арасына өмидсезлек тарала башлады. Иван Грозный, бу хәлдән куркып, һич шәфкать вә мәрхәмәт күрсәтмичә сугышырга фәрман бирде.

30 сентябрьдә (шәввәл аеның 20 нчесе, җомга көн) руслар Арча капкасының астын казып, дары куеп күтәрттеләр. Казан халкы бу хәлдән хәйрәттә торган вакытта руслар ошбу Арча капкасында, Аталык вә Төмән капкаларыннан һөҗүм итә башладылар. Моны күргәч, мөселманнар гакылларын җыеп, каршы торырга вә сакланырга керештеләр вә ошбу вакыт бу көнгә кадәр мисалы

күрелмәгән бөек сугыш булды. Руслар тыгызлашып шәһәр эченә керделәр вә урамнарда сугыштылар. Тавыш, гауга, үлем, кырылыш, кыямәт галәмәте булды. Ахырында руслар кире чыгарга вә качарга мәҗбүр булдылар. Казанлылар мәскәүлеләр тарафыннан чокырларга салынган күперләрне яндырдылар, җимерелгән ныгытмаларны төзәттеләр, фәкать Арча капкасында булган Мәскәү фиркасен куарга муафикъ була алмадылар. Вә мәга залик, ягъни шуның белән бергә бу кадәр мәшәкать вә зәхмәтләр белән кальганы яңартуларына руслар тәгаҗҗеб иттеләр, ягъни хәйран булдылар.

СОҢГЫ КӨН

Мәскәү гаскәре Казан кальгасының күп урыннарына дары куйды, урларга, ягъни чокырларга, күперләр салды. Иван Грозный: «Йә үзканыбызны түгәрбез, йә казанлыларның каннарын эчәбез!» — дип игълан иткән иде. Иң соңгы мәртәбә буларак, Камай мирза вә шуның кебек диннәрен дөньяга алмашкан Тау ягы мирзаларыннан кайберләрен шәһәргә җибәреп, шәһәрнең бирелүен таләп итте. Казанлылар исә: «Сугышсыз бер карыш җир бирмәячәкбез, йә үлем, йә носрәт, ягъни җиңү!» — диделәр. Моннан соң Иван Грозный соңгы һөҗүм чараларын күрергә кереште.

30 сентябрьдә дарыларга ут тоташтырып кальганы күтәрттеләр. Бөтен дөнья тупрак, тузан, таш, балчык белән тулды вә, моны күргәч, руслар электән тәртип итеп куйган рәвеш белән шәһәргә керә башладылар. Мөселманнар исә «Алла! Алла!» дип каты кычкырдылар да, күкрәкләрен биреп сугыша башладылар, кальга диварыннан руслар өстенә бүрәнәләр тәгәрәтергә, кайнар сулар коярга керештеләр. Шәһәр эчендә руслар белән мөселманнар шул кадәр сугыштылар ки, тәгъриф итмәк, ягъни аңлату мөмкин булмас. Ошбу вакыт Мәскәү гаскәренә ярдәм өчен яңа гаскәр килде, мөселманнар да эчке кальга вә Хан сараена җыела башладылар. Кальга диварына Мәскәү әләме кадалган иде[27].

Моннан соң Ядкәр хан үзенең янында булган сакчылары вә олуг түрәләре белән шәһәр уртасына килде, Мәскәү гаскәренең сугыш мәйданыннан берәм-берәм китүләрен күрде, Мәскәү гаскәренең йортлар вә кибетләр талау, акча җыю белән мәшгуль булуын белде[28]. Чөнки

рус гаскәре тарихның ошбу көненә кадәр мондый мәмләкәтне, кыйммәтле нәрсәләре вә байлыгы мисалсыз булган бер шәһәрне хәтта төшендә дә күргәне юк иде. Иван Грозный хәтта үзе килеп ялынып караса да, руслар ишетмәделәр, тоз күргән кәҗә мисалында акча һәм җиһаз әйберләреннән аерыла алмадылар. Хәтта үләргә яткан мәҗрухлар, ягъни яралылар, өстерәлеп килеп, беркадәр булса да алтын, көмеш, ефәк вә асылташлар алу иҗтиһадында улдылар, ягъни алырга тырыштылар. Моны күргәч, мөселманнар болар өстенә бер кешедәй һөҗүм иттеләр вә һәр тарафтан сөреп шәһәрдән чыгара башладылар. Иван Грозный моны күргәч, харап булачагын белде вә тизлек белән поплар, монахлар белән берлектә, тәреләр күтәреп, шәһәрдән чыгучы русларга каршы тордылар, сугышырга гаять димләделәр. Поплар бу сүзләрне тыңламаган адәмнәрнең диннән чыкканлыкларын игълан иттеләр вә, шул арада 20 мең кадәр гаскәр китереп, Хан капкасыннан боларга каршы куйдылар. Шулай итеп, руслар кире сугышырга мәҗбүр булдылар. Табигый, бер учтан гыйбарәт вә ничә һәфтәләрдән, ягъни атналардан бирле тоташ эш вә хезмәт өстендә булган мөселманнар үзләреннән ничә өлеш күп вә һәр көн яңарып торган гаскәргә каршылык күрсәтүдән гаҗиз калдылар һәм, бу хәлне белгәч, гаскәр тәртибен бозмыйча, таш Җәмигъ шәриф үзренә йөрделәр, ягъни баш мәчет янына килделәр. Галимнәр, шәехләр, сәедләр, муллалар әлеге җәмигъ эченә кереп тулмышлар вә боларның иң зур рәисләре булган Колшәриф тә монда иде. Русларны болар җиңел сурәттә түгел, бәлки кораллар вә кылычлар белән каршы алдылар. Барысы бер мизгелдә Мәскәү гаскәре өстенә һөҗүм иттеләр. Шулкадәр гайрәт белән каршы тордылар ки, хәтта дошманнары мәдех итмешләрдер, ягъни мактамышлардыр. Ахырда Колшәриф үзенең беркадәр әсхабы, ягъни юлдашлары белән шунда булган мәдрәсәнең түбәсенә менеп сугышты, руслар мәдрәсә түбәсеннән чәнчеп төшерделәр. (Мөстәфадел-әхбар, Т. 2, 2 б.) Шулай итеп, бер җан калмыйча, шушында булган галимнәр, шәкертләр, сәед вә шәрифләр, ягъни дин башлыклары һәм игътибарлы кешеләр шәһид булдылар.

Ядкәр хан вә башка сәламәт мөселманнар, моннан соң хан сарае булган кальгага кереп, капкасын бикләделәр. Вә бер сәгать кадәр сугышканнан соң, руслар капканы ватып керделәр. Казан халкының хатын вә кызлары һәммәсе шунда җыелган, алтын, көмеш, энҗе вә мәрҗән

Казанны буйсындыру. Академик Карл Вениг картинасыннан.
XIX гасыр.

кебек кыйммәтле җиһаз вә асыл ташлар үзләре белән бергә бер тарафта иде. Вә икенче бер тарафта хан вә аның тирәсендә ирләр җыелып торырлар иде. Руслар кергәннән соң, тагын бер микъдар сугыштылар вә, гаҗиз калачакларын белгәннән соң, кальганың бер кечкенә ишегеннән качмакчы булдылар, фәкать ул җирдә дә рус гаскәре булганлыктан, чарасыз туктадылар. Болар барысы 10 мең кадәр җан хисабы булыр иде.

Менә шул вакыт мөселманнар русларга каршы: «Сугышны туктатып торыгыз!» — дип кычкырдылар. Сугыш тукталганнан соң: «Без бу сәгатькә кадәр ватаныбыз вә ханыбыз өчен сугыштык, инде Казан сезнеке булды, фәкать ханыбызны сәламәт килеш алып, Иван Грозныйга тапшырыгыз, аннан соң без мәйданга чыгып, сезнең белән яңадан Алла өчен сугышачакбыз!» — диделәр. Моннан соң Ядкәр ханны рус гаскәренә тапшырдылар[29]. Сарай түрәләренең картларыннан яки карачы (Татарлар хөкүмәтендә «карача», «карачы» бер мәнсаб, ягъни дәрәҗә булса кирәк) булган Заниятне һәм дә ханның ике сөт анасын яки тәрбия итүчеләрен дә[30] бирделәр дә, тагын сугышырга керештеләр. Иң ахырда чишенеп, Казан елгасына төштеләр вә йөзеп чыктылар. Артларыннан руслар тоташ аталар иде. Моннан соң артларыннан атлы гаскәр җитеп, урап алды вә ошбу вакыт тагын бер мәртәбә сугыштылар. Һәрникадәр 5 мең микъдардан артмасалар да, шул кадәр гайрәт белән каршы тордылар ки, Мәскәү гаскәрен ярып чыгып киттеләр вә сазлык җиргә барып, урман эченә керделәр. Болар качып баручылар түгел иде, бәлки гаскәр җыеп килеп, яңадан Казанны кайтарып алу вә Мәскәүне куу теләге белән чыккан баһадирлар иде. Иван Грозный вә рус гаскәр башлыклары боларның болай котылып китүләреннән куркуда булырлар иде. Шул сәбәпле артларыннан тагын атлы гаскәр җибәрелде. Болар да урман арасында артларыннан җиттеләр. Мөселманнар әйләнеп болар белән яңадан сугыштылар. Бу вакыт, бер җан иясе калмыйча, тәмам шәһид булдылар.

Казанны руслар алды, шәһәргә керделәр, бөтен халыкны кылычтан кичерделәр. Мәчет вә мәдрәсәләрдә, өй вә урамнарда булган халыклардан бер җан әһеле сәламәт калмады[31]. Бөтен урам вә мәйданнар адәм үләксәсе белән тулды. Болыннарда, урманнарда өем-өем үлекләр ятыр иде. Бөтен шәһәр байгыш оясы хөкеменә керде. Тирә-як авылларда булган хатын вә кызларны әсир итеп алдылар.

Кол Шәриф. Рушан Шәмсетдинов рәсеме.

50 мең кадәр хатын белән ятим бала саналды. Менә шушы сәгатьтән Казан мәмләкәте мөнкариз улып, ягъни юкка чыгып, Мәскәү милкенә керде. Бу вакыйга исә һиҗри белән 959 нчы, миляди белән 1552 нче елда, шәввәл аеның 22 се сишәмбе көн, 1 октябрьдә буладыр[32].

Мәскәү гаскәренең башлыгы булган Михаил Воротынский, шәһәрнең алынганын, күз күрмәгән вә колак ишетмәгән ганимәт малы җыелганын игълан итәр өчен читтә торган Иван Грозныйга адәм җибәрде.

Ошбу вакыт Палецкий Ядкәр ханны Иван хозурына китерде. Ядкәр исә тезләнеп гафу үтенде[33].

«Мурали» (Нургали) капкасыннан Хан сараена кадәр булган юлларны, урамнарны тупрак вә ташлардан, адәм үләксәләреннән пакьладылар, шуннан соң Иван Грозный үзенең поплары вә гаскәрләре белән, тәреләрен күтәреп, шәһәргә килделәр. Иван Грозный Хан сараена керде вә бөтен байлыкны үзенә алды. Икенче мәртәбә кергәндә, Хан сарае янына чиркәү урыны билгеләде. Бу чиркәүнең исеме электә Благовещение иде, хәзер исә Кафедральный исемендәдер.

Мөселманнардан калган өй вә корылмалар харап булып, бу көндә анчак, ягъни бары Сөен Бикә манарасы ялгызы торып калмыштыр.

Ядкәр ханны Иван Грозный үзе белән алып китте, Мәскәүгә баргач, чукындырдылар. Симеон исеме кушып, Андрей Кутузов исемле бер рус боярының Мария исемле кызын бирделәр. 1560 елда Фелин шәһәреннән әсир алынган нимсәләрне, ягъни немецларны Мәскәү халкына күрсәтеп урамда йөрткәндә, бер гаскәр башлыкларына каршы килеп Ядкәр хан: «Русларга корал тотарга өйрәттегез, бу гыйлемегез белән безне харап иттердегез. Ләкин без генә түгел, үзегез дә харап булдыгыз, үзегез дә безнең көнгә төштегез!» — димештер. (Карамзин, Т. 9, 29 б.)

Казан дәүләте менә шушы рәвештә мөнкариз булды[34]. Моның сәбәбе исә — мөселманнарның үз араларында булган мохаләфәтләре, ягъни каршылыклары, җәһаләтләре, ягъни наданлыклары вә идарәсезлекләре булганы югарыда язганнарыбыздан мәгълүмдер[35].

Казан ханнары хакында без язган ошбу тәрҗемәи хальләрнең чыганаклары Карамзин, Рычков вә Соловьев кебек рус тарихларыдыр. Ләкин бу тарихларның кайбер җирләре, рәсми кәгазьләрдән алынган булса да, әксәре, ягъни күбрәге, монахлар тарафыннан язылган риваятьләрдән җыелмыштыр. Монахлар тарафыннан үзләренең

Басып алынган Казанда христиан динен кертү.

дин дошманнары дип инанган халыклар хакында язган нәрсәләр бик тә игътимад ителмәс, ягъни аларга бик ышанырга ярамас[36].

Мәскәү гаскәре кергәннән соң Казан шәһәрендә бер җан мөселман калмаганлыктан, әһел ислам ягыннан булган хәбәрләр бөтенләй тәләф вә зайг улмыштыр, ягъни һәлак һәм әрәм булмыштыр[37].

ИСКӘРМӘЛӘР (ЯДКӘР ХАН):

1 Шаһ Гали турындагы мәкаләне карагыз.

² Сүз 6 март турында бара. Бу көнне С. Микулинскийның үзенең Казанга килүе мәгълүм түгел. Ул 6 мартта Зөядән Казанга ике татарны (С. М. Соловьев буенча: «двух казаков») язу белән җибәрә. Анда: «Бөек кенәз һәм падишаһ Шаһ Галине ханлыктан төшерде, мине Казанга үзенең наместнигы итеп билгеләде. Барыгыз да миңа һәм Иван падишаһка турылыклы булу турында Зөягә килеп ант итәргә тиешсез»,— дип язылган була.

³ Казанлылар, Зөядә торучы Чапкын Отучев белән Борнаш кенәз ант кабул итәргә Казанга кайтсыннар, дип җиткерәләр. Болар һәм укчылар башлыгы Иван Черемисинов күренекле өлкән кешеләрдән 7 мартта ант алалар. 8 мартта Ходайкол

углан, Чапкын, Борнаш һәм муллалардан торган илчелек, Зөягә килеп, килешү төзиләр. Бу килешү буенча Казан Русиядәге урыс шәһәрләренә охшарга, кремльдә урыс воеводасы торырга тиеш була. Шунлыктан Казанны мөселманлыктан «чистартырга», шәһәрдә бәкләрнең, морзаларның өйләрен алып, урыс бояр балаларына һәм воеводаларга бирелү турында карар кабул ителә. Димәк, Казан урыс кулына кан коймыйча гына бирелсә дә, нигездә үзенең милли төсмерен, татар-мөселманлыгын югалтырга тиеш булган. Шул ук вакытта булачак наместник һәм воеводалар да, илчелек таләбе буенча, казанлыларның олуг кешеләренә урыс боярлары һәм дворяннарыныкы кебек өстенлекләр вәгъдә итеп ант эчәләр. Күренә ки, ханлыкның югары катлавы барыннан да элек үзенең шәхси мәнфәгатьләре турында кайгырткан.

[4] Шуннан соң И. Черемисинов һәм тылмач, яңадан Казанга килеп, калган халыкны да ант иттерергә керешәләр. Аларга Чапкын Отучев, Кол Гали, 4 бояр балалары ияреп килә: бу делегация наместник шәһәргә керер алдыннан тәртипне күзәтергә һәм урыс гарнизонын урнаштыру өчен йортлар әзерләргә тиеш була. Хан буларак Казанны ташлап чыккан Шаһ Гали шәһәрдә калган хатыны ханбикәгә, С. Микулинский башкалага керер алдыннан ук Зөягә чыксын, дип хәбәр сала. 8 мартта кич белән наместникка: шәһәрдә тыныч, ханбикә китәргә җыена, Хан сарае бушатыла, халык, ант итеп, өйләренә тарала, дип хәбәр бирәләр. Төнлә Казанга Микулинскийның багажы-йөге китерелә һәм, кирәк була-нитә калса, дип, 72 пищаль белән коралланган 70 казак кертелә. Наместникның Казанга керүе иртә белән 9 мартка билгеләнә.

[5] 9 мартта иртә белән наместник Микулинский Зөядән Казанга таба юлга чыга. Аның белән бергә воеводалар бара, хәрби отряд хәрәкәт итә, арттан Шаһ Гали заложниклар сыйфатында 6 мартта Казаннан алып чыккан мирзалар, бәкләр (500 гә якын татар) атлый. Юлда Зөягә юнәлгән ханбикә очрый. Шәһәрдә барысы да тыныч, дип, чапкыннар хәбәр биреп тора. Наместник командасы Бишбалтага килеп җиткәч, аны озата килүче Ислам һәм Кибәк бәкләр, Әликәй мирза Микулинскийдан үзләрен алданрак җибәрүләрен сорыйлар. Шәһәргә керүгә: «Капкаларны ябыгыз, шәһәрне, үзегезне үлемнән сакларга басыгыз, чөнки без урыс воеводаларының теләгән бе.әбез, алар бөтен Казан халкын кырып бетерергә уйлыйлар»,— дип халыкка җиткерәләр. Аларга тиздән Чапкын Отучев та кушыла. Казан халкы үз тормышын һәм шәһәрне сакларга күтәрелә. Капкалар бикләнә, шәһәр стеналары туплар, сакчылар, кораллы сугышчылар белән тула.

[6] Бу бик принципиаль момент. Чыннан да, Н. М. Карамзинның татарларның үз версиясен язмавы сәер. Вакыйга, бәлки, икенчерәк төсле булгандыр, ләкин рәсми идеологиягә буйсындырылган тарих беркайчан да хакыйкатькә хезмәт итмәде. Икенче яктан, Ислам, Кибәк, Әликәй, башта урыс яклы булып та, аннары кинәт казанлыларны үлем куркынычыннан кисәтүләренең, бәлки бер нигезе, сәбәбе булгандыр. Воеводаларның хәйлә-мәкерләрен белүләре дә бик ихтимал. Ләкин, чын дөреслекне без кайчан да булса белербез, дип өметләнергә әлегә урын юк.

[7] С. Х. Алишев язуынча, «шулай итеп, Казанны төрле хәйләле, мәкерле юллар, «тыныч» ысул белән рус дәүләтенә кушу омтылышы уңышсыз тәмамлана».

[8] Мәскәүнең Казанга ел саен диярлек ябырылуын, яу чабуын Ә.-З. Вәлиди мондыйрак юллар белән тасвирлаган иде: «Руслар ничаклы күп җиңелделәр, һичбер вакыт галәбә [җиңү] казана алмадылар. Ләкин руслар бу кадәр җиңелүләрдән бөтенләй хәсрәтләнә торган халык түгел иделәр... Казанлыларга русларның бәласеннан котылу һич мөмкин түгел иде. Алар йөз мәртәбә беррәттән җиңеләләр, мең мәртәбә киләләр дә, ябышалар... чөнки Казан ханлыгында хисапсыз күп булган рус халыкларына каршы һәрвакыт сугышып торырлык халык вә гаскәр юк иде... Ошбу көнгә кадәр казанлыларның үзләренә кыяс ителмәслек [чагыштыргысыз] дәрәҗәдә күп булган русларга җиңелми килүләре зур егетлектән башка бер эш түгел иде, руслар илә өзлексез сугышу аларны какшата иде...» Вәлиди Казанның 20 меңнән артык гаскәре булмавын да берничә урында искәртеп уза.

[9] Казанның халыкара изоляциядә калуын, хәрби яктан өметсез хәлен Ә.-З. Вәлиди болай аңлатты (теле җиңелләштереп бирелә): «Бу вакытлар Мәскәү кенәзенә Казанны алганчы сугышу өчен иң уңайлы вакыт иде. Һичбер хәвефле урыны юк иде: ул инде көнбатыш тарафындагы падишаһлар белән союз төзегән, Кырымның Сәхиб Гәрәй хан вафат итте, Әстерхан ханы Ямгурчы Русиягә, дуслык күрсәтеп, гаскәр белән ярдәм бирә, Әстерханның зур кенәзләреннән Кайбула мирза Мәскәүдә Җан Гали ханның кызына өйләнеп, рәсми каенатасы булган кенәз Иванга һәртөрле ярдәмнәр күрсәтә иде. Нугай кенәзләре Русия белән сәүдә итешеп дуслыкта торалар иде. Шул вакыт Русия өчен иң куркыныч булган Истанбулның солтаны Сөләйман Кануниның Кырым (Кәфа) дагы Русия пашалары Иванның дуслары иделәр. Алар Казанны солтанга бөтенләй Русия кулында вә Русиягә фәкать буйсындырылган итеп кенә күрсәтәләр иде. Солтан үзе Казан белән Кырым кушылуыннан, ягъни Кыпчак мәмләкәте килеп чыгуыннан курка иде. Вә шулай

Казанның иң ахыргы сәгатьтә таянган вә ярдәм көтеп торган солтаннан да Иван имин булган иде. Казанның бик күп булмаган халкы көннән-көн фетнәләр һәм русларга китү сәбәпле азаеп, Казан тәмам зәгыйфьләнгән иде. Инде ошбу вакыт гаскәре күп вә һәрбер кенәзләре берлектә булып, куәтле, гайрәтле вә усал падишаһка ия булган Русиягә һич башсыз, эче фетнә белән тулы вә егерме меңнән артык гаскәре булмаган һәм берьялгызы калган Казан хөкүмәтен алу осталык, баһадирлык вә сәлат булганда бик кыен эш түгел иде».

[10] Иван Грозныйга Казанны алырга ярдәм иткән төп сәбәпләрнең берсе итеп барлык чыганаклар да ханлыктагы башбаштаклык, астан сүз йөртү, шәхси мәнфәгатьләре өчен динен, милләтен, ватанын урыска сату, массовый төстәге хыянәтне күрсәтәләр. Мәскәү хезмәтенә унарлап, йөзәрләп, хәтта меңәрләп кергән татарлар соңыннан үзләре үк асыл ватаннарына кылыч тарталар, милләттәшләренең һәм диндәшләренең җанын кыеп, илне җимерергә ярдәм итәләр. Казанлылар, дип язды, Ә.-З. Вәлиди, «үз араларында бер-берсен үтерешеп, кырышып торалар иде. Бу өзлексез фетнәдән качып, ун мең кадәр Казанның Москва тарафдарлары Москва хезмәтенә керделәр». Икенче бер җирдә шул ук тарихчы: «Русларның эчләрендә динен, милләтен танымый-белми торган ниһаясез күп татарлар хезмәт итә иделәр»,— дип күрсәткән иде.

[11] Урыс наместнигы С. Микулинскийны кире какканнан соң, яшь бәкләрдән һәм мирзалардан башында Чапкын Отучев торган яңа хөкүмәт оештырылган. Бу хөкүмәт тиз арада хәл итү өчен үз алдына мондый бурычлар куйган: 1) тәхеткә яңа хан утырту; 2) Тау ягын кире Казан карамагына кайтару; 3) өзлексез экспансия алып барган Мәскәүгә каршы сугышка хәзерлек чаралары күрү. Шушы максатлардан Казан хөкүмәте кешеләр җибәреп, Әстерхандагы ханнар династиясеннән булган шаһзадә Ядкәрне хан итеп чакырган.

[12] Ядкәр 30 яшьләр тирәсендәге кеше итеп тасвирлана. Аның хөкүмәтенә сәед Колшәриф, Чапкын Отучев, Әликәй, Нарыйков, Себер бәге Кибәк, Нугай бәге Зиннәт яки Зәйнәш, Ислам, Дәрбиш кебек олылар кергән.

[13] Бу сүз бирүнең үтәлү-үтәлмәве хакында 29 һәм 33 нче искәрмәләрдәге аңлатмаларга игътибар ителсен.

[14] Шаһ Галинең хәрби җәһәттән әзерлеге һәм мөмкинлекләре турындагы фикерләрне без «Шаһ Гали» исемле материалның искәрмәләрендә күрсәтеп үткән идек инде.

[15] Иван Грозныйның Казанга 1552 елдагы явы да, аның һәм ата-бабаларының әүвәлге еллардагы һөҗүмнәре дә чын мәгънәсендә «тәре походлары» була. 1551 елда Зөя крепостен төзе-

гәндә беренче эш итеп агач чиркәү куюлары да шуның бер галәмәте. Бу 1552 елгы яулап алу сугышына да Казанны басып алуның төп рухландыручысы, идеологы митрополит Макарий фатиха бирә. М. Г. Худяковка мөрәҗәгать итик: «Войско было напутствовано митрополитом Макарием, который трактовал эту завоевательную войну, как святое дело, направленное к обращению «безбожных» и «поганых» мусульман в христианство и к освобождению пленников из неволи, воинов же, павших в этом священном походе—как мучеников за веру». Димәк, яулап алу дини флаг астында, православиенең исламны бетерүгә, мөселманнарны чукындыру максатында алып барылган. Рәсми чыганак булган «Патша Китабы»н («Царственная Книга»)да теркәлгәнчә, гаскәрен барлаган Иван IV, үзенең сугышчыларына мөрәҗәгать итеп, болай дигән: «Агаряне (мусульмане), они Бога не имеют... мы же имеем владыку своего Господу Бога; аще за имя его постражем, да венцы мученически увяземся». Ә.-З. Вәлиди язганча, Казан походы өчен гаскәр җыйганда, Иван Грозный урыс шәһәрләрендә мондый оран салган: «Христиан динендә булганнарның рәхәте өчен, Казанны таптарга, христиан динен югары күтәрергә вакыт җитте». 1552 елның 23 августындагы һөҗүм алдыннан Иисус Христос сурәте (образы) астында Иван IV гаскәрләре алдында мондый сүзләр әйтә: «Приспело время нашему подвигу! Потщитесь единодушно пострадать за благочестие, за святые церкви, за православную веру христианскую, за единородную нашу братию, православных христиан, терпящих долгий плен, страдающих от этих безбожных казанцев...»

Менә ни өчен Казанны алганнан соң мәчетләр булган җирдә таш өстендә таш калмаган икән.

[16] С. М. Соловьев, җавап хатының эчтәлеген үз җаена көйләп, болай ди: «В нем заключалось ругательство на христианство, на Иоанна, на Шиг-Алея и вызов на брань». Кыскасы, барысына да урыс явыннан һич югында биш мәртәбә ким казанлылар гаепле булып чыккан.

[17] Моңарчы язылган совет рәсми тарихларында Казан ханлыгының Мәскәү хөкүмәтенә каршы яман да агрессив сәясәт алып барганы, аның җирләренә әледән-әле яу чапканы, төрле вәхшилекләр кылганлыгы бәян ителеп киленде. Баксаң, Казан дәүләтенең көче үз җирендә, борын төбендә генә Зөя крепосте салуга гына түгел, хәтта Казанга терәлеп дип әйтерлек аккан Идел аркылы урыс гаскәренең чыгуына да, көймәләреннән корал, азык-төлек бушатуларына да каршы тора алмаган.

[18] Дөресе: Ябынчы булырга тиеш.

[19] Камай мирза Хөсәенов, ватанына хыянәт итеп, җиде казак белән Казаннан качып чыгып, Иван Грозныйның аягына егыла.

Соңыннан, Казан инде алынганнан соң, урыслар биргән гаскәр белән, баскыннарга каршы баш күтәргән халыкны кырып йөри.

[20] Казанны камау моңа кадәр 1487, 1524, 1530, 1550 еллардагы һөҗүм итүдән нык аерылып торган. Элекке камауларда гаскәрләр дәррәү һөҗүмгә ташланса, бу юлы аларга шәһәргә ыргылмыйча, ул вакыттагы барлык инженер-техник ысулларны ахыргача кулланырга кушылган. Урыслар үрмә (туры) һәм текмәләр (тын) системасы булдырырга, җир астын казып шартлату әмәлләре, диварлар белән янәшәдә алар биеклегендә башнялар төзергә тырышканнар. Бу гамәлләрдә Мәскәү явына чит ил (Европа) белгечләре — инженерлары күп сабак биргәннәр. Моннан чыгып фикер йөртү, Казанны алу — халыкара христианлыкның исламга каршы бердәм фронт тәшкил итүе нәтиҗәсе, дигән фаразга юл калдыра. Бу хәрби әзерлекләрне күргәндә, урысларга Казанның эчке гаскәре гел һөҗүм итеп торган. Боларга Ябынчы, Шунак һәм Явуш атлыларының һөҗүм итеп торулары да өстәлгән. Казанны алышучы кенәз Курбский хәтта «интегеп беттек» дип язган. Воеводалар да, кара ипи, ягъни сохари, ашап өлгереп булмый, казанлылар һөҗүм итәләр, дип зарланган.

[21] Ябынчы гаскәрләренә каршы һөҗүмгә Горбатый һәм Серебряный командалыгындагы 30 мең җәяүле һәм 15 мең атлы гаскәр ташлана. 31 августтагы бик каты сугышта инде аз гына санлы калган Ябынчы гаскәре җиңелә, таралган сугышчыларны урыслар Киндерле елгасына кадәр куалар.

[22] Чыганакларда немец Размысл (елъязмада: «Немчина, именуемый Размысл»), инглиз инженеры Бутлер (атаклы урыс химигы Бутлеровның ерак бабасы, дигән хәбәрләр бар) исемнәре очрый.

[23] Сүз «Таһир мунчалары» дигән юыну урыннары турында бара булса кирәк.

[24] Башка чыганакларда, 4 сентябрь, дип күрсәтелә.

[25] Ябынчы гаскәрен 31 августта җиңү белән генә урыс командованиесе канәгатьләнми. Чөнки бу каһарманны бөтенләй зарарсызландыру өчен аның базасы Биектауны, анда урнашкан Арча ныгытмасын алмыйча мөмкин булмаган. Шуның өчен 6 сентябрьдә өч полк составында зур армия походка чыга. Аларга юл күрсәтергә Шаһ Гали яраннары, Темник бәге Еникәй отряды бирелә. Ябынчы гаскәренең ныгытмасы урман һәм сазлыклар эчендә була. Воеводалар штурмга җәяүләп баралар. Көчләр тигез булмаганлыктан, 2 сәгать сугышканнан соң, ябынчылар таратыла, 200 кеше әсир төшә, ныгытма җимерелә. Шуннан соң Горбатый чирүе очраган авылларны талап, көл итеп Арчага юл

ала. Арчалылар, көчләре бик аз булганлыктан, бу афәттән куркып качалар. Баскыннар шәһәрне таларга керешәләр. Горбатый, гаскәрен берничә төркемгә бүлеп, Казансудан Чулман (Кама) һәм Нократ (Вятка)га кадәр җирне яулап алырга, 150 чакрым җирне аркылыга-буйга болгар-татарлардан чистартырга җибәрә. Елъязмалар: «Авыллар яндырылды, бихисап күп терлек көтүләре кулга төште, хатын-кыз һәм балалар әсир алынды»,— дип язалар.

[26] Ризаэтдин Фәхретдиннең бу искәрмәсе басып алучыларның нинди фанатик, сихер-ырымнарга җиңел ышанучылар икәнен искәртүе белән кызыклы.

[27] Тексттагы даталарда кайвакыт бер көнгә аерма килеп чыга. Мөгаен, бу Ризаэтдин Фәхретдиннең көн исәбен милядидан һиҗригә күчерүе сәбәпле килеп чыккандыр. Ләкин вакыйгаларның хронологик агышы дөрес бирелгән.

[28] Биредә инде сүз 2 октябрь турында бара.

[29] Безгә калса, Казан өчен сугышның шактый сәер моменты бу. Ил өчен соңгы сулышына кадәр сугышырга ант эчкән (әллә коры сүз генә биргәнме?) гайрәтле хан асылда үз теләге белән әсир бирелгән булып чыга. Чыганакларда Ядкәрнең яралануы һәм гомумән ничек сугышуы турында да бер сүз юк. Димәк, әсирлеккә яраланган килеш төшмәгән. Монда ике версия булырга мөмкин: йә Казанның соңгы ханы Ядкәр, сәед Колшәрифтән аермалы буларак, изге сугышта шәһид китәсе килмичә, башын саклауны артык күргән, яисә тоташтан монахлар каләме белән язылган елъязмалар алдый, Казанның соңгы хөкемдарын мәсхәрәләп, юри куркак итеп тасвирлый. Әмма Мәскәүгә китерелгәннән соң чукындырылып, урыска ихлас хезмәт итә башлавын искә алсак, беренче фаразыбызның дөреслеккә якынрак икәнен күрербез...

[30] Соловьев: «выдавший царя вместе с тремя приближенными к нему вельможами»,— дип яза.

[31] Шул ук тарихчының хезмәтендә мондый сүзләр бар: «В Казани не осталось в живых ни одного из ее защитников, потому что Иоанн велел побивать всех вооруженных, а брать в плен только женщин и детей».

[32] Миляди белән 2 октябрь.

[33] Казанны актык сулышына кадәр сакларга сүз биргән ханның яулап алучы алдында тезләнеп, ни-нәрсә өчен гафу үтенүен аңлап булмый. Һөҗүмнәр вакытында Иванның: «Бирелсәгез, барыгызны да гафу итәм», дигән сүзләренә казанлылар: «Без Аллаһе Тәгаләдән башка беркемнән дә гафу сорамыйбыз»,— дип җавап бирүләре бу ханга кагылмаган булса кирәк, югыйсә ул гомумән әсир төшәргә риза булмас иде.

[34] Кайбер тарихчылар, Казан дәүләтенең эчке һәм тышкы хәлләрен, үткәнен һәм фараз ителгән киләчәген анализлап, аның иртәме-соңмы барыбер Мәскәү кул астына керәчәге турында фикер йөрттеләр. Казанны яулап алуны Иван Грозный үзе эшләмәде, фәкать моның өчен бөтен шартлар өлгергәч кенә, диделәр алар, татар мәмләкәтен басып алу мөмкин булды. Һәм бу форсат Мөдһиш Иван (Иван Грозный) гасырына туры килде. Казанның нәкъ менә Иван IV тарафыннан фәтех ителүе, дип язды Ә.-З. Вәлиди безнең «тарихыбызның иң уңайсыз ноктасыдыр». Бердән, аның фикеренчә, Иван кенәзләр арасында акыл һәм зирәклек белән аерылган зат түгел, икенчедән, гадәттән тыш дини фанатик иде. Бу җәһәттән З. Вәлиди, башка тикшеренүчеләрнең фикерен мисал итеп китереп, болай ди: «Басып алынуы хәл ителгән Казан Иван Грозный тарафыннан алынганчы, йә аннан элек, йә аннан соң, мәсәлән, Борис Годунов кебек гыйлемне һәм цивилизацияне тәкъдир итә ала торган бер зат тарафыннан фәтех ителсә, яхшырак булыр иде».

[35] 1552 елның 2 октябрендә Казанның алынуы әле илнең язмышын хәл итми. Татар халкы һәм Казан дәүләтенә кергән башка халыклар (марилар, чуашлар, удмуртлар, мордвалар) әле 1557 елга кадәр дәүләтне торгызу, мөстәкыйльлекне кайтару өчен героик көрәш алып баралар. Бу көрәш үзенең бөек каһарманнарын тудыра. 1552—1557 еллардагы баш күтәрүләр татар һәм башка халыкларның чын мәгънәсендәге Ватан сугышы була.

[36] Бу бик мөһим искәрмә. Р. Фәхретдин, үтә җитди тикшеренүче буларак, үзе файдаланган урыс чыганакларына бик тәнкыйди килергә чакыра, чөнки алар үзләренең дин дошманнарын күрә алмаучы елъязмачы монахлар каләме белән иҗат ителгәннәр.

[37] Болгар һәм Казан тарихы буенча практик яктан бер генә язма чыганакның да калмавы Иван Грозный явының вәхшилеге һәм чирканыч фанатизмы белән аңлатыла. Р. Фәхретдин үзенең «Болгар вә Казан төрекләре» дигән хезмәтендә (ул «татар» сүзен «монгол» этнонимы урынына куллана) болай дип язды: «Руслар болгар («татар» дип әйтәсе килми.— *Р. Ә.*) каберлекләрендәге язулы ташларны гына да сәламәт калдырмадылар. Башка нәрсәләрне әйтеп торасы да юк... Кабер ташларын гына да үз хәлләренчә калдырырлык вөҗданга ия булмаган кавем арасында нинди тарих чыганагы калсын!..»

Татар мәдәниятенә Иван Грозный явы ясаган коточкыч удар турында Ә.-З. Вәлиди мондый юллар язып калдырды: «Иван IV динсез дип фикер йөрткән мөселман ханнарының каберләрен туздырып, сөякләрен алып ташлатты. (Тик дошман-

нан сакланып торырга уңай булуын уйлап, Сөенбикә бина иттергән вә бу көнгә кадәр сәламәт калган манараны калдырды.) Мөселманнарның, казанлыларның үз диненә каршы дип тапкан гыйльми әсәрләрен, китапларын, язуларын — берсен дә сәламәт көйгә алып калмады. Ул заманда белем җәһәтеннән бик түбән урында торган рус гаскәре, динсез дип уйланган казанлыларның әсәрләрен бер дә кызганмады. Шулай итеп, Иван Грозныйның дини фанатизмы тәэсирендә безгә тарихыбызны, үткәнебезне күрсәтерлек бернәрсә дә сәламәт калмады».

Моңарчы язылган Казан тарихларының нигездә орыш-сугышлардан гына торуы, мәдәният, сәүдә, халыкара багъланышлар турында мәгълүматларның юк дәрәҗәсендә аз булуы татар милли чыганакларының туздырылуы, ә монахларның чит мәмләкәтнең мондый хасиятләре белән кызыксынмавы һәм шуңа күрә теркәмәве белән аңлатыла.

ЙОМГАК

Шулай итеп, без бөек тарихчыбыз Ризаэтдин бине Фәхретдиннең Казан дәүләте хөкемдарларының шәхесләре, аларның идарә ысуллары, кылган эшләре, ханлыкның эчке һәм тышкы хәле турындагы мәкаләләр циклын укучыларга тәкъдим итәбез. 1439 елдан 1552 елга кадәр Көнчыгыш Европаның эре һәм куәтле бер дәүләте булып хөкем сөргән, зур халыкара абруйга ия булган Казан ханлыгы тарихының шанлы чорлары да, фаҗигале дәверләре дә биредә шактый калку чагылыш таба. Татар укучысына бу материалларны 1908—1909 еллардан соң укырга нигездә насыйп булмады. Мәктәп балаларының зиһенен дистәләгән еллар буена рәсми совет дәреслекләрендә бәян ителгән дөреслеге үтә шөбһәле, бик тенденциоз мәгълүматлар белән миңгерәүләтеп килделәр. Нәтиҗә буларак, берничә буын татар халкы үз тамырларын, үз тарихын, үз бабаларының каһарманлыгын белүдән мәхрүм булып калды.

Без китап рәвешендә тәкъдим иткән бу мәкаләләрне укыганнан соң, күп кенә укучылар, бәлки, фаҗигале һәм мәгърур тарихыбызга карата кайбер әүвәлге фикерләрен үзгәртерләр һәм, әлеге җыентык материаллары белән генә чикләнмичә, махсус әдәбиятка, тарихчы классикларыбызның әсәрләренә мөрәҗәгать итәрләр, үткән дәверләр, бай мирасыбыз хакындагы хезмәтләрне тагын да кызыксыныбрак укый башларлар.

КАЗАН — ХАНЛЫК МӘРКӘЗЕ

(Башкаланың тарихи топографиясе)



Кол Шәриф мәчете. XVI гасыр. Рушан Шәмсетдинов рәсеме.

Татарстан башкаласы Казан географик яктан шундый уңайлы һәм җайлы урнашкан ки, бу урынны кешеләр борын-борын заманнардан бирле яшәү өчен сайлап ала торган булганнар. Әмма әлеге язмада алга куйган максатыбыз бераз таррак, шуңа күрә андый ерак дәверләргә, чал тарихка ук кереп тормастан, Казан шәһәренең ханлык башкаласы сыйфатында яшьнәп яшәгән дәверендәге хәлен күздән кичерик. Димәк, сүз Казанның Мәскәү дәүләте тарафыннан яулап алынганчыга кадәрге гомуми күренеше, тарихи топографиясе хакында барачак.

Ул вакытта татар ханлыгы үзәге Казан ирекле, мөстәкыйль тормыш белән яши, хәтта үзенә килүче адәмнәрне

мәгъруp һәм кабатланмас матурлыгы белән әсир итә. Әмма бераздан аның шанлы тормышында кискен үзгәреш була — 1552 елда татар башкаласы үз гаскәреннән биш тапкыр ишлерәк Мәскәү чирүе тарафыннан яулап алына. Шушы көннән аның язмышы текә борылыш ясый, күз явын алырлык төзек кала танып булмаслык хәрабә хәленә төшә. Иван IV кушуы буенча мәчетләр, зиратлар, бай китапханәләр җимертелә, яндыртыла, туздырыла, юк ителә. Зиннәтле Хан сарае яулап алучыларның корал саклау урынына әверелә. Башкаланы алуның икенче көнендә үк, агачтан гына булса да, вакытлыча Киприан һәм Иустин чиркәве салып куела, яңа таш чиркәүләргә, монастырьга нигез салына. Шулай итеп, дошман кулына калу белән татар Казанының йөзе үзгәртелә башлый. Хәер, монысы инде үзенә бер аерым тема, җәелеп китмик. Әлегә Казан каласын салу турындагы риваятьләрнең берсен искә төшереп үтик.

Бәлки, кайберәүләр ханлык үзәге Казан каласы үсеп чыкканчы болгар-татарның тагын бер Казаны булганлыгын белеп тә җиткерми торганнардыр. Анысы Казан елгасы буенча өскә күтәрелгәндә 45—50 чакрым арырак урнашкан була. Хәзерге көндә аннан Арча тимер юлы уза. Камаево станциясе бу кала урыныннан әллә ни ерак тормый.

Каланың барлыкка килүе турында төрле риваятьләр яши. Берсендә вакыйгалар болайрак сурәтләнә. Көннәрдән бер көнне Болгар иленә Урта Азиядән зур яу белән Аксак Тимер исемле кансыз җиһангир килеп чыга. (Риваятьнең тарихи нигезе 1395 елгы Аксак Тимер явы, Идегәй мирза, Алтын Урда ханы Туктамыш вакыйгаларына барып тоташа.) Аксак Тимер Болгар шәһәрен җимертә, болгарларның соңгы ханы Габдулланы үтерә. Бәхеткә, болгар иленең олуг адәмнәре, хан нәселенең киселеп калуыннан куркып, аның хатыны ханбикәне һәм ике угылы — тугыз яшьлек Галимбик белән җиде яшьлек Алтынбикләрне явыз җиһангир күзләреннән ераккарак яшерәләр, саклап калалар. Сугыш афәте үтеп киткәч, ханның уллары бөтенләй башка җиргә, Казан дигән елга буена яңа кала салдыралар һәм аны елга исеме белән «Казан» дип атыйлар, имеш.

Бу хәлләрдән соң күпмедер вакыт узгач, калада яшәүче халык аны елга тамагынарак, ягъни Казан суының Иделгә койган төшенә күчереп салуны кирәк таба. Болай

эшләү калага сәүдәгәрләр килеп йөрүне дә җиңеләйтергә тиеш булган, чөнки аралашу һәм сәүдә җайга салынмаганда кала үзе дә, гомумән, дәүләт тә чәчәк ата алмас иде. Шулай итеп, Иделдән алты-җиде чакрымдагы өр-яңа җирдә яңа кала үсеп чыга. Һәм бер үк исемдә ике шәһәр була алмаганга, иске кала табигый рәвештә Иске Казан, ә яңасы Казан дип йөртелә башлый.

Чыннан да, яңа кала (Казан) өчен урын бик белеп, бөтен ягы исәпкә алынып сайлана. Шәһәрнең үзәк өлеше биек калкулык өстенә урнашып, аннан бөтен тирә-юнь күренеп тора, бу төштән ерак-еракларга сузылып киткән гүзәл манзара ачыла. Каланың биек җирдә торуы хәрби яктан да бик уңайлы була, чөнки дошманның якынлашуы әллә кайлардан күренә.

Төньяктан кала урнашкан калкулык кырт киселеп тәгәлләнә, ә аста җәелеп яткан болын буенча тыныч кына Казан суы ага. Дөрес, елга бу урында борыны белән бераз үзәнгә табарак чыгып торган калкулыкка килеп төртелеп, текә генә борылыш ясап ала да кабат үз юлына ята — яшел хәтфә белән капланган үзәннән Иделгә таба юл ала. Казан суының аргы ягында, яшел болын тәгәлләнгән төштә, биек дивар булып нарат урманы күтәрелә.

Көнбатышта калкулык итәгеннән үк Болак суы аккан, ул Казан суына койган. Бу урында, Казан суы ярында, ул заманда тарихта билгеле Таһир мунчасы торган. Ә Болакның аргы башы Кабан күлләре системасына барып тоташкан. Бу күлләр Түбән Кабан, Урта Кабан, Ерак Кабан дип йөртелгәннәр. Кала калкулыгыннан көнбатыш тарафка күз салучының игътибарын, Болак аръягыннан ук башланып китеп, уннарча чакрымга сузылган яшел болыннар, зәңгәр төймәләр сыман ялтырап яткан күллекләр, сазламыклар, әрәмәлекләр җәлеп иткән. Каланың шушы ягындагы яшел дәрья ул заманнарда «Хан болыны» дип йөртелгән. Казан ханлыгы дәверендә биредә бәйрәмнәр, бәйгеләр, Сабан туйлары уздырылган. Бу болынлыкта Казан халкы ял итү, күңел ачу, көч сынашу, хәрби уеннар, төрле ярышлар оештырган. Болынлыкның Кабан күленә якынрак очында «Үтәч мәсҗеде» (чыганакларда «Отучева мечеть») дип аталган мәчет тә булган. Әлбәттә, ул заманнарда андый бәйрәмнәр Коръән сүзеннән башланып киткән, әлеге мәчет тә, күрәсең, күмәкләшеп намаз уку өчен салынган булгандыр. Явыз Иван килеп, аның гаскәре Казан диварларын штурмлаган чакта патшаның чатырлары нәкъ Үтәч мәсҗеде тирәсенә



XVI гасырның беренче яртысында Казанның планы һәм 1552 елда башкаланы камаган Явыз Иван гаскәренең урнашуы.



Шартлы билгеләр:

1 — XV гасырда кремль стеналары.
2 — XVI гасырда кремль, калачык (посад) стеналары һәм манаралар.
3 — Хан сарае дивары.
4 — Олы урамнар — юллар.
5 — Манаралы капкалар.
6 — Мөселман зираты.
7 — Өске базар.
8 — Аскы базар.
9 — Таһир мунчасы.

Капкалар:

1 — Олы капка.
2 — Түбән капкасы.
3 — Нургали капкасы.
4 — Алабуга капкасы.
5 — Сбой капкасы (татарча исеме сакланмаган)
6 — Аталык капкасы.
7 — Кыраиш (Кораеш) капкасы.
8 — Кырым капкасы.
9 — Аскы Нугай капкасы.
10 — Өске Нугай капкасы.
11 — Хан капкасы.
12 — Арча капкасы.
13 — Кабак капкасы.

Урамнар-юллар:

14 — *Н*угай урамы-юлы (хәзерге Бауман урамына туры килә).
15 — Хан капкасыннан кремльгә кадәр килә торгән урам-юл (хәзерге Ленин урамына туры килә).
16 — Арча урамы-юлы (хәзерге Карл Маркс урамына туры килә).
17 — Чокыр буе урамы-юлы (хәзерге Куйбышев урамына туры килә).

Күлләр:

18 — Ак күл.
19 — Черек күл.
20 — Мунча күле.
21 — Пычрак күл.
22 — Хуҗа күле.
23 — Түбән Кабан.
24 — Кыраиш (Кораеш) бистәсе.

Казанны камаган Явыз Иван гаскәренең урнашуы:
Сул канат, Сакчы полк, Уң канат, Алдагы полк, Зур полк, Шаһгали полкы.

куела. Ул анда чатырлары белән янәшә вакытлы чиркәү дә төзетә.

Көньяктан төньякка таба сузылып яткан кала калкулыгы шәһәрнең умыртка сөяген тәшкил иткән, чөнки Хан сарае, мәчетләр, шәһәр аксөякләренең бизәкле йортлары, хөкүмәт б},налары барысы да диярлек шушы калкулык өстендә урнашкан булган.

Үз дәрәҗәсен белеп, горур кыяфәт белән тау башында басып торган зиннәтле сарайларны, биек манараларын күккә терәгән таш мәчетләрне, сырлап-бизәкләп төзелгән, төсле керамика белән капланган биналарны үзән ягыннан күзәткән шәһәр кунаклары татар башкаласының мәгърур һәм чагыштыргысыз матурлыгыннан исләре китеп карап торганнар. Хәтта каланы җимерергә, мәсхәрә итәргә, дип килгән Явыз Иван белән аның воеводасы Андрей Курбскийлар да Казанның гүзәл манзарасына соклануларын яшерә алмаганнар.

Шәһәр калкулыгы артында, каланы ике өлешкә бүлгәндәй, озын һәм тирән иңкүлек сузылып яткан. Тоташ күлләр һәм сазламыклар системасын хасил итүче бу иңкүлектә, бер-берсенә тоташа язып, Ак күл, Черек күл, Мунча күле, Пычрак күлләр тезелеп киткән, алар, баскыч-баскыч төшеп, ахыр чиктә Казан суына килеп кушылган. Ә инде бу иңкүлекне аркылы чыккач, шәһәр акрынлап өскә, Арча кырына таба күтәрелгән.

Казан ханлыгы дәверендә башкаланың үзәк өлеше биек һәм калын диварлар белән уратып алынган булган, диварларда зур-зур капкалар һәм нык манаралар куелган. Диварлар эченә таш, вакташ һәм ком тутырылган. Нык булсыннар өчен алар бик киң итеп эшләнгән. Әйтик, Болак буенда сузылган диварның киңлеге 6 метр тирәсе, ә Арча кырындагысы хәтта 15 метр булган. Мөмкинлектән чыгып дивар каршына тирән чокырлар казылган, аларга су тутырылган, һәр капканың күтәртмә күпере булган.

Исемнәре безнең көннәргә килеп җиткән 13 шәһәр капкасы билгеле. Дөрес, кайберләренеке бары тик урыс телендә генә сакланган. Бу факт үзе үк күп нәрсә хакында сөйли. Башкала капкаларының исемнәрен дә урыс чыганаклары буенча билгеләрлек булгач, яулап алучылар без-

нең халыкны, гомумән, татарның матди һәм рухи мирасын юк итү буенча нинди вәхшилекләр эшләгәнен чамалавы кыен түгел.

Кала капкалары түбәндәге исемнәрне йөрткән: Олы капка, Түбән капкасы, Нургали капкасы, Алабуга (яки Илбуга капкасы), Сбойливые ворота (татарча ничек аталуы билгеле түгел), Аталык капкасы, Кыраиш (Кораеш) капкасы, Кырым капкасы, ә менә Нугай капкалары исә икәү булган: Аскы Нугай капкасы, Өске Нугай капкасы, Хан капкасы, Арча капкасы, Кабак (яки Күбәк) капкасы. Бу соңгысының да ике төрле язылышы яши. Кайсы дөрестер — әйтүе кыен, гәрчә Казан ханлыгы дәверендә татарларда Көбәк, Күбәк сыман исемнәр гадәти исемнәрдән саналган. Соңрак алардан Кубяков-Кобяков кебек фамилияләр барлыкка килгән.

Табигый, башкаланың иң мәһабәт бинакалары кала калкулыгының төньяк очында урнаша. Бу урында хәзер Президент резиденциясе, Сөенбикә манарасы, шәһәрне алу белән үк төзелгән Благовещение соборы (1556—1562) тора. Биналар арасында иң мәһабәте һәм зиннәтлесе Хан сарае була. Ул берничә таш һәм агач корылманы үзара тоташтырган комплексны тәшкил иткән һәм биек койма белән әйләндереп алынган. Хан сарае янәшәсендә генә төсле керамика белән зиннәтләнгән ак таш мәчет торган. Казанның иң затлы, йогынтылы нәселе Ширiннар сарае да шушында урнашкан булган. Татар риваятьләрендә Сафа Гәрәй ханның кабере Сөенбикә манарасына куелган, диелә. 1551 елны өч яшьлек улы Үтәмеш Гәрәй белән көчләп Мәскәүгә озатылганда Сөенбикә яраткан ире Сафа Гәрәй хан каберенә капланып нәкъ шушы төштә елаган булса кирәк.

Әгәр дә ул замандагы Казанга читтән торып күз салсаң, башкала калкулыгы өстендә биек манаралары белән күккә омтылган биш мәчетне күрергә мөмкин булган. Арадан берсе — калкулыкның көньягында урнашкан Кол Шәриф мәчете — башкаланың төп гыйбадәтханәсе саналган. Монда имам Кол Шәриф җитәкчелегендә ислам университеты эшләгән, шәкертләр илаһият гыйлеменең төрле өлкәләрен өйрәнгәннәр. Казан өчен барган көрәшнең иң соңгы һәм дәһшәтле көне — 1552 елның 2

октябрендә имам Кол Шәриф, аның тугры шәкертләре, абызлар, муллалар, гади казанлылар шушы изге йорт ишеге төбенә тупланып, ныгытма эченә бәреп кергән урыс гаскәрләренә аяусыз каршылык күрсәткәннәр һәм барысы да шәһид киткәннәр.

«Таҗик чокыры» дип йөртелгән тирән чокыр Казанны, бил каешы кебек, ике өлешкә бүлеп торган. Әйткәнебезчә, калкулыкның төньягында каланың рәсми өлеше — сарайлар, мәчетләр, хөкүмәт биналары, аксөяк катлау йортлары кебек корылмалар урнашкан була. Ә инде киң күпер салынган Таҗик чокырын үтеп чыгуга кеше бөтенләй башка Казанга килеп эләккән. Бу якта гадирәк халык яшәгән. Монда базарлар гөрләгән. Бохара якларыннан да Казанга бик күп сәүдәгәрләр килгән, шуңа күрә каланы икегә бүлеп торучы чокыр «Таҗик чокыры» дип йөртелгән. (Ул чакта әле «үзбәк» дигән милләт юк!) Каланың бу өлешендә тормыш кайнап торган. Кемдер мактый-мактый товарын саткан, кемдер алган, ә кайберәүләр, кызык табып, карап-танышып кына йөргәннәр. Халык яңа хәбәрләр ишетер өчен дә шушында килгән. Кол Шәриф мәчетеннән башка монда тагын берничә гыйбадәтханә булган. Намаз вакыты җитү белән мәчет манараларыннан агылган азан тавышлары Казан урамнарын илаһи моңга күмгән.

Әлбәттә, ул заманнарда калалар план нигезендә төзелмәгән. Бу яктан караганда Казан да, гасырлар буе үсә килеп, шәһәр мәйданы киңәя, урамнары бер-берсенә өстәлә барып, шактый катлаулы организмга әверелгән. Ул чакта Казанда туры сызык рәвешендә сузылган урамнар булмаган диярлек. Шулай да, бөтен шәһәр буенча үтеп, төп капкаларга илтә торган берничә урам булуы безгә билгеле.

Мәсәлән, кала калкулыгы итәгеннән Болак буйлап сузылган урам Нугай юлы дип аталган һәм Нугай капкасына килеп тоташкан. Нугай капкасы исә якынча хәзерге Бауман урамындагы Татар ашлары йорты тирәсендә урнашкан булырга тиеш.

Икенче бер зур урам кала калкулыгының нәкъ сыртыннан (хәзерге Ленин урамы) үткән һәм, татар кылычы сыман бераз кәкрәеп, юлчыларны Хан капкасына китереп

чыгарган. Хан капкасы исә якынча хәзерге Ленин бакчасы тукталышы урынында тоган булса кирәк.

Моннан тыш тагын бер озын урам кала буенча узган. Ул Хан сараеннан ук башланып китеп, Олы капка аша шәһәрнең рәсми өлешеннән чыккан да, Таҗик чокырына җитү белән кинәт сулга борылган, аннан аска, күлләр урнашкан иңкүлеккә төшкән. Аннан соң, иңкүлекне аркылып чыгу белән, уңга борылган. Бу урам, хәзерге Карл Маркс урамы юнәлешендә бара торгач, Арча капкасына барып терәлгән.

Без бары тик өч урамны гына телгә алдык. Әгәр дә хәзерге Казан урамнары планына күз салсак, бүгенге кайбер урамнарның борынгылары белән туры килүенә игътибар итми калмас идек. Күп гасырлар үтүгә карамастан каланың рельефы әлләни зур үзгәрешләр кичермәгән һәм шушы хәл әле дә аларның юнәлешен билгеләгән. Әлбәттә, ул заманда да Казанда аркылы-торкылы урамнар, тыкрыклар, тупиклар күп булган, алар башкала мәйданын шактый катлаулы челтәргә әйләндергән. Уйлап карасаң, Казан өчен бу табигый күренеш. Шәһәрнең иң элек калкулык өстендә төзелә башлавы, аннан, төрле чокыр-чакырларны әйләнеп уза-уза, кайчакта аларны тигезли дә барып, төрле корылмаларның, йортларның акрынлап аска, бер яктан, Болак буена төшүе, икенче яктан, эчке күлләр тезелеп киткән иңкүлек тирәсенә сырышуы, аннан кабат үргә таба үрмәләве, ә көньяк очтагы урамнарның хәзерге Пушкин урамы урынында сузылып яткан тирән ермакка хәтле килүе Казанны, чыннан да, кабатланмас йөзле шәһәр итеп формалаштырган. Казан халкы йортларны план буенча сала алмаган, каланың катлаулы рельефы төзүчеләр алдына үз таләпләрен куйган. Шул сәбәпле урамнарның күпчелеге кәкре-бөкре һәм борылмалы булган.

Казан үзенең суга бай булуы белән дә аерылып торган. Чыннан да, башкаланың үзендә дә, әйләнә-тирәсендә дә кая карама су чыганаклары: Казан елгасы, Болак, Кабан күлләре, шәһәрнең эчке күлләре, көтелмәгән җирләрдән тибеп торучы чишмәләр, алар тирәсендәге яшеллек. Болар барысы да татар башкаласын гаҗәеп үзенчәлекле, тиңе булмаган матурлыкка күмгән. Җирнең

тигез булмавы сәбәпле йортлар күч-күч урнашкан, алар арасыннан матур-матур күренешлр ачылган.

Шунысын да әйтеп үтәргә кирәк: әлегә кадәр сүз барган сарайлар, мәчетләр, бай йортлар, хөкүмәт корылмалары, күп санлы остаханәләр, чит ил сәүдәгәрләре яшәгән колонияләр, кәкре-бөкре урамнар һәм тыкрыклар барысы да диварлар белән уратылган эчке калада урнашкан булган. Һәм ышанычлы сакланган. Ә башкала диварлары түбәндәге тәртиптә узган: каланың рәсми өлеше аерым диварлар белән уратып алынып, үзе үк ныгытма эчендәге ныгытманы хәтерләткән. Аннан соң диварлар, ике канат кебек, калкулыкның көнчыгыш һәм көнбатыш ягына таба сузылып төшеп киткәннәр. Берсе, Болак буена төшеп җитәр-җитмәс, туры почмак ясап борылган да, Кабан күленә таба киткән. Әмма барып җитмичә тагын бер текә борылыш ясаган һәм хәзерге Ленин бакчасына таба үрмәләгән. (Бу урында Хан капкасы торганын әйтеп үткән идек.) Бераз шулай барганнан соң, Арча капкасын узгач, почмак ясый-ясый юнәлешен Казан елгасына таба үзгәрткән, аннан кала калкулыгына кире яктан — кояш чыгышыннан әйләнеп кайткан.

Без Казанның төрле тарафларга чыккан 13 капкасын телгә алып уздык. Һәр ике капка арасында нык манаралар торганлыгын да искә төшерик. Аларны бер-берсеннән ук җитәрлек ара калдырып төзегәннәр булса кирәк. Төрки халыкларда бер ук, ике ук дип, аралыкны билгеләү гадәте борын-борыннан килә. Бабаларыбыз да моны бөтенләй ук исәпкә алмый калмагандыр. Болай иткәндә манаралардан торып капкага килгән дошманга ату да җиңеләя төшә. Каланың Хан сарае торган рәсми өлешендә манаралар бер-берсенә тагын да якынрак урнашкан булганнар.

Яулап алынганчы Казан каласында халык бик күп яшәгән һәм ул диварлар белән уратылган эчке калага гына сыеп бетә алмаган. Халыкның байтак өлеше калачыкта (посад), һәм бистәләрдә гомер иткән. Калачыкның берсе Болак буйлап урнашкан, Болакның Кабанга барган очындарак Кыраиш (Кораеш) бистәсе үсеп чыккан. Кабан күленең көнчыгыш ярында тагын Әрмән бистәсе дә булган. Сәүдә эшенә һәвәс әрмәннәр Казан ханлыгы җир-

ләренә әле болгар заманнарыннан ук килеп төпләнә башлаганнар. Персия һәм Кавказ белән алып барылган сәүдә эшләрен алар үз кулларында тотканнар. Атаклы тарихчы М. Худяков үзенең Казан ханлыгы турындагы китабында бер кызыклы факт китереп үтә. 1552 елны урыслар Казанны штурмларга керешкәч, шактый вакытлар бернинди уңышка ирешә алмыйча интегәләр, чөнки татарлар аларның һәр һөҗүмен кире кага баралар. Җавап йөзеннән үзләре дә каладан чыгып хәтәр һөҗүмнәр оештыралар. Урысларның хәле мөшкел икәнне күреп, Иван IV гә берничә әрмән сәүдәгәре килә дә, күпмедер акча бәрабәренә, кала ныгытмаларының үтеп керү өчен уңайлы җирләрен күрсәтергә әзер икәнлекләрен әйтә. Иван IV серне сатып ала. Ә инде Казан алынып, җиңү бәйрәмнәре узгач, Иван IV кабат теге әрмәннәрне исенә төшерә. «Иске дусларын сатучылар яңаларын да сатарга күп сорамаслар»,—дип уйлый ул һәм хыянәтче әрмәннәрне үтереп бетерергә куша. Бу хакта белеп алган әрмәннәр тиз-тиз каладан качарга тотына. Әмма барыбер барысы да качып котыла алмый.

Казан елгасы буенда Бишбалта дигән авыл да булган. Бишбалта белән башкала арасында Казан суының бер тармагы аккан, ул елгачык «Эчке Казан» дип аталган. Шунысы кызык: ул заманда Идел уртасында, нәкъ шушы авылга каршы төштә бер утрау булып, ул «Кунаклар атавы» дип йөртелгән. Анда ел саен төрле җирләрдән килгән сәүдәгәрләр сату иткән. Иделнең суы үз ярларына кайту белән, җәй башында, бирегә төрле тарафлардан-илләрдән сәүдә әһелләре агыла башлаган. Шулай итеп, Казанның борын төбендә халыкара базар-ярминкә эшләп торган. Утрауда сәүдәгәрләрнең мал саклау складлары, амбарлары һәм таш пулатлары урнашкан. Сәүдәнең кызган айларында утрау кайберәүләр өчен тору-куну урынына әйләнгән.

Иделдә ярминкә эшләгән чакта Казан урамнары да җанлана төшкән, базарларда да чит илләрдән килгән ят киемле халык арткан. Алар татар башкаласына чуар үзенчәлек һәм экзотика өстәгән.

Бер уңайдан Казанның көньягында урнашкан тагын ике авылны телгә алмыйча үтеп булмый: берсе—Кабан

күле ярында урнашкан Кол Мәмәт авылы, икенчесе — Арча кыры артындагы Әхмәт (Әмәт) авылы.

Урыслар кулына төшкәнче Казан Идел буеның иң гүзәл һәм зур шәһәрләреннән саналган. Зур су юлында урнашуы сәбәпле ул тиз үскән, ныгыган һәм баеган. Әмма бераздан соң көндәше Мәскәү аңа комсыз күзен кыздыра башлаган. Мәгърур татар башкаласы яшь Мәскәү дәүләтенең көнчыгышка барыр юлына да, Идел кебек зур су юлына да киртә булып баскан. Казанны ул юлдан алып ташласаң, урыс кавеменә Тын океанга кадәрле арада нык каршылык күрсәтүче бүтән көч калмаячагын Мәскәү сәясәтчеләре яхшы аңлаган, күрәсең. Шуңа күрә Казанны тар-мар итү алар өчен Көнчыгышка ачкыч ярату белән бер булган. Һәм алар «мәгърур татар патшалыгын» юк итү өчен барысын да эшләгәннәр. Күп яулар, туктаусыз һөҗүмнәр оештыра торгач, Казан 1552 елның көзендә чыннан да егылырга мәҗбүр була.

Инде менә күп гасырлар буйсынып-буйсындырылып яшәгәннән соң Казанның яңача, мөстәкыйль тормыш башлар вакыты җитте. Ул үзенең элекке горурлыгын да, данын да кайтарырга тиеш.

Солтан Шәмси, язучы

КАЗАН ХАННАРЫНЫҢ ХАКИМЛЕК ИТҮ ЕЛЛАРЫ

Олуг Мөхәммәд Тимер угылы 1437—1446 (сарайлы)
Мәхмүд Олуг Мөхәммәд угылы 1445—1462(?) (сарайлы)
Хәлил Мәхмүд угылы 1462(?)—1467 (сарайлы)
Ибраһим Мәхмүд угылы 1467—1479 (сарайлы)
Гали (Илһам) Ибраһим угылы 1479—1487 (сарайлы)
Мөхәммәд Әмин Ибраһим угылы 1487—1495 (сарайлы)
Мамук Ибак угылы 1495—1496 (себерле)
Габдел-Латыйф Ибраһим угылы 1496—1502 (сарайлы)
Мөхәммәд Әмин Ибраһим угылы 1502—1518 (сарайлы)
Шаһ Гали Шәех-Әүлияр угылы 1519—1521 (касыймлы)
Сәхиб Гәрәй Миңле Гәрәй угылы 1521—1524 (кырымлы)
Сафа Гәрәй Фатыйх угылы 1524—1531 (кырымлы)
Җан Гали Шәех-Әүлияр угылы 1531—1533 (касыймлы)
Сафа Гәрәй Фатыйх угылы 1533—1546 (кырымлы)
Шаһ Гали Шәех-Әүлияр угылы 1546 (1 ай) (касыймлы)
Сафа Гәрәй Фатыйх угылы 1546—1549 (кырымлы)
Үтәмеш Гәрәй Сафа Гәрәй угылы 1549—1551 (кырымлы) (регентша Сөенбикә Йосыф кызы)
Шаһ Гали Шәех-Әүлияр угылы 1551—1552 (касыймлы)
Ядкәр Мөхәммәд-Касыйм угылы 1552 (әстерханлы)
Гали Әкрам Йосыф угылы 1553—1556 (нугайлы)
(Казан төшкәч өч ел тирәсе мари ягындагы Чалым каласында ханлык кыла.)

Фәхретдин Р.

Ф 97 Казан ханнары.—Казан: Татар. кит. нәшр., 1995.—189 бит.

ISBN 5-298-00491-1

Китапка үзенең йөзләгән хезмәтләре белән татар мәдәниятендә тирән эз калдырган мәшһүр галим, дин әһеле һәм мәгърифәтче Ризаэтдин Фәхретдиннең (1859—1936) Казан ханнары һәм аларның эшчәнлеге турындагы мәкаләләр тезмәсе тупланды. Укучыларга тулырак мәгълүмат бирү өчен төп текст төрле искәрмә-аңлатмалар, галимнең иҗатын яктырткан зур кереш мәкалә һәм ханлык башкаласы Казанның тарихи топографиясе турындагы язма белән баетылды.

Халкыбыз тарихы белән кызыксынучы киң катлау укучылар бу китаптан бай мәгълүмат алачаклар.

Ф $\frac{0503020900-090}{М132(03)-94}$ без объявл.—94 **ББК 63.3(2Тат.)**

Научно-популярное издание

Ризаэтдин Фахретдин

КАЗАНСКИЕ ХАНЫ

(на татарском языке)

Бизәлеш редакторы *Р. Шәмсетдинов*
Техник редакторы *Н. Зәйнуллина*
Корректорлары *А. Низамиев, И. Хасанов*

ИБ № 6547

Җыярга тапшырылды 19.05.94. Басарга кул куелды 24.01.95. Форматы $84 \times 108^1/_{32}$. Типогр. кәгазь № 2. «Тип-Таймс» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 10,08 + ф. 0,21. Шартлы буяу-оттиск 11.34. Нәшер-хисап табагы 9,24 + ф. 0,35. Тиражы 10 000 экз. Заказ А-325.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул. Баумана, 19.

Татарстан газета-журналлар нәшрияты типографиясе.
420066, Казан, Декабристлар ур., 2.

ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫНЫҢ
фәнни-популяр әдәбият редакциясе 1995 елда түбәндәге китапларны бастырып чыгара:

Р и з а э т д и н Ф ә х р е т д и н. **Алтын Урда ханнары.** Татар һәм урыс телендә.

Я к о в Г р и ш и н. **Польско-литовские татары (XIV—XX вв.)** Исторические очерки. На рус. языке.

Б у л а т С у л т а н б е к о в. **История Татарстана: Сталин и «татарский след».** Историко-публицистические очерки. На рус. языке.

Г. Б а т т а л - Т а й м а с. **Мин бер яктылык эзләдем.** Кызыл дөнья (20 нче елларда Төркиягә күчеп киткән татар тарихчысының хатирәләре). Төрекчәдән тәрҗемә.

Әхмәд ибне Фазланның Иделгә сәяхәте. Бизәлгән басма. Татар һәм урыс телендә.

А. В. Е ф р е м о в. **Петр Иванович Рычков (историк и просветитель).** На рус. языке.